ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№ 11 (335) – НОЯБРЬ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Ташландык сәнәгать территорияләренә – яңа сулыш

Юныс Әхмәтҗанов: «тәмле ашлар җырчысы»

Карашай-Саклау: дүрт Саклауның берсе

КАДЕРЛЕ ЯДКАРЬЛӘР МУЗЕЕ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Мөршидә Кыямова, Ксения Сёмина,
Луиза Шарова, Илшат Фәйзрахманов
Фотографлар: Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: «Әлифба» музеенда (Арча районы)
Лилиана Вәлитова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1150 данә,
рус телендә: 2350 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-3246
Басарга кул куелды: 26.11.2019
Басмадан чыкты: 29.11.2019

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ТЫЛСЫМЧЫЛАР КАЙДА ЯШИ?

18 ноябрьдә барлык тылсымчы бабайлар да Бөек Устюгка – Дед Морозга кунакка юнәлде. Безнең Кыш Бабайдан башлап Йоулупуккига кадәр – һәммәсе. Ә без алар турында беразгына гәп куертып алу бер дә зыянга булмас, дигән фикергә килдек.

Әлбәттә, туган көнен билгеләүче тылсымчы бабайларның иң-иң атаклысы бик җиңел генә теләкләр үтәү сәләтенә дә ия, чыршы төбенә бүләкләрне сиздерми генә калдырып китү осталыгына да... Моннан кала да әллә никадәр таланты бар аның. Үзе дә, аның тылсымчы агай-энеләре дә тылсымны эзлекле рәвештә, җиренә җиткереп, гасырлар дәвамында башкарып килә. Һәм, әйтергә кирәк, эшләрендә тоткарлык йә тәртипсезлек булганы күзәтелмәде әле бүгенгә кадәр. Әмма без аларның барысын да белеп кенә бетермибез...

Күптән түгел массакүләм мәгълүмат чараларында күңелне җылыта торган яңалык пәйда булды да, күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Чөнки ул чын-чынлап игелек һәм кече күңеллелек турындагы яңалык. Казанда яшәүче Николай Трофимов исемле бабай Крутушка янындагы Казансу аша сузылган асылмалы күперне төзекләндергән. Үз көче белән, пенсия акчасына! Акча белән аның башлаган эшенә сокланучылар һәм битараф булмаучылар да булышкан. Ремонтка бабакай 137 мең сум акча сарыф иткән, шуларның 80 мең сумы – үзенең акчалары, 57 меңе халыктан җыелган.

Хәзер Крутушка күперендә гашыйклар фотога төшә, Инстаграм шул ягымлы сурәтләр белән чуарланды. Барысы да заманыбызның тылсымчы бабаена рәхмәтләрен юллый.

Тагын бер очрак: Иске Чүпрәле авылында 83 яшьлек бабай авылдашларына... җимеш бакчасы бүләк итәргә карар кылган! Камил Бикмөхәммәтов үз куллары белән һәм үз акчасына бакча булдырырга керешкән. Авылдашларыма ничә еллар буе ярдәмләшеп яшәгәне, туганнарча якынлык күрсәткәне өчен шушы бакча аша рәхмәтемне белдерәм, ди ул.

Бакча коллекциясендә төрле сортлардагы 75 данә алма, чия, слива куаклары бар. Бу ни дигән сүз? Берничә елдан Иске Чүпрәле язларын ап-ак чәчәккә батып утырачак, димәк! Ә көзен җиләк-җимеш исеннән, тәменнән хушланачак.

Ә сез нинди тылсымчы бабайларны беләсез? Сөйләгез алар турында безгә дә – үзегезнекеләрме, күршеләрме, авылдашлармы, бөтенләй таныш түгелләрме... анысы әллә ни мөһим түгел. Иң мөһиме – алар безнең арада яши. Ә Яңа ел алдыннан безнең журналда тылсымчылар турында менә дигән тарихлар тупланачак!

ТЫЛСЫМ КӨЧЕНӘ ЫШАНУЧЫ, **СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯ**

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Харис Якупов. «Татария алтыны», 1974 ел.

НОЯБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

6. Тынычлык максатларында рухи энергия
Фарсы култыгында толерантлык дәресләре турында

8. Бөтенсоюз масштабындагы шәхес
Түбән Кама химкомбинаты төзелешенең башында кем торган

10. Онлайн-сәүдәне үстерү өчен логистиканы оештыру
Индустриаль парктагы төзелешләр нинди нәтиҗәләргә китерәчәк

12. Реинкарнация. Архитектура аспекты
Ташландык сәнәгать территориясен ничек заманча шәһәр районына әйләндерергә

18. Башкала көзгесе
Аккош күлен ни рәвешле яңарттылар

24. «Ул әле дә безне тәрбияли...»
Әниләр көне уңаеннан

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

30. Мистика юк – бары тик кулларның сизгерлеге генә
Баш авыртуларның сәбәбе кайда яшерелгән

32. «Тәмле ашлар җырчысы»
Хрущевны Казанда тутырган тавык белән кем сыйлаган

42. Искәндәр Гыйләҗевның тормыш линиясе
Татфакны нигә саклап калып булмый иде...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

48. Әлифба музее
Дөньяда бердәнбер әлифба музее кайда урнашкан

52. Хәрби машина экипажы
Танк училищесы музеенда нинди раритетлар саклана

56. Иске Татар бистәсе музее
«Дөрес» татарлар һәм «барабыз» чаналары

62. Стратосферага күтәрелү
Тавыш тизлегеннән тизрәк Ту-144 очкычында ничек очарга

66. Зөя тарихы музее
Кайда ят кеше хатларын укырга мөмкин

70. Николай II бүләге
Император Казан университетына нинди бүләк тапшырган

74. Тарих сәхифәләре
Хәлфиннар династиясе

84. Татар авыллары
Карашай-Саклауда картлык ничәдә башлана

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

05.11

Борис МЕНДЕЛЕВИЧ, Татарстаннан РФ Дәүләт Думасы депутаты:

– Фитнес-хезмәтләр өчен салымнардан чигерүне гамәлгә кертү – минемчә, уңай башлангыч. Сәламәт яшәү рәвеше – сәламәтлекне саклауның мөһим өлеше. Әгәр дә һәркайсыбыз үзенең сәламәтлеген кайгыртмаса, хәтта бик күп акчалар керткән очракта да, без бу юнәлештә беринде җитди уңышларга ирешмәячәкбез.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

18.11

Павел КОЛОБКОВ, Россия Федерациясенең спорт министры, – ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов белән эшлекле очрашу вакытында:

– Алдагы елларда Казанда, су спорт төрләре буенча 2025 елда узачак дөнья чемпионатын да кертеп, күпсанлы халыкара ярышлар үткәреләчәк. Су спорт төрләре буенча Европа чемпионатын уздыруга гариза бирергә җыенабыз. Моның өчен барлык шартлар тудырылган – 2013 елгы Бөтендөнья Универсиадасы, 2015 елгы су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты кебек эре халыкара ярышлар үткәрелүнең нәтиҗәсе бу...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

9.11

Дамир ЙОСЫПОВ, очучы, Россия Герое, – «Мәскәү – Татарстан күпере» Бишенче Мәскәү яшьләр форумында:

– Белүебезчә, самолет җилгә каршы очып күтәрелә һәм төшә. Шуңа күрә мин сезне тормыш кыенлыклары һәм киртәләреннән курыкмаска өндәр идем, үз күңелегезне тыңлагыз, бирешмичә, бары тик алга гына барыгыз.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Бөтен дөньяда иминлекне һәм тотрыклылыкны **НИЧЕК** сакларга

Түбән Кама химкомбинаты төзелешенең башында **КЕМ** торган

«Яшел Үзән» ТР кече һәм урта эшкуарлыгын үстерүгә **НИНДИ** йогынты ясый

Ташландык сәнәгать территориясен **НИЧЕК** заманча шәһәр районына әйләндерергә

Табигать бүләкләрен **НИЧЕК** кайтарырга

ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2020 елның
I яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 933 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 933 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7077 **татар телендә**

П 7076 **рус телендә**

«Татарстан» журналына ТР буенча еллык язылу индекслары:

ПА 468 **татар телендә** 1866 сум 00 тиен

ПА 471 **рус телендә** 1866 сум 00 тиен

Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

ДУБАЙ. ТОЛЕРАНТЛЫЛЫК ДӘРЕСЕ

Нәхайян бән Мөбәрәк Әль Нәхайян, БГӘнең толерантлык министры:
–Әлеге форум – Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә озак еллар дәвамында алып барыла торган зур хезмәтнең турыдан-туры дәвамы. Без илебездә толерантлык принципларының никадәр таралуы белән горурланабыз. БГӘ халкы, ихтимал булган экстремизм чагылышларыннан һәм раса сегрегациясеннән курыкмыйча, үз киләчәген төзи, балалар тәрбияли.

Фото ТР Президенты сайтыннан

НӘРСӘ:

II Бөтендөнья толерантлык саммиты

КАЙДА:

Дубай, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре

КАЙЧАН:

13–14 ноябрь

ТУЛЫРАК:

Толерантлык җәмгыять иминлегенә юнәлдерелгән, тынычлык һәм бердәмлекне ныгытучы рухи энергия булып тора. Дубай форумының максаты – бөтен кешелек дөньясы иминлеген ныгыту юнәлешендә сөйләшү-аңлашуларның глобаль платформасына әйләнү, диде ачылыш тантанасында БГӘ толерантлык министры Нәхайян бән Мөбәрәк Әль Нәхайян. Саммит кысаларында ачылган күргәзмәдә Татарстан стенды да урнаштырылган иде. Анда милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне ныгыту буенча республика тәҗрибәсе турында, дини объектларны һәм һәйкәлләрне төзәтү, Халыклар дуслыгы йорты эшчәнлеге хакында сөйләнде.

Милләтара һәм динара татулык – тотрыклылыкның нигезе һәм алга таба үсешебезнең мөмкинлекләре ул, дип белдерде ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, саммитның пленар утырышында чыгыш ясаганда. Татарстанда 173 милләт вәкилен үз эченә алган 4 млнга якын кеше үзара дус һәм тату яши. Республикада толерантлыкны һәм тотрыклылыкны ныгытуга традицион конфессияләр зур өлеш кертә, дип басым ясады Президент. Республикада мөселман һәм православие ядкәрләре беррәттән торгызыла. Күркәм мисал – территориясендә Колшәриф мәчете дә, православиелеләрнең Благовещение соборы да урнашкан Казан Кремле. Свияжск утрау-шәһәрен һәм Изге Болгарны яңарту буенча гаять зур эш башкарылды. Ике объект та ЮНЕСКО тарафыннан танылу алды. Соңгы проектлар арасында – Болгар ислам академиясе төзелеше һәм Казан Изге ана иконасы соборын яңадан торгызу.

«Республикада Татарстан Президенты каршында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча Совет эшли. Без Дәүләт милли сәясәте концепциясен эшләдек һәм кабул иттек. Казан федераль университеты базасында Фәнни-эксперт советы эшли. Һәм, әлбәттә, үз эшчәнлегебездә без мөфтиятебезгә һәм митрополиягә таянабыз – бу безгә тынычлыкны, татулыкны һәм тотрыклылыкны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә», – диде ТР Президенты, республикада дини белем бирүгә җитди игътибар күрсәтелүгә басым ясап.

Шунысын билгеләп үтик: әлеге форум кысаларында Татарстан Республикасы толерантлыкны үстерүгә керткән өлеше өчен махсус бүләккә лаек булды. Бүләкне Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова алды.

Саммит барышында ТР Президенты Согуд Гарәбстаны принцессасы Ламия бине Әбделмәҗит Әл-Согыд – Alwaleed Philanthropies хәйрия фонды генераль секретаре белән очрашты. Фонд мәгариф, сәламәтлек саклау, хатын-кызлар хокуклары өчен көрәш өлкәләренә, стихияле бәла-казалар зыяннарын юкка чыгаруга караган хәйрия проектларын гамәлгә ашыра. Мәдәниятләр арасында диалогны үстерү, Европа илләре арасында ислам мәдәниятен презентацияләү – шулай ук Alwaleed Philanthropies фонды эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре арасында. Рөстәм Миңнеханов әлеге чараларда уртак катнашу мөмкинлеген тикшерүне тәкъдим итте.

БЕЛЕШМӘ:

II Бөтендөнья толерантлык саммитында төрле дәүләтләр, дини учреждениеләр, уку йортлары, мәдәни ассоциацияләр, дәүләтнеке булмаган оешмалар вәкилләре һәм төрле фикерләр лидерлары катнашты. Форумның темасы – «Мультикультурализмда толерантлык: толерантлы дөньяда социаль, икътисадый һәм гуманитар өстенлекләргә ирешү». Катнашучылар бөтен дөньяда куркынычсызлыкны һәм тотрыклылыкны тәэмин итү өчен хезмәттәшлекне һәм партнёрлык мөнәсәбәтләрен ныгытуга аерым игътибар бирделәр.

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Безнең республика уникаль тәҗрибәгә ия: мең еллар дәвамында бергә ике традицион конфессия – ислам һәм православие вәкилләре үзара тыныч яши. Без бер-беребезне тулысынча аңлыйбыз.

ТҮБӘН КАМА. ТАРИХТА ШӘХЕСНЕҢ РОЛЕ

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Миңа Николай Васильевич Лемаев белән шәхсән аралашырга туры килде. Химия өлкәсендә тирән белемгә һәм киң эрудициягә ия булу белән бергә, аңа масштаблы категорияләр белән перспективага карап фикер йөртә белү хас иде. Вакыт аның зирәклеген һәм алга карап дөрес фикер йөртә белүен раслады.

Фото ТР Президенты сайтыннан

НӘРСӘ:

«Түбән Кама Нефтехим»ның беренче генераль директоры Николай Лемаевның 90 еллыгына багышланган тантаналы чаралар

КАЙДА:

Түбән Кама

КАЙЧАН:

13 ноябрь

ТУЛЫРАК:

Түбән Камада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Николай Лемаев һәйкәленә чәчәкләр салды, ул яшәгән йортта мемориаль такта ачу тантанасында катнашты, шулай ук әлеге легендар шәхескә багышланган фотокүргәзмә белән танышты.

Күренекле шәхес, профессионал, үз иленең патриоты Николай Васильевич Лемаевның 90 яшьлеге – Россия һәм Татарстан Республикасы сәнәгате тарихында мөһим вакыйга, диде Рөстәм Миңнеханов Халык иҗаты йортында истәлекле чараны ачканда. «Европада иң эре нефть химиясе комплексының һәм Түбән Кама шәһәренең төзелеше һәм үсеше Лемаев исеме белән тыгыз бәйләнгән. 60 нчы еллар башында Татарстанда нефть сәнәгате көчле үсеш ала. Зур нефть бөтен Советлар Союзының нефть химиясе үсешенә куәтле этәргеч бирә. Әлеге киңкүләм проектның башында яшь җитәкче Николай Лемаев тора, ул аның хәрәкәтләндерүче көче һәм йөрәге була. Көнбатыш Себердә нефть химиясе производстволары төзелеше файдасына Түбән Кама химкомбинатын төзү ҮК һәм СССР Министрлар Советы карары белән дүрт тапкыр туктатыла һәм бары тик Николай Васильевичның үҗәтлеге һәм ныклы дәлилләре нәтиҗәсендә проектны яңадан башлыйлар. Лемаев «Түбән Кама Нефтехим» белән 22 ел җитәкчелек итә, һәм нәкъ менә шул чорда химкомбинатта үзенең мөһимлеге, масштабы һәм тормышка ашырылган технологияләре буенча уникаль булган җитештерү куәтләре гамәлгә кертелә. Түбән Кама шәһәре илебезнең иң төзек һәм заманча шәһәрләренең берсенә әверелә», – диде Татарстан Президенты.

Киләчәктә СССР химия һәм нефть эшкәртү сәнәгате министры вазыйфасында Николай Лемаев илнең әлеге тармагы үсешенә шактый өлеш кертә. Химия өлкәсендә тирән белемгә һәм киң эрудициягә ия булу белән бергә, аңа масштаблы категорияләр белән перспективага карап фикер йөртә белү хас була. Полимерлар җитештерү буенча Лемаев тарафыннан әзерләнгән проектлар аның укучылары тарафыннан тормышка ашырыла. Хәзерге вакытта «Түбән Кама Нефтехим» 120 дән артык исемдәге югары технологияле продукция җитештерә, Россиянең синтетик каучук һәм пластик базарында лидер булып тора, дип басым ясады Рөстәм Миңнеханов.

«Түбән Кама Татарстанның төп үсеш нокталарының берсенә, нефть химиясе башкаласына әйләнде, – диде ТР Президенты. – Николай Лемаев үзеннән соң якты истәлек калдырды: ул шәһәрне илебезнең төп сәнәгать үзәкләренең берсе буларак формалаштырган җитәкчеләрнең берсе булды. Халык тавыш бирүе нәтиҗәсенә «Бигеш» аэропортына Николай Лемаев исеме бирелүе дә очраклы гына түгел».

Шул ук көнне Рөстәм Миңнехановка «Бигеш» аэропортын бизәү проектын күрсәттеләр. Татарстан Президенты аэропортны бизәү буенча иң яхшы проектка бәйге игълан итәргә тәкъдим кертте.



ЯШЕЛ ҮЗӘН РАЙОНЫ. ОНЛАЙН-СӘҮДӘ ӨЧЕН ЛОГИСТИКА

Фото ТР Президенты сайтыннан

НӘРСӘ:

Онлайн-сатулар буенча компанияләрнең бүлү үзәкләре төзелешен башлау

КАЙДА:

Яшел Үзән районы

КАЙЧАН:

11 ноябрь

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Бүген дөнья электрон сәүдә юнәлешендә үсә. Республикада мондый куәтле база булдыру кече һәм урта бизнесны үстерүгә җитди этәргеч бирәчәк һәм гомумән алганда халыкка хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшыртачак.

ТУЛЫРАК:

«Яшел Үзән» индустриаль паркында Wildberries һәм Ozon компанияләренең бүлү үзәкләре төзелеше башланды. Әлеге вакыйгага багышланган тантананы ачканда, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзәкне сафка бастыру республикада кече һәм урта бизнесны үстерүгә җитди этәргеч бирәчәк һәм гомумән алганда халыкка хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшыртачак, дип билгеләп үтте.

Ozon компаниясенең яңа хабын киләсе елда ачарга ниятлиләр. Аның эшли башлавы ТРның өч меңнән артык торак пунктына товарларны тиз арада китереп җиткерергә мөмкинлек бирәчәк. Үзәктә җиде миллион товарны саклау һәм эшкәртү өчен мөмкинлекләр тудырылачак. Татарстан җитештерүчеләре дә, Ozon маркетплейс платформасыннан файдаланып, үз продукцияләрен бөтен Россия һәм дистәләгән чит илгә сата алачак.

Wildberries бүлү үзәген ачу республикада дүрт меңнән артык яңа эш урыны булдырырга мөмкинлек тудырачак. Бу турыда компаниянең генераль директоры Татьяна Бакальчук хәбәр итте. 2020 елның беренче яртыеллыгында аның беренче чиратын эшләтеп җибәрү көтелә. Проектка салынган инвестицияләрнең күләме 5,5 миллиард сумны тәшкил итәчәк.

Сүз уңаеннан, биредә, индустриаль паркта, бу көнне X5 Retail Group компаниясенең яңа бүлү үзәге эшли башлады. «Бу бик кирәкле һәм кызыклы проект. Комплексның мәйданы 38 мең квадрат метрдан артыкны тәшкил итә. 500 эш урыны төзү планлаштырылган – бу шулай ук бик мөһим. Һәм инде иң мөһиме – «Пятерочка» системасының товар үткәрү челтәре республика кулланучылары һәм Татарстан тәэминатчылары мәнфәгатендә эшләячәк», – диде Рөстәм Миңнеханов объектны ачканда.

Махсус күргәзмә кысаларында Татарстан Президенты X5 Retail Group кибетләрендә үз товарларын сатучы Татарстан җитештерүчеләре продукцияләре үрнәкләре белән танышты. «Әлеге комплексның ачылышы җирле тәэминатчылар белән эшләүнең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк», – диде «Пятёрочка» сәүдә челтәренең генераль директоры Сергей Гончаров.

Бүлү үзәге территориясендә сигез төрле саклау зонасы урнашкан: киптерелгән продукция склады, катырылган эшләнмәләр, җиләк-җимеш, яшелчә һәм башка товарлар өчен мәйданчыклар. Һәр секциядә продуктлар бозылмасын өчен тиешле температура режимы саклана. Яңа үзәкнең куәтләре тәүлегенә биш мең тоннага кадәр йөкне эшкәртергә һәм 1,2 мең сәүдә объектына хезмәт күрсәтергә мөмкинлек бирә. Комплекс Татарстан, Удмуртия, Мари Эл һәм Чувашия кибетләрен продуктлар белән тәэмин итәчәк.

Александр Шульгин, Ozon компаниясенең генераль директоры:
– Татарстан халкы онлайн-сатып алуларга булган кызыксынуы белән тәэсирләндерә. Мондый үсеш потенциалын канәгатьләндерү бездән беренче чиратта татарстанлылар өчен логистика инфраструктурасына һәм ассортиментка акчалар кертүне таләп итә. Без, рекордлы срокларда киңкүләмле проектыбызны гамәлгә ашыруда күрсәткән ярдәме өчен, республика җитәкчелегенә рәхмәтебезне белдерәбез. Әлеге проект кысаларында логистика комплексында бер меңнән артык яңа эш урыны ачылачак.

БЕЛЕШМӘ:

«Яшел Үзән» сәнәгать мәйданчыгында инфраструктура объектлары Моношәһәрләрне үстерү фонды ярдәмендә төзелде. Бүлеп бирелгән акчаларның суммасы 931 миллион сумнан артып китте. Әлеге акчаларга керү һәм мәйдан эчендәге юллар һәм мәйданның инженер челтәрләре төзелде. Барлык объектлар да эксплуатациягә тапшырылды.



Казан архитекторлары Илсөяр Габдрахманова белән Ринат Гарипов (биеннале финалистлары, «Порт элеваторы» категориясе) фән белән иҗатны берләштерә торган үзенчәлекле пространство уйлап чыгарган. Анда үсәргә, фикердәшләр белән аралашырга, сәнгать әсәрләреннән ләззәт алырга мөмкин.

ПРОМЗОНА. **РЕИНКАРНАЦИЯ**

Ташландык сәнәгать территориясен шәһәрнең заманча районы итеп үзгәртү? Рәхим итеп! Иннополиста яңа җәмәгать урыннары турында архитектура экспертлары хөкеменә чыгарылган утыз проект әлеге сорауга нәкъ шулай дип җавап бирә.

Автор:
Ольга Туманская

ЯҢА ФОРМАТЛЫ ТОРМЫШ

Хыял ярымутравы. Әйе, әйе, Идел суы юа торган әлеге урын миңа нәкъ шулай күренә. Анда озак итеп, иркенләп һава сулап йөрергә мөмкин. Тагын әле эшләргә була, алга барырга һәм яшәргә – әгәр дә сиңа гүзәллек белән иҗат хакимлек итә торган формат ошый икән, нигә юк ди әле? Паркта аллеяләр арасында нон-стоп режимында театраль перфоманслар бара, каршыдагы Үзеңне таныту мәйданында заманча сәнгать фестивале «кайный». Янәшәдә – Витрувий трилогиясенә охшатып эшләнгән һәм үзендә төплелек (фән), файда (бизнес) һәм гүзәллекне (иҗат) берләштергән атаклы концептуаль архитектура комплексы. Бу бизнес-инкубаторлары һәм коворкинглары, тикшеренү лабораторияләре һәм институтлары, концерт заллары һәм лекторийлары, остаханәләре һәм сәнгать студияләре, рестораннары һәм кунакханәләре булган иҗади индустрия дөньясы…

Биредә мин, туктап, әлеге картинаның киләчәктән икәнлеген танырга мәҗбүрмен. Аны Казанның «АКС «ЭСФОЭС Архитекс» компаниясенең яшь архитекторлары Илсөяр Габдрахманова һәм Ринат Гарипов уйлап чыгарган. Алар Иннополиста үткән Икенче Россия яшьләр архитектурасы биенналесының утыз финалисты арасында.

Сүз уңаеннан, биеннaледа катнашучылар алдына куелган бурыч җиңелләрдән түгел иде – Казандагы конкрет сәнәгать объектын ревитализацияләү проектын эшләргә кирәк. Икенче төрле әйткәндә, ташландык, шыксыз сәнәгать зонасын заманча район итеп үзгәртергә. Аңа җан өрү турында да уйларга кирәк әле! Мин күңелдән генә сәйран кылып йөргән киләчәк ярымутравы – Казанның Елга порты янәшәсенә «хыянәтчел» төстә җәелеп утырган порт элеваторы. Ни өчен «хыянәтчел» рәвештә? Чөнки әлеге территориянең мөмкинлекләре күпкә киңрәк – бу урын шәһәр халкын тартып торучы бер үзәк, шулай ук туристлар өчен Казанның тагын бер матур йөзе була алыр иде. Һәм бу фикер күп еллар инде шәһәр төзүчеләргә һәм хакимияткә тынгылык бирми. Архитектура биенналесы хыялларны тормышка ашыруның күп төре вариантларын тәкъдим итә.

Фото: Александр Ефремов, Икенче Россия яшьләр архитектурасы биенналесының матбугат хезмәте

ХӘТЕР УРЫНЫ

Үткәннәр турындагы хәтерне чүп искә төшереп тора? Нишләп тиеш түгел, ди? Казанда булачак «чүп революциясе» шаукымында әлеге идея заманча гына түгел, концептуаль яктан да бик вакытлы күренә. Аны Уфаның «КБ 11» бюросыннан яшь архитекторлар үзләренең проектларында кулланырга җөрьәт иткән. Куркып тормаганнар һәм... «Сантехприбор» заводы» категориясендә көмеш медальле булдылар. Әлеге үле сәнәгать «аждаһа»сы биенналеда катнашучыларга проект өчен тәкъдим ителгән икенче зона иде. «КБ 11» яшьләре аның территориясенең бер өлешен актив рельефлы җәмәгать урыны итеп үзгәрткәннәр, ул «истәлек итеп махсус калдырылган мәйданда сәнәгать калдыклары «катырылган» тарихи катлам ярдәмендә эшләнергә мөмкин». Шул рәвешле утопия-шәһәр барлыкка килә, аның хәрабәләре кулланырга яраклы. Биредә кайгырырга урын юк, архитекторлар сәнәгать антуражын күпфункцияле корылмалар белән аралаштырганнар, алар исә аудиториянең ихтыяҗына карап, пыяла оранжерея һәм хәрәкәтләнә торган яктылык объектлары, кайчандыр биредә булган цехларның контурларын кабатлаган трансформацияләнә торган диварлар, күперләр, декоратив сулыклар ярдәмендә үзгәртергә мөмкинлек бирә. Әйе, киләчәктә әлеге территория урам белән интерьерлар, шәһәр белән өй җиһазлары арасындагы чикләр җуелган уникаль урын булып китәргә дә мөмкин. Сезгә мондый идея ошыймы?

– Бездә иҗади кешеләргә мохтаҗлык бар, ә аларны шушындый форумнарда яшьләр арасыннан табарга була. Миннән арт-директор чыкмый инде, мин кирпеч белән измә генә ташый алам, – дип шаяртты Рөстәм Миңнеханов, финалга чыккан яшь архитекторларның эшләре белән илһамланып. ТР Президенты сәнәгать территорияләрен ревитализацияләү – яңадан җан өрү темасының бүгенге көндә илебезнең бик күп шәһәрләре өчен актуаль булуын искәртте. Казан да чыгарма түгел: республика башкаласының Иделгә карап торган иң матур урыннарында чистарту корылмалары, йөк порты, сәнәгать зоналары урнашкан. Шундый ук вазгыять шәһәрнең кайбер үзәк районнарында да күзәтелә...

– Советлардан соңгы чорда без күп нәрсәләрне югалттык, хаталар җибәрдек. Һәм бүген яңача караш бик әһәмиятле. Яшь архитекторлар яңалык алып киләчәк, заманча эшләячәк. Без аларны һичшиксез эшкә җәлеп итәчәкбез – эш җитәрлек!

Генпланнан күренгәнчә, элеккеге промзоналар зур мөмкинлекләр бирә. Биенналеның абруйлы кураторы һәм жюри рәисе, Россия һәм Германиянең танылган архитекторы Сергей Чобанның фикере шундый.

– Бүген бөтен архитектура тарихи мохит белән аның урынына килгән яңасы арасындагы «талаш» нәтиҗәсендә барлыкка килә. Ләкин, беләсезме, миңа калса, архитектурада инде бөтен төрле формалар да табылган, шуңа бүген тагын да көтелмәгән яңа формалар табу процессы түгел, ә әйләнә-тирә контекстына ниндидер яңалык кертү, халыкның барлык төркемнәренең тормышына уңайлылык китерә торган пространство булдыру тенденциясе кызыклы. Кичәге белән бүгенге төзелеш үзара ярашырга омтылганда, иң үзенчәлекле, иң киеренке үсеш нокталары табыла. Шуңа да шәһәр өчен мондый территорияләр – киртә түгел, ә үсеш юлы.

Әлеге процессның бер чылбыры булган заманча тренд – акыл белән уйлап эшләү, дип саный архитектор. Ресурсларны бәрәкәтле тотып, әйләнә-тирә мохиткә зыян китермичә төзергә мөмкинлек бирә торган проектлар вакыты җитте. Әлеге территорияләрне үзгәртү турында уйлаганда, тарихи субстанцияне бәяләү төп критерий булып кала: «Сүтәргәме, әллә сакларгамы дигәндә, һәрвакыт аек акыл белән бәяләргә кирәк». Һичшиксез сакланырга тиешле архитектура һәйкәле турында сүз бармаганда, билгеле. Шул ук вакытта «урын хәтерен» саклау да мөһим, дип басым ясый Чобан.

Мондый объектлар белән эшләгәндә, архитекторлар аккош, чуртан һәм кысланы хәтерләтмәсен өчен, РФ Төзелеш министрлыгы, «Дом РФ» компаниясе һәм «Стрелка» институты белән берлектә, шәһәр төзелешен көйләү һәм архитектура проектлары өлкәсендә норматив-хокукый базаны камилләштерү максатыннан Сәнәгать территорияләренең комплекслы үсеше стандартын эшләгән. Документта уңай халыкара тәҗрибә дә исәпкә алынган. Хәзерге вакытта документны кулланышка кертү бурычы куелган. «Дом РФ»

Уфаның «КБ 11» бюросы архитекторлары (биенналеның «Сантехприбор» категориясендә көмеш медаль ияләре) җәмәгать урынының актив рельефлы яңа форматын уйлап чыгарган.

компаниясе директор урынбасары Денис Филиппов әйтүенчә, биредә сүз стандарт төзелеш турында бармый. Документта иң мөһиме – төзелеш типларын төгәл билгеләү турында язылган, ул исә яңа территорияләр булдыру мөмкинлеге бирә һәм безнең шәһәрләрне тагын да уңайлырак итә.

Ләкин әлеге документ көн кадагындагы проблеманы – бүген Мәскәү, Санкт-Петербург (хәзер инде Казанда да борын төртә башлаган) архитекторлары белән девелоперлары арасындагы каршылыкны уңай хәл итәрме? Мәскәүнең Халыкара архитектура академиясе профессоры, DNKag төркеме генераль директоры Константин Ходнев раславынча, әлегә архитекторлар сәнәгать архитектурасы һәйкәлләрен яңадан җан өреп саклап калырга омтылганда, девелоперлар, аларны сүтеп, ул урынга «йөз, ә иң яхшысы – ике йөз катлы» йорт салырга тырыша.

Казан үзәгендәге тарихи территорияне шушы рәвешле файдалану буенча мисал итеп, күптән түгел сүтелгән һәм шуның аркасында киң җәмәгатьчелектә зур канәгатьсезлек тудырган Арча казармаларын китерергә була. Хәрби шәһәрчек буларак, кайчандыр бу урында Казан капкалары булган, йөз ел үткәч тә ул, тарихи әһәмиятен саклап, шәһәр кешеләренең яраткан җәмәгать урынына әверелә алыр иде. Күрәсең, Арча казармаларын мондый тормыш белән яшәтергә теләүче табылмаган, аның каравы, әлеге җир участогына альтернатив рәвештә – казармаларсыз гына файдаланырга теләүче инвестор пәйда булган.

ЯҢА КӨЧ УРЫННАРЫ

– Шәһәрнең генпланы контекстында сәнәгать зоналарының үсеш нокталары булуында шәһәр төзүчеләрнең дә, республика хакимиятенең дә шиге юк. Ә менә әлеге үсешнең ни рәвешле барачагы хакында берәү дә анык кына әйтеп бирә алмый, – диде ТР Президенты ярдәмчесе һәм биеннале директоры Наталия Фишман-Бекмамбетова. – Бу безнең өчен үтә дә актуаль тема, без аннан беркая да китә алмыйбыз һәм монда акыл белән эш итү сорала. Биеннале безгә ярдәм итәр, дип ышанам. Без мондый стратегия формалашу өчен этәргеч бирәбез, дип уйлыйм, һәм финалга үткән архитекторларны җәлеп итәчәкбез.

Биенналеның иң яхшы проектлары гамәлгә ашырылачакмы соң? Моны инде жюри әгъзалары түгел, ә сәнәгать зоналарының хуҗалары хәл итәчәк. Наталия Львовна элеккеге «Сантехприбор» заводының хуҗасы ревитализация белән кызыксынуын белдерде, диде. Завод хуҗасы, әлегә кадәр иң катлаулысы нинди дә булса стратегиянең булмавы иде, хәзер исә никадәр идея бар, дип белдергән.

Сүз уңаеннан, идеяләр турында. Ревитализация буенча барлык проектлар да бу урынның хәтерен саклауны һәм территориянең яңа функциональ исәпкә алып эшләнде. Шул рәвешле, архитекторлар бизнеска уйланылган, җентекләп эшләнгән вариантлар тәкъдим итә.

– Үзебезнең проектта без бернәрсәне дә сүтмәдек һәм махсус рәвештә биналарның бер өлешен элеватор зонасына урнаштырдык, – ди Илсөяр Габдрахманова. – Казанда мон-

дый сәнәгать территорияләре бихисап, шул ук вакытта алар безнең тарих. Шәһәр катлам-катлам шул тарихка таянырга, иске участокларны яңа социаль ихтыяҗларга яраклаштырырга тиеш. Һәм бу шул исәптән шәһәрләрнең җәелү проблемасын да хәл итә.

Мондый язмыш порт элеваторы белән «Сантехприбор»ны гына көтми дип ышанасы килә, бертуган Крестовниковлар һәм Петцольдларның тарихи заводларына, шулай ук Казанның башка урыннарына да кагылсын иде.

Ләкин ниндидер мәйданны реконструкцияләп, алга таба кешеләр анда үзеннән-үзе килер, дип өметләнергә кирәкми. Тәҗрибә күрсәткәнчә, шәһәр тукымасын үзгәртү һәм сәнәгать территорияләрен җәмәгатьчелеккә кайтару процессы һәрвакытта да бертөрле генә бармый. Кайбер очракларда идея, дәүләт сәясәтенең бер өлеше буларак, өстән төшә. Кайбер очракларда исә коммерция структуралары яки шәһәр халкы инициативасы белән эшләнә. Һәм беркайчан да бу эшнең нинди нәтиҗәләргә китерәсен, ташландык урынга җан керәчәкме, юкмы икәнен алдан төгәл итеп әйтеп булмый. Биенналеда шушы турыда да сөйләштеләр, чөнки алдан уйлап эшләнмәсә, сәнәгать зоналарын ревитализацияләү идеясе, ким дигәндә, файдасыз булачак.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов сәнәгать территорияләрен ревитализацияләү темасы бүген илнең күп шәһәрләре өчен актуаль һәм Казан да чыгарма түгел, дип билгеләп үтте.

– Күптән түгел генә әле Россиянең һәрбер шәһәрендә сәүдә комплекслары шундый «көч урыны» иде – халык мегамолларга кирәк-ярак сатып алырга да, буш вакытын уздырырга да йөри иде. Хәзер инде икенче бер тенденция күзәтелә – кешеләр кулланучылыктан китеп, шәһәрдә булудан, бер-берсе белән аралашудан тәм таба башлады. Күз алдында сценарийлар һәм «көч урыннары»ның форматы үзгәрә, – дип сөйли Мәскәү архитекторлары берлегенең махсус проектлар менеджеры Елена Петухова.

Чыннан да, бүген җәмәгать урыннарының төп кыйммәте анда килгән кешеләргә үзләрен реализацияләү мөмкинлекләре белән билгеләнә, дип саный ARTPLAY Дизайн үзәге җитәкчесе, Россиядә креатив кластерга нигез салучыларның берсе Сергей Десятов. Моның ачык мисалы – Мәскәүнең элекке «Плутон» заводы территориясендә урнашкан дизайнерлар, архитекторлар һәм проект төзүчеләр өчен булдырылган һөнәри мохит.

Шулай туры килә, Беренче яшьләр архитектурасы биенналесы вакытында Казан архитектура-төзелеш университетына Фабио Панцери лекция белән килә. Италиянең билгеле архитекторы шәһәрләрнең регенерациясе тарафдары буларак танылган. Ул ташландык биналарга, заводларга һәм фабрикаларга яңадан җан өрә. Мин аннан бүгенге көннән нәрсәне киләчәк архитектурасы карлыгачы дип була, дип сорадым.

– Минемчә, биналарны файдалануда һәм билгеләнешендә сыгылмалылык барлыкка киләчәк, ягъни алар кешенең ихтыяҗларына бәйле үзгәрешләр кичерәчәк, – диган иде ул. – Минемчә, сыгылмалылык – киләчәк архитектурасын характерлый торган бер билге, һәм ул иң якын арада күренә башлаячак.

Күрәсең, вакыты җитте.



Җәмәгать урыннары буенча утыз проект – биеннале финалистлары архитектура җәмәгатьчелегендә, шулай республика җитәкчелегендә һәм территория хуҗаларында кызыксыну уятты.

ЙОРТ УҢАЙЛЫГЫНА ИНВЕСТИЦИЯЛӘР

2019 елда Төркиянең Kastamonu компаниясе ярты гасырлык юбилеен билгеләп үтә. Аның бер заводы «Алабуга» МИЗ территориясендә урнашкан. Kastamonu Россия генераль директоры Али Кылыч «Татарстан»га инвесторларның республикабызны ни өчен югары бәяләве, яратуы, сыйфатны яхшырту һәрвакыт өстәмә чыгымнар таләп итмәве һәм бу сезонда ламинатның нинди төсе модада булуы турында сөйләде.

– Бүген компаниягез Россия һәм халыкара базарларда нинди урын били?

– Kastamonu Европада агач эшкәртү тармагының иң эре компанияләре арасында беренче бишлеккә керә һәм, идән өслекләре базарының ламинат сегментында 20% ны алып, бу юнәлештә иң алда бара. Бүген заводның җитештерү куәте елына 1,05 млн кубометр МДФ плитәсен һәм 35 млн квадрат метр ламинатны тәшкил итә. Kastamonu брендын Россиядә беләләр һәм яраталар. Мәсәлән, Мәскәүдә Kastamonu продукциясе «Level Павелецкая» бизнес-апартаментлары төзелешендә дә, 2017 елдан бирле эшләп килгән торакларны реновацияләү программасы объектларында да кулланылды.

– Мондый популярлыкның сере нәрсәдә?

– Алар күп. Иң мөһиме, мөгаен, һәрвакыт сыйфатны яхшырту юнәлешендә эшләвебездәдер. Мәсәлән, Kastamonu заводында Quality Control Circles («Сыйфат контроле төркемнәре») программасы гамәлдә. Хезмәткәрләр үз участокларындагы бурычларны хәл итү өчен командаларга берләшә. Бу бурычлар продукциянең сыйфатын күтәрүгә һәм үзкыйммәтен киметүгә, теге яки бу операцияләрне үтәү вакытын кыскартуга, сәнәгать иминлеге һәм хезмәтне саклау өлкәсендәге куркынычларны киметүгә, экология һәм кеше сәламәтлегенә йогынтыны азайтуга һ.б. юнәлгән булырга мөмкин. Командалар җитештерүнең теге яки бу өлешен оптимальләштерү буенча тәкъдимнәре булган проектлар әзерли, аларның күбесе соңыннан заводта кулланышка кертелә һәм чын файда китерә. Моннан тыш, без Россия һәм дөнья базарларында тенденцияләрне күзәтеп барабыз һәм, төрле сегмент кулланучысының барлык теләкләрен исәпкә алып, продукция төсләре, бизәкләре линейкасын киңәйтү юнәлешендә ашыгыч чаралар күрәбез. Шунысын да искә алыйк: сыйфатны яхшырту һәрвакыт өстәмә инвестицияләр таләп итә дигән сүз түгел: кайбер очракларда инде булган технологияләрне яңадан карап чыгып, бераз төзәтеп җибәрү дә җитә.

– Алабуга янындагы завод – Kastamonu компаниясенең эре җитештерү учагы. Ни өчен нәкъ менә Татарстан сайланды?

– Моңа республиканың махсус икътисадый зонасы булуы йогынты ясады. МИЗ форматы хосусый-дәүләт партнерлыгы проектларын гамәлгә ашыру өчен аеруча нәтиҗәле, чөнки монда резидентлар өчен сыгылмалы салым системасы эшли (аерым алганда, табышка салым, җир салымы һ.б.), дәүләт инвестицияләре хисабына эш өчен кирәкле инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы булдырылган. Моннан тыш, резидентларга күп кенә мәсьәләләр буенча – кадрлар сайлаудан алып, хакимият органнары белән хезмәттәшлек итүгә кадәр – булышлык күрсәтелә. Без Россия, Татарстан Республикасы хөкүмәтләреннән һәм җирле муниципаль дәрәҗәдә дәүләт ярдәме алабыз. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов аеруча кайгыртучанлык күрсәтә. «Алабуга» МИЗ җитәкчелеге дә шактый булыша. МИЗнең тагын бер өстенлеге – продукцияне төяп җибәргәндә, таможня процедуралары гадиләштерелгән тәртиптә һәм бердәм тәрәзә режимында гамәлгә ашырыла. Гамәли өстенлекләрдән тыш, Татарстан һәм Төркия халыкларының якынлыгы, мәдәни-тарихи уртаклыгы да безнең сайлау нәтиҗәсенә зур йогынты ясады.

– Сезнең карашка, республиканың көндәшлектә башка өстенлекләре бармы?

– Мин географик яктан уңайлы урынны, чималның якынлыгын һәм яхшы үсеш алган логистиканы телгә алыр идем, болар исә әзер продукцияне Европага, Азиягә, шулай ук ерак чит илләргә җибәрергә мөмкинлек бирә. Аннары – эшче кадрлар чыганагы булган зур шәһәрләрнең якынлыгы. Һәм, әлбәттә, Татарстанда югары һәм урта уку йортлары булу мөһим фактор санала, алар төрле һөнәрләр буенча квалификацияле кадрларны, шул исәптән агач эшкәртү өлкәсе өчен профильле белгечләрне җитәрлек күләмдә чыгара.

– Соңгы дүрт елда завод хезмәткәрләре республиканың урман хуҗалыклары территорияләрендә 1500 гә якын үсенте утыртты. Бу берәр төрле экспериментмы, әллә башка нәрсәме?

– Бу – компаниябезнең экологик сәясәт чараларының берсе. Kastamonu чимал белән тәэмин итүчеләрне һәрдаим күз уңында тота, аларны экологик сертифика-

Реклама Фотолар Kastamonu компаниясеннән алынды



ция узу эшендә активрак булырга чакыра. Татарстанның завод өчен агач китерүче урман хуҗалыклары FSC[1] сертификатларына ия, ягъни алар агач әзерләү белән беррәттән киселгәннән күбрәк күләмдә урман торгызу белән шөгыльләнә. Шулай ук PEFC[2] сертификатлары да бар, ягъни агач продуктларының сертификацияләнгән урманнардан булуын гарантияләүләр дигән сүз. Шул рәвешле без Татарстанда агач чималы әзерләүчеләрнең FSC һәм PEFC сертификация узу эшен активлаштырабыз.

– Ламинат сайлаганда кулланучылар бүген иң әүвәл нәрсәгә игътибар итә?

– Хәзерге тренд – продукциянең бактериягә каршы торучанлыгы, дымлылыкка чыдамлыгы һәм экологик яктан чиста булуы. Биредә Kastamonu ширкәтенең бизнес-партнёрларга һәм кулланучыга тәкъдим итәр нәрсәсе күп. Floorpan[3], Artfloor[4] һәм Sunfloor[5] сәүдә маркалы ламинат бактериягә каршы торучанлык сертификатына ия. Бу сыйфат Дрездендагы (Германия) EPH Success by Quality[6] лабораториясендә һәм Казандагы Гигиена һәм эпидемиология үзәгендә идән өслекләрен ISO 22196:2011 стандартына туры килү-килмәүгә тест үткәрү нәтиҗәсендә расланган. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, Kastamonu җитештерә торган идән өслекләре бактерияләргә каршы тору сыйфатына ия. Дымлылыкка чыдамлык мәсьәләсенә килгәндә, без продукциябезне даими рәвештә камилләштерәбез. Соңгы тест нәтиҗәләре күрсәткәнчә, T-тоташтыру нокталарында безнең ламинат 1 сәгатьтән соң 0% бүртә, 24 сәгатьтән соң бүртү 1,5% тан да артмый. Мондый күрсәткечләр сыйфатлы тоташтыру йозагы ярдәмендә тәэмин ителә. Kastamonu материалларының экологик чисталыгына предприятиедәге катгый җитештерү нормалары, даими сыйфат контроле, шулай ук җитештерү процессының тышкы аудиты хисабына ирешелә.

– Интерьердагы модалы агым-үзгәрешләр ничек тәэсир итә?

– PANTONE институты мәгълүматлары буенча, 2019 елның рәсми төсе[7] дип Living Coral[8] PANTONE® 16–1546 номерлы коралл төсе танылган – «җете, әмма йомшак» төсмер. Күп кенә дизайнерлар аны «җанландырып җибәрү» үзенчәлеген билгеләп үтә: ул җылынаклык та бирә, пространствоны «оптимизм» белән дә тулыландыра, хәтта йокыдан уянырга да булыша. Безнең компания коралл төсмеренә бик туры килә торган ламинацияләнгән «Ачык Нарат Лагерта» («Сосна Лагерта Светлая») идән өслекләре тәкъдим итә.

– Хәзер яңа продукция ясаганда, Kastamonu нәрсәгә йөз тота?

– Мөһим максатларыбызның берсе – формальдегид эмиссиясе түбән булган плитәләр җитештерү. Без дөньядагы тенденцияләрне күзәтеп торабыз. Мәсәлән, Германия законнарына 2020 елдан үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә, яңа стандартларга туры килү өчен, хәзер без формальдегид эмиссиясен минималь дәрәҗәләргә кадәр киметү юнәлешендә берничә төрле чара күрәбез. Моннан тыш, без инде хәзер товарның яңа төрләре – ут һәм суга чыдам МДФ плитәләр турында да сүз алып бара алабыз. Сынаулар уңышлы уздырылды, хәзер Россиядә әлеге продукцияне сертификацияләү процедурасын узабыз, шулай ук барлык халыкара стандартлар буенча Европада сертификат алырга планлаштырабыз.

– Соңгы вакытта компания тормышында булган нинди вакыйгаларны, сезнеңчә, аеруча мөһим дип билгеләргә мөмкин?

– Мин Kastamonu компаниясендә 16 ел эшлим. Шәхси фикерем шул: бу вакыт эчендә шактый күп әһәмиятле вакыйгалар булды. Шуларның берсе – Румыниядә җитештерү эшен ачып җибәрүгә инвестицияләр. Моңа кадәр Европа кыйтгасының бер генә илендә дә ишек өстышламасы кебек товар җитештермәгәннәр (аларны, нигездә, Америкадан кайтарганнар). Россиягә инвестицияләрне Kastamonu компаниясе тарихында тагын бер мөһим вакыйга дип саныйм. «Алабуга» МИЗнда завод эшли башлаганнан соң, биш ел эчендә Kastamonu Россиядә югары технологияле җитештерүне үстерә һәм базарда сорау зур булган, сыйфатлы продукция чыгаруны тәэмин итә торган ышанычлы партнёр һәм җаваплы эш бирүче статусын ныгытты. Безнең барлык казанышларыбыз – коллективның җаваплы хезмәте нәтиҗәсе. Бу вакыт эчендә без куелган максатны күреп, аңа ышанычлы адымнар белән бара торган бердәм, нык команда һәм тату гаиләгә әйләндек.

[1] ЭфЭсСи. [2] ПиИЭфСи. [3] Флопэн. [4] Артфло. [5] Санфло. [6] ИПиЭйч Сакссес бай Кволити. [7] Тренд сораштырулар үткәрә торган тикшеренү үзәкләре, шулай ук яңа материаллар барлыкка килүгә йөз тоткан кино, шоу-бизнес, мода тенденцияләре тарафыннан билгеләнә. — **Ред. иск.** [8] Ливинг Корал.

БАШКАЛАБЫЗ **КӨЗГЕСЕ**

Татарстан башкаласында октябрьдә үткән World Urban Parks-2019 Бөтендөнья парклар конгрессында Казанның Аккош күле урман-паркы халыкара International Large Urban Parks Awards* премиясенең Eurasian Park Awards номинациясендә бүләкләнде. Әлеге абруйлы бүләкнең ни өчен тапшырылганын аңлар өчен, без дә күлгә юл тоттык.**

* International Large Urban Parks Awards – Халыкара зур калалар парклары премиясе
** Eurasian Park Awards – Евразия парклары премиясе



Трассадан диярлек үк башланган агач такта түшәлгән юл күл ярлары буйлап бормалана-бормалана бара. Биредән Зур Аккош күленә гаҗәеп манзара ачыла: гаять зур су көзгесе ак комлы ярлар, яшел ылыслы чыршылар, нарат антенналары белән уратып алынган. Без килеп җиткәндә кояш байый иде, тик шунысы гаҗәпләндерде: салкын ноябрь кичендә дә күл буенда кеше шактый иде. Һава сулап йөрүче пенсионерларны, кирәк-ярагын күтәргән балыкчыны, кечкенә маэмае белән йөрүче егетне, скандинав йөреше өчен таякларын кыстырып китеп баручы әбине очраттык. Сабыйлары коляскада йоклап яткан арада ике яшь әни күл буенда ук фотосессия үткәреп маташа. Без узган җәйдә су коенган урыныбызны эзләп таптык. Ул вакыттан бирле биредә агач такта түшәлгән сукмак һәм аның буеннан буена урнаштырылган яктырткычлар пәйда булган. Суык һәм эңгер-меңгер битне һәм бармакларны чеметкәли башлый, һәм без кайту юлына борылдык. Әлбәттә инде, кабат әйләнеп килү теләге белән.

ИКЕ ТАПКЫР ЮККА ЧЫККАН СУ

Чынлыкта исә бу – Аккош күлләрен төзекләндерү, торгызу буенча зур проектның соңгы штрихлары гына. Кайчандыр шәһәребез әлеге могҗизалы табигать бүләгеннән колак каккан, хәзер исә күп көч куеп кире кайтара.

Без Аккош күле дип атаган объект чынлыкта бер-берсе белән тоташкан дүрт күлдән торган система ул. Кече, Зур, Якты һәм Коры Аккош күлләре – Казанның Киров районы территориясендәге 3,2 мең гектар мәйданны билгән шәһәр урман-паркының бер өлеше. Сулыклар чагыштырмача яшь, аларга әле нибары 200 әр яшь чамасы гына. Урман сызалары һәм чокырлары буйлап сулык касәләренә агып төшә торган кар сулары күлләрне туендыруның төп чыганагы була. XX гасырның 70 нче елларында тирәюньдәге төзелеш ландшафтны үзгәртә, һәм күлләр табигый туену чыганагыннан мәхрүм кала. 90 нчы еллар уртасына Кече Аккош күле – яртылаш, Зур Аккош күленең – өчтән бер, Коры Аккош күленең өчтән дүрт өлеше кибә. Су көзгеләренең гомуми мәйданы ике тапкырдан артыгракка кими. Коры Аккош күле исә бөтенләй сазлыкка әйләнә.

Шул вакытта ук шәһәр күлләрдәге су күләмен тулыландырырга омтылып карый һәм Юдино карьерында барлыкка килгән яңа Зөбәрҗәт күл суын Аккош күленә агыза. Яңа система 2000 нче еллар башына кадәр генә эшли. Әмма бу вакыт эчендә карьер суының составы, яхшы булса да, Аккош күлләре өчен табигый судан аерылганга, аларның флора һәм фаунасы составын үзгәртә. Зөбәрҗәт күлдән

Автор:
Ксения Сёмина

Автор фотолары

су агызуны туктаткач, сулыклар кабат саега.

2016 елда ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов карары белән Аккош күлләре Татарстан парклар һәм скверларны үстерү программасы объектлары исемлегенә кертелә. «ТАИФ» КТ һәм «Казан Оргсинтез» ГАҖ финанслауның шактый өлешен үзләренә ала, проектка эксперт-экологлар, «Татмелиорация» белгечләре, профильле министрлык һәм ведомстволар кушыла. Әмма хәтта башкаручыларның шундый җитди составы өчен дә бурыч шактый катлаулы булып чыга.

– Күлләр арасында урман үскән, флора һәм фауна тулысынча үзгәргән. Урман үзе чирле, Коры Аккош күлен тулысынча диярлек агач-куаклар каплаган. Авыру агачларны сакларгамы-юкмы, касәләрне ничек су белән тутырырга? Моның өчен күләмле тикшеренү үткәрү таләп ителде, – дип сөйли проект авторы, «Архитектура десанты» бюросы җитәкчесе Лилия Гыйззәтова. Экологлар, гидрологлар һәм башка белгечләр белән бергә проект ясаучылар эш планын төзи. Күлләрне киптерергә һәм Зөбәрҗәт күлгә яңадан тоташтыру хисабына су белән тутырырга булалар. Әмма Аккош күле үзен коткаручыларга яңа проблема әзерләп куя.

СУ КОЕНУ ТЫЕЛМЫЙ!

– Без күлләрнең төбендә су үткәрми торган балчык – линза булыр, дип фаразлаган идек. Әмма экологлар балчыкның булмавын, аның тулысынча эшкәртелеп бетүен ачыклады, – ди Лилия Гыйззәтова. – Шунлыктан күлләрне уртача дүртәр метрга тирәнәйтергә һәм яңа гидроизоляция катламы ясарга туры килде.

Су төбендәге туфрак белән дә мәшәкатьләнәләр: аны башта өскә чыгаралар, касәләрдә эш тәмамлангач, туфракта сакланган тере организмнар хисабына сулыкларның биогеоценозын торгызу өчен кире җәяләр.

Реконструкция 2018 елда тәгәлләнә. Шәһәр халкы моңа рәхәтләнә инде – җәен Аккош күлләрендә алма төшәрлек тә урын булмый. Биредә су коену рәсми рәвештә рөхсәт ителгән.

– Кешеләр безгә паркта су коену урыннарының һәрвакыт булуы турында язды, шунлыктан без аларны торгызуны үзебезгә максат итеп куйдык, – дип сөйли Лилия Гыйззәтова. Проектның төп нәтиҗәсе – Аккош күлләренә 29 гектарлы су мәйданнарын кире кайтару. Татарстан Президенты ярдәмчесе Наталия Фишман әйтүенчә, Россиядә бу әле беренче шундый очрак, моңа кадәр беркемнең дә моны эшләү хәленнән килмәгән.

Хәзер паркта пикник өчен зоналар төзекләндерелә, бәдрәфләр, эскәмияләр, кием алыштыру кабинкалары куела, стритфуд өчен павильоннар төзелә. Тик реконструкция проекты халыкара премиягә лаек булган Аккош күле нибары су коену һәм кояшта кызыну урыны гына булып калырмыни?

Бер караганда, әллә нәрсәләр оештырып булыр төсле. Биредә –



Фото ТР Җәмәгать урыннарын үстерү программасының матбугат хезмәтеннән алынды (Даниил Шведов)



скай-парк, янәшәдә генә – спорт снарядлары һәм мәйданчыклары комплексы... Әмма эш шунда: бу урман-парк аеруча саклана торган табигать территориясе категориясенә карый, димәк, биредә тарихи ландшафтка зыян китерү, ауга чыгу, чәчәк һәм теләсә нинди үсемлек җыю, йорт хайваннары белән йөрү (махсус билгеләнгән урыннардан тыш), учак ягу тыела... Бер яктан, бу закон тарафыннан тыелган актив ял итүне оештыру өчен каршылык. Территориянең бер өлешенең аеруча саклана торган статусын үзгәртү мәсьәләсен хакимият берничә ел рәттән күтәреп караган, әмма эшне азагына җиткермәгән. Икенче яктан караганда, аеруча саклана торган табигать территориясе статусы аннан файдаланучыларга бүген безгә чыннан да җитешмәгән технологияләр – кешенең табигать белән адекват аралашуы технологияләрен булдыру мөмкинлеген бирә. Әлеге аралашу ике як өчен дә файдалы булырга тиеш.

ЯШЬ НАТУРАЛИСТЛАР СУКМАГЫ

– Швециядә конституциягә табигать хокукларын кертергә тәкъдим итәләр. Төрләрнең сәяси тормышта да үз урыны бар. Без – тере дөньяның бер өлеше, башкалар һәлак булса, без дә һәлак булачакбыз. Безгә «эгодан» «экога» күчәргә кирәк, – дип белдерде World Urban Parks – 2019 Бөтендөнья парклар конгрессы спикеры, архитектор, урбанист, мөгаллим, Ага Хан Премиясенең оештыру комитеты әгъзасы **Анна Грихтинг**. Форумда ул шәһәр һәм яшел зоналар симбиозының иң шәп үрнәкләре турында сөйләде: мәсәлән, БМОның Европа бүлеге штаб-квартирасы – Милләтләр сараен әйләндереп алган «Ариана» паркындагы чирәмлектә сарыклар утлап йөри, аллеяләрендә тәвә кошлары, төлкеләр һәм җирле фаунаның башка вәкилләре сәйран кыла; Катардагы университет кампусы территориясендә «ризык урманы» булдырылган һәм ел әйләнәсе җиләк-җимеш, яшелчә үстерелә, алар җирле

органик калдыкларны эшкәртү нәтиҗәсендә табылган су белән сугарыла.

Әлбәттә, әлеге проектларны Аккош күле территориясендә тормышка ашыру мөмкин түгел, әмма яшел территорияләрне файдалануга шулай якын килүне үрнәк итеп алып була.

– Паркта күлләр белән тыгыз бәйләнештә булган борынгы агачлар үсә, биредә экосистема һәм биотөрлелек бар. Әлеге күренешләр белән танышу бик кызык. Шуңа күрә «Аккош күле» мөһим белем бирү ролен башкарырга да мөмкин. Парк кешеләр һәм табигать арасында тигезлекне эзләү юлында экспериментлар һәм үсеш өчен яхшы лаборатория була алыр иде, – дип сөйләде Анна Грихтинг.

– Аккош күле – шәһәр халкын тәрбияләү, аларны табигать территориясендә үзләрен адекват тотарга өйрәтүгә булышу өчен идеаль урын. СССРда искиткеч практикалар булган бит, бүген алар юкка чыккан. Мәсәлән, яшь натуралистлар түгәрәкләре. Ботаника, кошларны күзәтү, экология нигезләрен өйрәнү – бу программаларны парк территориясендә рәхәтләнеп тормышка ашырып була. Төрле маршрутлар салырга, алар буенча экскурсияләр оештырырга, – ди гамәли урбанистика үзәкләре проектлары идеологы һәм оештыручысы **Святослав Мурунов**. – Мондый программаларны оештыруда шәһәрдәге төрле җәмгыятьләр – эт асраучылар, велосипедта йөрергә яратучылар, яшьләр, креатив класс – зур

роль уйный алыр иде. Әмма моның өчен күмәк карарлар кабул итү һәм район хакимиятләренә үз ихтыяҗларыңны төгәл җиткерү зарур. Казанның тарихи үзәген үстерү концепциясен эшләүдә катнашучы буларак мин, Татарстанның хакимият вәкилләре, халык, культурологлар, социологлар һәм архитекторлар катнашында мондый конструктив диалог алып бару тәҗрибәсе бар, дип әйтә алам. Республикада парклар саны бик күп, шунлыктан «кайда» соравыннан «нәрсә эшләргә» соравына күчәргә вакыт җитте.

– Әгәр әйләнә-тирәгә күз салсак, «территорияләрне актив файдалануның» бүген әле тулысынча үтәлмәвен күрербез. Сәбәбе өлешчә шунда: соңгы вакытта мегаполисларда социаль проектлаштыру институтлары шөгыльләнергә тиешле күп нәрсә архитекторлык проектларына бирелә. Ә бит социолог, эколог, психолог, антропологны – кыскасы, конкрет территориядә социум ихтыяҗларын чыннан да ача алырлык белгечләрне архитектор белән алыштырып булмый, – дип саный Святослав Мурунов. – Архитектура һәм яшел мәйданнарның уртаклыгы аз, ул бүгенге шәһәр паркларын төзүнең глобаль процессы эчендә генә күп тоела. Аккош күле – Татарстан аеруча саклана торган табигать территориясе статуслы яшел территорияләр белән үзара хезмәттәшлекнең принципиаль яңа механизмын үстерә алырлык урын ул. Россиядә моңа мисалларның бармак белән генә санарлык булуын исәпкә алганда, практика бик әһәмиятле, файдалы булырга мөмкин.

Фото: creativewomen.co

Фото: vk.com/swqter

Реклама 16+

ИГОРЬ ПРИВАЛОВ: «БЕЛЕМ БИРҮ ӨЗЛЕКСЕЗ БУЛЫРГА ТИЕШ»

«Без көндәшлеккә сәләтле булырга тиеш... Ә көндәшлеккә сәләтлелекне югары дәрәҗәдә тотар өчен, кешеләр кирәк», – дигән фикердә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов. Кеше капиталы – 2030 елга кадәрге республика стратегиясенең төп өлеше. КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе, Татарстанда дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр бу капиталны туплау һәм арттыру процессында актив катнашучылар булсын өчен, барысын да эшли.

Автор:
Ксения Сёмина

Республикада дәүләт хезмәтенең нәтиҗәлелеге күп очракта аның вәкилләре белән дәүләт хезмәтләренең төп заказчысы булып торган халык арасында үзара элемтә, багланышның ни дәрәҗәдә яхшы оештырылуына бәйле. Моннан тыш, хәзерге вакытта дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә арасындагы багланышлар сыйфатын арттыру мәсьәләсе федераль дәрәҗәдә хәл ителә. Россия Президенты Владимир Путин илнең Премьер-министры Дмитрий Медведев белән октябрь аенда Кремльдә узган очрашуда хакимиятнең әлеге баскычлары арасында даими рәвештә өзеклекләр килеп чыгуын билгеләп үтте. «Безгә бу хезмәттәшлекне, элемтәне һичшиксез җайга салырга кирәк», – диде Владимир Путин.

Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбенең максаты – республика түрәләренең шәхси эш нәтиҗәлелеген, ә нәтиҗәдә – тулаем республикада дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәлелеген арттыруга актив ярдәм итү. Шуңа күрә уку планнарын төзегәндә, мәктәп, беренче чиратта, көн тәртибендәге мәсьәләләргә йөз тота.

УРЫННАРДАГЫ ЭШ ӨЧЕН

– Курсларда без практик мисаллар нигезендә көн кадагындагы бик күп темаларны кыскартылган рәвештә күздән кичердек. Безне тикшерергә килә торган, бездән хисаплар җибәрелә торган дәүләт органнары вәкилләреннән турыдан-туры киңәшләр алу мөмкинлеге бик файдалы булды, – дип сөйли «Авыл җирлеге башлыклары эшчәнлегенең актуаль мәсьәләләре» курсы тыңлаучысы, Татарстанның Чирмешән районы Кармыш авыл җирлеге башлыгы Илдар Фәсхетдинов.

Курс җитәкчеләргә «урыннарда» үз эшләрен оптимальләштерергә, шулай ук юридик, финанс, норматив-хокукый актлар әзерләү, идарә итү һәм башка өлкәләрдә белем багажын тулыландырырга мөмкинлек бирә торган корал рәвешендә оештырылган. 2019 елда аны 300 кеше узды. Ә соңгы биш елда 1500 авыл җирлеге башлыгы белем алды.

– Программа республиканың барлык авыл җирлеге башлыкларын диярлек колачлый. Әмма өйрәнер темалар күп, ә бу төр категория муниципаль хезмәткәрләрнең составы вакыт-вакыт үзгәреп тора. Шуңа күрә, программаны яңартып, тулыландырып, киләсе елда да дәвам итәчәкбез, – ди Югары мәктәп директоры Игорь Привалов. – Без авыл җирлекләре секретарьларын укытырга керешергә дә теләр идек, чөнки авылдагы хакимият эшенең шактый өлеше – документлар әйләнешен алып бару, халык белән хезмәттәшлек һәм башка бик күп мәсьәләләр шулар җилкәсенә төшә.

МИНИСТРЛЫКТА КУНАКТА

Җирле үзидарә органнары белән дәүләт хакимиятенең башкарма органнары арасында багланышларның тизлеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру өчен, Татарстанда үтәли стажировкалар программасы эшли башлады. Муниципаль хезмәткәрләр берничә көн дәвамында тегe яки бу ведомствода стажировка мәйданчыгында булып, предметны теоретик һәм гамәли яктан өйрәнәләр, ә аннары күнекмә-тәҗрибәләрне үз эш урынында тормышка ашыралар. Программа эшли башлаганнан бирле, аның нигезендә 100 дән артык хезмәткәр белем алды. Остазлар ролендә Татарстанның Финанс, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык, Икътисад, Юстиция министрлыклары, Тарифлар комитеты, Казан, Баулы, Яшел Үзән, Әлмәт, Алабуга, Питрәч башкарма комитетлары хезмәткәрләре чыгыш ясады. 2019 елның 9 аенда гына да 55 кеше стажировка үтте.

– Программаның максаты – муниципаль юристларның, кадрлар буенча белгечләрнең, икътисадчыларның белем базасын яңарту һәм киңәйтү, аларның төрле ведомстволар белән багланышларын җайга салу. Программа шактый яңа, алга таба без стажировка мәйданчыклары исемлеген киңәйтергә ниятлибез. Моннан тыш, министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләренең муниципалитетларга

Фотолар КФУның Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбеннән алынды

җавап сәфәрләре оештырылачак, – ди Игорь Привалов.

КЕШЕЛӘРНЕ ҺӘМ МАКСАТЛАРНЫ БЕРЛӘШТЕРӘБЕЗ

2030 елга кадәр исәпләнгән республика стратегиясе нигезендә, киләчәктә Татарстанның алдынгылыгын һәм глобаль көндәшлелеккә сәләтлелеген кеше капиталы тәэмин итәчәк. 2019 елда Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе базасында Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы инициативасы белән старт алган «Территорияләрне стратегик үстерү» программасы тәмамланды. Анда муниципаль районнарның башкарма комитетлары җитәкчеләре урынбасарлары, шулай ук дәүләт хакимияте башкарма органнарының структур бүлекчәсе җитәкчеләре урынбасарлары һәм башлыклары белем туплады. Киләчәк позициясеннән чыгып, һәркем үз районының көчле һәм көчсез якларын бәяләргә, башка муниципалитетлар белән кисешү нокталарын эзләргә, уртак продукт, үзара файдалы инфраструктура яки җитештерү проекты булдыру өчен кластерлы берләшү шартларын тикшерергә мөмкинлек тапты.

Илнең беренче премьер-министры Ли Кван Ю үз китабында тәфсилләп сөйләгән Сингапур тәҗрибәсе күрсәткәнчә, кеше капиталы потенциалын инновацион эшчәнлек һәм сакчыл җитештерү принципларын кертү белән бергә гамәлгә ашыру, тышкы шартларга карамастан, теге яки бу территориядә алга киткән икътисад булдырырга мөмкинлек бирә.

ГРАЖДАНЛЫК ИНИЦИАТИВАЛАРЫНА ЯРДӘМ ИТҮ

Дөньякүләм тәҗрибәләрне гамәлгә кертү Татарстан өчен бик перспективалы булырга мөмкин, өстәвенә, республика үз идеяләрен дә уңышлы тормышка ашырып килә. Республикада территориаль иҗтимагый үзидарә институты кебек гражданнар һәм хакимият арасында бәйләнешне тәэмин итә торган орган уңышлы үсә бара. Территориаль иҗтимагый үзидарәләр саны республиканың эре шәһәрләрендә дә, авыл җирлекләрендә дә арта. Тик кайчагында аларның җитәкчеләренә квалификация яки белем җитми. Нәкъ менә шуңа күрә дә Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе һәм «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясе уртак белем бирү программасын гамәлгә ашырды.

– Без республика гражданнарының конструктив башлангычларына бик теләп ярдәм итәбез һәм территориаль иҗтимагый үзидарәләргә тагын да күбрәк бурычларны хәл итәргә булышабыз. Курсларда белем алучылар остазлары белән актив аралашты, алар кирәкле мәгълүматларны турыдан-туры беренче заттан алды, бер-берсе белән кыйммәтле тәҗрибә уртаклашты, мондый форма куллану бәрабәренә дәресләр бик нәтиҗәле үтте. Без бу программаның алдынгы тәҗрибәсен башка төбәкләр белән бик теләп уртаклашачакбыз, – ди Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе директоры урынбасары Наталья Аксенова.

ДӘҮЛӘТ – СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ

Дәүләт хезмәткәре статусы һәрчак аның иясенә зур җаваплылык йөкләгән, шактый авыр, еш кына фидакарь хезмәт таләп иткән һәм хәзер дә таләп итә.

– Бүгенге көндә күп кенә процесслар «цифрлы өлкә»гә күчерелгән, ә бу исә сигез сәгатьлек эш көне инде үткәндә калган, дәүләт хезмәткәрләре һәрчак «онлайн», мәгълүмат белән даими рәвештә эшли дигән сүз. Түрәләрнең, эре предприятие һәм компания хезмәткәрләре кебек үк, эш аркасында янып бетү синдромына дучар булуы гаҗәп тә түгел. Без мондый хәлне кисәтергә тырышабыз, эшне нәтиҗәле дә, динамикалы да, илһамландыра торган да итеп көйләргә булышабыз. Стресска чыдамлык, дәүләт хезмәте кыйммәтләренә тугрылык, мотивация, хезмәт культурасы – әлеге һөнәри сыйфатларны үстерүгә аерым игътибар бирәбез. Ә безнең тыңлаучыларыбыз даими үзгәрешләр сынавына әзер булсын өчен, белем бирү процессын өзлексезлек принцибыннан чыгып төзибез, – дип аңлата Игорь Привалов.

Югары мәктәптә материалны җиткерү форматы шулай ук үзгәреп тора. Дәресләрнең шактый өлеше практикум рәвешендә һәм бүген актуаль булган тренинглар формасында уза, аларда системалы, креатив фикерләү, эмоциональ интеллект, командада эшли белү һәм башка кирәкле күнекмәләр өйрәтелә. Тагын бер мөһим тренд – мәгълүмат әйләнешенең югары тизлеге, бигрәк тә социаль челтәрләрдә. Дәүләт хезмәткәре интернетның халык өчен ачык киңлек икәнлеген хәтердә тотарга тиеш, аның интернеттагы теләсә нинди фикере шәхси затныкы түгел, ә дәүләт вәкиленең сүзләре буларак бәяләнә.

Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе белгечләре, темалар сайлаганда, һөнәри үзенчәлек кысалары белән чикләнмичә, дәрес программаларын тулаем җәмгыятькә хас процессларны исәпкә алып төзиләр, чөнки мәктәптә белем алучылар, – беренче чиратта, әлеге җәмгыять гражданнары. Ә аларның хезмәте район, республика, ил күләмендә җәмгыятьнең иминлегенә саллы өлеш кертә.

2018 елда гына да Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбендә **1502** дәүләт гражданлык хезмәткәре һәм **2243** муниципаль хезмәткәр белем ала.

Соңгы биш елда **740** программа буенча курсларда **25** меңнән артык кеше, шул исәптән – Россия Федерациясендәге **30** субъектның дәүләт хезмәткәрләре дә белем туплый.

«УЛ ӘЛЕ ДӘ БЕЗНЕ ТӘРБИЯЛИ...»

Әни... Әнкәй... Адәм баласы өчен моннан да кадерле, күңел түрендәге иң нечкә кылларны тибрәтүче сүз бармы икән? Юктыр, мөгаен. Шуңа да әниләр турында сөйли башлаганда йөзләребез балкый, ә инде мәрхүм икән, күзләр яшьләнә...

Без традиция буенча ноябрь азагында зурлап Әниләр көнен билгеләп узабыз. Бик күркәм күренеш. Шул уңайдан күренекле шәхесләрнең әниләре турындагы истәлекләрен бирергә булдык.

«ӘТИ БЕЛӘН ӘНИ – БЕРБӨТЕН...»

Фәрит Мөхәммәтшин, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе:

– Мин әнине – әтидән, әтине әнидән башка күз алдына китерә алмыйм. Алар бербөтен булып яшәделәр, безне дә үз үрнәгендә шуңа өйрәтеп үстерделәр. Әтием – Хәйрулла Динкай улы, сугыш ветераны, фронтовик дусты Юныс Йосыпов өенә кайтып керә. Чөнки әнисе, улы сугышта чакта вафат булып, йорт бикләнә. Шунда аның балдызы Маһинур белән таныша. Яшьләр бер-берсен ошатып кавышалар.

Әти белән әни өч бала тәрбияләп үстерделәр. Без аларның матур, тату гомер итүләренә, үзара дустанә мөнәсәбәтләренә сокланып яшәдек. Әнием бик йомшак кеше иде. Безне тынычландырыр өчен: «Тавышланмагыз, әтиегез кайта!» – дип бер әйтүе җитә иде.

Мин хәзер шундый фикергә киләм: әнием Маһинур гомере буе әтинең гаиләдәге абруен күтәреп яшәгән. Хәер, бер әни генә түгел, ул чорларда күпчелек татар хатыннары ирне ир итеп яшәделәр, гаиләнең иминлеген, бөтенлеген сакладылар.

Берсендә, әти турында сөйләгәндә, әнием болай диде: «Ул бик рәхәт кеше иде. Бер генә тапкыр да ризасызлык күрсәтмәде, тавыш күтәргәне булмады. Пешергән ашымны һәрчак мактап ашады. Эштән елмаеп кайтып керүгә, балалар сырып ала үзен. Берәү булса: «Китегез әле, мин ашамаган да әле», – дияр. Ә ул иң элек: «Әниегез кайда?» – дип сорар иде. Минем аш-су өендә икәнлегемне белгәч, чишенеп ташлый да балалар белән уйнарга тотына. Белмим, каян шундый әйбәт кеше булгандыр...»

Әти командировкаларга, партия укуларына киткәндә, әни белән хат алыша торган була. Кадерле кешеләремнең бер-берсенә язган хатларын бүген дә кайта-кайта укыйм. Андагы наз, ихласлык, йөрәк җылысы күңелне алгысытып, матур хатирәләргә алып кайта. Әти хатларында «Маһинурым-күз нурым» дип яза, ә әни аны «Хәйруллам» дип йөртте. Еш кына әти әнигә яратып «карчыгым» дип эндәште. Үз эченә күпме җылылык сыйдырган шушы сүз безнең гаиләгә дә үтеп керде, хәләл җефетем Луизага да вакыт-вакыт «карчыгым» дип эндәшәм.

Әтием белән әнием 55 ел буе яратышып гомер иттеләр. Әтинең вафатыннан соң әни ялгыз яшәде. Күпме генә үзебезгә яшәргә чакырсак та, бер баласына да бармады, үз фатирында тыйнак кына гомер итте. Әлмәттә әти белән яшәгән фатирга бер яңа әйбер дә керттермәде, соңгы көннәренә кадәр гаилә учагын элек ничек булган, шулай саклап яшәде.

Марсель Галиевнең «Су буеннан әнкәй кайтып килә» җырын тыңлаганда мин көянтә-чиләк белән судан кайтып килүче әниемне, аңа чордаш апаларны күз алдыма китерәм. Без яшәгән Акташ авылы чишмәләре дә яр астында иде, көн саен ничәшәр көянтә су китерде икән әниебез...



Автор:
Руфия Фазылова

Иллюстрация: Х.Якупов, «Ана портреты»



«КОЕНЫ ЯҢАРТТЫМ...»

Рәдиф Гаташ, Татарстанның халык шагыйре:

– Әниләр турында сүз чыккач, менә тагын мең хатирә яңарып, күңелдә шатлык, үкенеч хисләре уянды... Әйе, һәр кеше өчен үз әнисе – иң яхшысы, иң изгесе. Ә безнеке шулар арасыннан да иң-иңе кебек тоела. Моны мин генә әйтмим. Туган нигезгә язучы, шагыйрь дусларымның да кайтканы булды. Алар да: «Әниеңдә гаҗәеп бер нур бар, нечкә күңелле», – дияләр иде.

Әнием Сәвия гомере буе Башкортостанның Кушнаренко районы Марс авылында яшәде. Безне, өч улын, ялгызы тәрбияләп үстерде ул. Кызганычка каршы, әтиебез Бөек Ватан сугышыннан әйләнеп кайтмады. Әни тормыш авырлыкларын үз җилкәсендә күтәрде. Иң хикмәтлесе – бөтен йөкне үзе тартса да, әни безне укудан аермады. Авыр эшкә чыгарып җибәрмәде. Ике игезәк абыем – Рәшит белән Рәфитне әдәбият тәэсирендә тәрбияләде. Район үзәгенә кайта торган һәр китапны алып, ярыша-ярыша укый идек. Ашарга ризык, кияргә кием булмаса да, без ул вакытта рухи байлыкка кинәндек. Абыем Рәшит тә шагыйрь иде...

Әнкәй арабыздан киткәнгә утыз биш ел инде. Ә мин әле дә ятимлек ачысын тоям. Әниләрдән дә якын кеше була алмый, моңа яши-яши тагын мең кат инанасың. Юкка гына «җәннәт әниләрнең аяк астында», димиләр бит. Бүген мин япа-ялгыз. Әни, ике абыем да дөньяда юк. Бердәнбер улыбызны да югалттык... Тормыш иптәшем дә алтынчы ел инде урын өстендә. Соңгы вакытта истәлекләр белән генә яшим, дисәм дә була. Аларның иң күбесе әни турында. Эх, исән булса, хәзер әллә нинди җылы сүзләр әйтер идем, әллә ниләр эшләр идем кебек... Исән чагында әйтеп бетермәдем, ахрысы, дип тә борчылам...

Быел туган якка кайта алмадым. Узган ел дуслар белән кайтып, туган нигез янындагы коены төзекләндердек. Авылдашлар аны әни истәлеге итеп, «Сәвия апа коесы» дип йөртә. Менә шуңа нык сөенәм, әни алдында бер эш эшләдем кебек. Зират коймаларын да яңарттым. Без хәзер алар өчен башка нәрсә эшли алмыйбыз – каберләренә зыярәт кылып, хәердогада булып торсак кына...

«БЕЗ БИШ БАЛА ҮСТЕК... »

Роберт Миңнуллин, Татарстанның халык шагыйре:

– Без әнкәй тәрбиясендә үстек. Ул безгә әткәй тәрбиясен дә бирде, чөнки әткәй мин бишенче класста укыганда дөнья куйды.

Әнкәй безгә әби-бабай урынына да булды, чөнки үзе дә ятим үскән, ә әткәйнең әти-әнисенең, ягъни авылдагы әби-бабайның, әткәйдән башка да балалары, оныклары күп иде. Без аерым йортта аерым дөнья көттек.

Ул безгә укытучы да булды! Аңа педагоглык тумыштан бирелгән иде. Аның тәрбиясе, үгет-нәсихәтләре, тормыш дәресләре безне олы юлга алып чыкты. Инде олыгайгач, башлы-күзле булгач, үз дөньяларыбызны коргач та, ул безнең өчен остазыбыз булып калды. Нинди генә эшкә тотынсак та, нинди генә гамәлләр ниятләсәк тә, һәрчак аның белән киңәшләшә торган идек. Аның фатихасын алмыйча, бер генә эшебез дә эшләнмәгәндер, мөгаен.

Әнкәй безне акыллы, эшлекле, конкрет киңәшләр белән тәрбияләде. Гыйбрәтле мисаллар белән, үзенең тормыш тәҗрибәсе белән яшәргә, кешеләр белән аралашырга, акны карадан аерырга өйрәтте. Аның сөйләгәннәрен тыңлау, аның белән сөйләшеп утыру, хатларын уку – безнең өчен үзе кабатланмас тормыш сабаклары, тәрбия сәгатьләре булды. Андый дәресләрне беркайда да – мәктәпләрдә дә, вузларда да бирмиләр.

Аның алдан күрүчәнлеге, аналитик фикерләве, принципиальлеге безнең барыбызны да туры юлдан алып баргандыр, дип уйлыйм. Биш бала – биш төрле холык-фигыль, биш төрле гадәт-кыланмышлар, дигән сүз... Биш төрле максат-омтылыш, биш төрле үҗәтлек, биш төрле кирелек, биш төрле мавыгу... Шушыларның барысын да тоеп, белеп, күреп, бишесенә биш төрле юнәлеш, бишесенә биш төрле акыл биреп торырга кирәк! Безнең әнкәй нәкъ шулай эшләде дә...

Аның фани дөньядан киткәненә дә шактый еллар инде. Урыны җәннәттә булсын! Әмма безнең аны бер генә минутка да онытканыбыз юк. Ул әйткән сүзләр, гыйбарәләр, мәкальләр искә төшә, киңәшләре, догалары күңелдән китми... Аның җылы карашына, җылы сүзенә без әле һаман да мохтаҗбыз. Ул әле дә безне тәрбияләвен дәвам итә!

Әнкәй тәрбиясе... Ул игелекле тәрбия безнең йөзебезгә бервакытта да кызыллык китермәде!

«ЗӘВЫКЛЫЛЫК ЭТАЛОНЫ ИДЕ»

Наилә Гәрәева, Татарстанның халык артисты:

– Әниемнең исеме Ралан иде, әтисе азәрбайҗан милләтеннән булганга, шундый исем кушканнар.

Әни турында сөйләгәндә иң беренче аның зәвыклы булуына басым ясыйсым килә. Матурлыкны тоя, күрә белә торган гаҗәеп хатын-кыз иде ул.

Без өч баласын – ике кыз, бер улын – әни һәрвакыт матур киендерде. Күбрәк үзе тегә иде. Ә инде кием-салымны кибеттән сатып ала икән, аңа, һичшиксез, берәр матур деталь өсти. Брошь булсынмы, чигүме... Шул рәвешле безнең кием башкалардан аерылып торды. Казан театр училищесына кабул итү имтиханнарына барганда, әни миңа күлмәк тегеп бирде. Урындыкка бастырып, озак итеп үлчәм алганы бүгенгедәй хәтеремдә. Күлмәккә туры китереп туфли дә алып кайтты. Инде укырга кергәч: «Син актриса, һәрвакыт матур киенеп йөрергә тиеш!» – дип көн саен әйтә иде. Гаҗәп: нинди юклык. кытлык заманнарында да әллә нинди матур әйберләр таба иде ул. Әле берәүдә дә булмаган япон свитеры, француз туфлие... Әни күп еллар «Вузовец» кинотеатрында контролер булып эшләде. Ә ул вакытта киногa эләгү бик авыр иде. Ә әни билетлар табып бирә ала! Миңа шуңа күрә дә танышлары күп булган, дип уйлыйм.

Диндә булса да, әни алдынгы карашлы, яңалыкны алга сөрүче хатын-кыз иде. Әтиебез сугыштан кайткач вафат булды. Әлбәттә, әнигә өч бала белән җиңел булмагандыр. Ә безгә ул аны сиздермәде.

Безнең өйдә китаплар күп иде. Без шул китаплар белән тәрбияләндек. Һәм матур савыт-саба – монысы шулай ук әнинең зәвыклы мавыгуы булды. Әни аз ашый иде. «Матур савыттан ашасам, аз ризык белән дә тамагым туя», – диюе гел истә.

Сәнгатькә гашыйк кеше иде ул. Өчебезне дә музыка мәктәбендә укытты. Абыйны, мине скрипкага бирде, апам фортепиано сыйныфын тәмамлады. Миңа шуңа да матурлыкны, сәнгатьне тою, ярату бар бездә. Без боларның барысы өчен дә әниебезгә бурычлы. Тик ничек кенә тырышсам да, аның кебек була алмадым...

«КҮҢЕЛ ҺАМАН ЫШАНМЫЙ...»

Зөлфия Нигъмәтҗанова, Әлфия Авзалованың кызы:

– Әни безне ялгызы үстерде, әтием белән әле без кечкенә вакытта ук аерылышкан. Шуны әйтим: Әлфия Авзалова кызы булу безгә рәхәт тә, кыен да иде. Кая барма, без – һәрвакыт күз уңында. Алай гына да түгел, фамилиябез журналда исемлек башында тора бит, мәктәптә укытучылар көн саен диярлек дәрес сорады. Шуңа да һәрвакыт әзерләнеп йөрдек. Сынатмаска тырыштык. Әни гастрольләргә киткәндә, без әнинең якын туганы Закирә апа белән кала идек. Әни кайтуга дип бөтен җирне җыештыра идек, чөнки ул чисталыкны яратты. Һәр нәрсәне җиренә җиткерергә тырыштык – керләрне дә гел кайнатып юдык. Әни кайтып керүгә: «Кызлар, молодцы! Булдыргансыз!» – дисә, моннан да зур сөенеч юк иде. Аннан розетка өстендәге тузанны, бармагы белән сыпырып, безгә күрсәтә... Әнә шулай безне ул чисталыкка, пөхтәлеккә өйрәтте.

Мин шактый еллар әни белән гастрольләрдә йөрдем. Үзенә карата да, труппасына карата да бик таләпчән иде ул. Шуның белән бергә позитивлык та бар иде. Берәрсе кәефсезрәк булса, хәзер бер кызык сүз сөйләп ала, кәефне күтәрә.

1989 елда Ульяновск өлкәсе Иске Кулаткадан Уфага ике тәүлек салкын поездда бардык. Ашарга такы-токы. Шулай интегеп юлда килгәннән соң, безне Уфадан туры Учалыга алып киттеләр. Бер ял итмәгән килеш бит. Дөрес, самолет белән инде, шулай да кыяфәтебез бер дә кешегә күренә торган түгел иде. Учалыда әнине самолеттан бер төркем халык каршы алды. Әни, мәрхүмкәем, и оялды шул чагында. Ул тамашачысы алдына беркайчан да ясанмый, киенми чыкмады. «Артист кеше һәрвакыт гүзәл булырга тиеш», – дия иде. 1989 елгы шул сәфәрне картайган көндә дә искә ала иде.

Әнинең арабызда юклыгына һаман күңел ышанмый әле. Аның булмәсе үзе исән чагындагы кебек тора. Шунда көн дә керәм. Киемнәрен алып исним. Үзен күргәндәй булам...

Язып һәм 5 смартфонның берсен от!

Бүләкләр 2020 елның 19 февралендә уйнатылачак

2019 елның 30 декабренә кадәр «ТАТМЕДИА» АҖнең кимендә өч басмасына

1 ЯЗЫЛ

Язылу квитанцияләренә «Акция» билгесен куеп, копияләрен (телефон номерын язарга онытмагыз!) 420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2нче йорт яисә podpiska@tatmedia.ru адресына

2 ҖИБӘР

Биш смартфонның берсен, юрган һәм башка бүләкләр

3 ОТ

татмедиа

Акциянең үткәрелү вакыты, бүләкләр һәм аларны алу тәртибе турында тулырак tatmedia.ru сайтында. Акциянең үткәрелү вакыты 1. 11.2019-30.03.2020. Гаризалар 2020 елның 20 гыйнварына кадәр кабул ителә. Оештыручы - «ТАТМЕДИА» АҖ. Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Баш авыртуларының сәбәбе **КАЙДА** яшерелгән

Хрущевны Казанда тутырган тавык белән **КЕМ** сыйлаган

Татфакны **НИГӘ** саклап калып булмый иде...



ТАБИБ КУЛЫНДАГЫ **ГАЛӘМ**

Остеопатка күренергә бару кай ягы беләндер мистиканы хәтерләтергә мөмкин. Менә табиб кулын баш очыннан йөртә, бер мизгелгә туктап кала. Кулы белән умыртка баганасына «китә», бил турысын капшый… Ә аннан соң баш авыртуларының сәбәбе… оча сөягендә икәнлеген әйтә! Кешене болай карауның сере нидә соң? Әлеге сорауны без табиб-остеопат, медицина фәннәре докторы, Казан медицина академиясенең неврология һәм мануаль терапия кафедрасы профессоры Васил Зыятдиновка бирдек.

ТЫЛСЫМ ЮК

– Васил Билалович, кайчак классик медицина табиблары кыйммәтле тикшеренүләрдән башка төгәл диагноз куярга авырсыналар, ә остеопатның сандыгынданиләр бар?

– Иң беренче чиратта – куллар. Үзенең сизгер куллары ярдәмендә остеопат киеренкелек сизелгән урыннарны тоя, һәм мускул киеренкелеген генә түгел, фасциальне дә. Фасция – ул кешенең бөтен органнарын һәм мускулларын каплаган тоташтыргыч тукымалы тышча. Мәсәлән, оча, таз фасциясендәге киренкелекне башта, муенда сизәргә мөмкин. Һәм монда бернинди дә мистика юк. Остеопат дәвалавы – кеше гәүдәсенең биомеханикасы белән эшләү, ул идеаль дәрәҗәгә җиткерелеп өйрәнелгән анатомиягә нигезләнә.

Фото: Александр Ефремов

– Сүз уңаеннан, бик еш кына кешеләр остеопатияне рәсми медицинага каршы куялар. Шуңа күрә классик медицина табиблары баш тартканнан соң гына остеопатларга мөрәҗәгать итәләр.

– Чынлыкта остеопат – шул ук табиб. Россия стандартларына ярашлы рәвештә, ул мәҗбүри рәвештә медицина белеме алырга тиеш. Һәм инде шул белемнәренә остеопатия буенча белемнәрен дә өсти. Мануаль күнекмәләргә ия остеопат үзен классик медицина практикасы табибларына каршы куймыйча, берьюлы ике яссылыкта уйларга сәләтле. Остеопатка вакытында мөрәҗәгать итсәләр, ул организмдагы проблемалы зоналарны билгеләргә ярдәм итә, кирәк булганда тар белгечләргә җибәрә. Без һәрвакыт холистик, ягъни комплекслы якын килүгә таянып эш итәбез.

ЮЛ БАШЫ

Васил Зыятдинов беренче мәртәбә остеопатия тәэсирен моннан егерме еллап элек – Россиядә гомумән бу турыда бик сирәкләр генә ишетеп белгән вакытларда күрү бәхетенә ирешә. Бер очрак ярдәм итә. Васил Билалович ул чакта балалар шифаханәсендә баш табиб булып эшли. Пациентларны дәвалау һәм тернәкләндерү нәтиҗәләре, йомшак кына әйткәндә, аны канәгатьләндерми. Шуңа ул Казанга Балалар ортопедиясе фәнни-тикшеренү институты табибларын чакыра – алар тәҗрибәсен дә өйрәнү максатында.

Тулы бер команда килеп төшә. Шунда форсаттан файдаланып Зыятдинов болай дип сорый: «Мөдиребез икенче катта кушеткада ята, тора алмый!» Питердан килгән профессорның нинди алымнар кулланганын Васил Зыятдинов ул чакта аңлап өлгерми. Әмма унбиш минуттан ханым аягына баса һәм атлап китә. «Тылсымчы» үзенең серләре белән уртаклашырга җыенмый, шулай да Зыятдиновның янып торган күзләрен күргәч бирелә: «Остеопатия менә шулай эшли. Өйрәнәсең киләме?»

Инде берничә айдан Васил Зыятдинов Россия табибларының беренче төркеме составында Бөекбританиядә остеопатияне өйрәнә башлый.

– Укуның беренче айларында без гаҗәпләнеп бетә алмадык, аңлау шунда ук килмәде, – дип искә төшерә ул. – Англиядә остеопатия алга киткән. Ул, АКШта башланып, алга киткән күп илләрне яулый, шул исәптән Европаны, Канаданы... Анда квартал саен гаилә остеопатында тикшеренү узу норма санала. Аларның хәтта балалар туганнан соң ук даими күзәтеп торган остеопатлар да бар.

– Шуңа да карамастан, безнең илдә күпләр өчен остеопатия һаман да әле нииндидер серле әйбер булып кала бирә.

– Гади генә әйткәндә, остеопатия – ул тулаем кеше организмына тәэсир итүнең мануаль системасы. Шул ук вакытта аны мануаль терапия белән бутарга ярамый. Алай гына да түгел, остеопатия, күпләр уйлаганча, терәк-хәрәкәт аппараты белән генә шөгыльләнми. Тагын да алга китеп әйтсәк, «остеопат» «сөяк утыртучы» да түгел. Остеопатия – ул мәҗбүри системалы якын килү алымы. Безнең эш – пациентның барлык зарларын һәм авыру билгеләрен бергә туплап, организмның физик халәтен күрә белү, авырту сәбәпләрен табу һәм, әлбәттә, аларны төзәтү.

ЭТИКА

Күптән түгел генә Васил Зыятдинов Яр Чаллыдан килгән яшь ханымны кабул иткән. Ханымның улында – ДЦП. Алар өчен остеопат бертуктаусыз табибларга йөрүнең соңгы ноктасы. Табибларның берсе анага: «Туктагыз йөрүдән, балагыз беркайчан да йөреп китә алмаячак», – ди.

– Мондый катлаулы очраклар минем өчен бигрәк тә кадерле. Алар күп. Зәгыйфьләнгән кешеләр, туганда травмалар алган сабыйлар... Еш кына ата-аналар сөйләшүдә тоткарлыклар туган балалары белән дә киләләр. Әлеге проблеманың сәбәбе еш кына муен тирәсенә яшеренгән була. Остеопат проблеманы хәл итә, һәм сабыйлар сөйләшә башлыйлар. Әйе, авыруның сәбәбе пациент атаган зарларга бөтенләй бәйле булмаска мөмкин, һәм бу бик мөһим момент! Без исә нәтиҗәләр белән түгел, нәкъ менә сәбәпләрне ачыклау белән шөгыльләнәбез, шуңа күрә эшебезнең нәтиҗәлелеге дә озакка саклана.

– Кайсы чирне безнең гасырның бәласе дип саныйсыз?

– Соңгы елларда миңа торган саен ешрак яшь кешеләр мөрәҗәгать итә башладылар. Аларның тормышында хәрәкәт кимеде. Көннәр буе компьютер артында утыралар, эштән чыгуга, машинага күчеп утыралар, спорт белән шөгыльләнмиләр диярлек. Инде шөгыльләнә башлыйлар икән, чиген белмиләр! Нәтиҗәдә бераз вакыттан соң умыртка баганасында, аякларда, йөрәктә, сулыш юлларында авырту барлыкка килә... Табибка йөрүләр, бертуктаусыз авыртуны баса торган дарулар эчү башлана... Авыру чигенгән кебек тоела, ләкин вакытлыча гына, чөнки организмның физиологиясен көйләми, аны нормаль халәткә китерми торып, чир беркая да китми.

– «Бөтен авырулар да нервылардан» дигән киң таралган фикер ничегрәк?

– Мин моның белән килешеп бетмим, ләкин шуны танырга тиешмен: кешеләр стресстан һәм артык мәгълүматтан ешрак җәфалана башлады. Мәгълүмат ташкынын баш мие кабыгы кабул итә, ә ул безнең гәүдә белән идарә итә. Ул иң «кирәкмәгәннәрен» түбәнгәрәк, күкрәк читлегенә төшерә. Кысылу барлыкка килә, «күкрәккә төер тыгылды» дигән халәт туа, йөрәк сикерә, тахикардия башлана. Менә шуннан кеше табибларга йөри башлый, анализлар тапшыра, ә сәбәбен таба алмый. Әгәр әлеге халәтне ачыклап, аны юкка чыгармыйсың икән, йөрәк, үпкәләр белән җитдирәк проблемалар туарга мөмкин. Остеопат, гәүдәнең биомеханикасы белән эшләп, бу хәлдән котылу юлын табарга ярдәм итә.

– Сез шәхсән үзегез сәламәтлегегезне саклар өчен нишләр эшлисез?

– Күбрәк хәрәкәтләнәм! Хәрәкәттә – бәрәкәт. Иртә-кич күнегүләр комплексы ясыйм. Үземнең пациентларым белән бүлешәм. Барлыгы биш минут вакыт кирәк һәм башка бернишлисе дә юк, ә файдасы – әйтеп бетергесез! Сәламәтлекне әллә кайдан эзлисе юк, ул безнең башта, күңел халәтендә. Бары тик кеше үзе генә язмышын һәм, димәк, сәламәтлеген дә билгели.

Автор:
Анна Белозёрова

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ



«ТӘМЛЕ АШЛАР ҖЫРЧЫСЫ»

Быел Казан шәһәре үзәгендәге Татар халык ашлары йорты ачылуга 50 ел тулды. Татарстан башкаласында нәкъ ярты гасыр элек Советлар Союзындагы беренче татар рестораны үз ишекләрен ача. Аны оештыручы – РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре, Ленин һәм Халыклар дуслыгы орденнары кавалеры, СССРның Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә кулинар хезмәтләре өчен алтын медаль алган татар халык ашлары белгече Юныс Әхмәтҗанов.

Автор:
Мөршидә Кыямова

Фотолар Юныс Әхмәтҗановның гаилә архивыннан алынды



Юныс Әхмәтҗанов танылган аш-су остасы гына түгел, аларның әзерләү ысулын өйрәнер өчен татар авылларына йөреп, бөртекләп рецептлар җыйган, милли традицияләрне китаплар аша халыкка кайтарган ашчы-галим дә. СССР заманында татар ашларын бөтен Россия күләмендә оештырыла торган чараларда таныта һәм яраттыра ул. 1980 елда Мәскәүдә узган Олимпиада вакытында да милли ризыкларыбыз белән бөтен Җир шарыннан җыелган катнашучыларны һәм кунакларны сыйлый. ГДРдагы Лейпциг ярминкәсендә татарның милли ризыкларын оста пешерүче буларак дан казана. Аның кул астында эшләгән коллегалары, рәхмәтле шәкертләре әле бүген дә шул заманнарны сагынып искә ала.

Юныс Әхмәтҗанов – тумыштан пешекче, чөнки үзен белә башлаганнан бирле аны аш-су тирәсендәге ыгы-зыгы җәлеп иткән (сугыш чоры баласы булганга түгелме икән?). Юнысның әтисе иртә дөнья куя. Малай Бөек Ватан сугышының иң катлаулы чоры – 1942 елда15 яшендә Яңа Бистәдәге бер предприятиедә үзенең хезмәт юлын башлый. Авыр елларны Юныс Әхмәтҗанов болайрак искә ала:

«Үз күзе белән күрмәгән кешегә хәзер ул чордагы завод ашханәсенең ни икәнен аңлатуы шактый кыен. Утын ягып җылытыла торган плитәләр, аның утынын табыштыру, кисү-яру – болар барысы да ашханә хезмәткәрләренә тапшырылган. Яңа эшкә килгән яшүсмер малайны, ягъни мине күргәч, ашханә кешеләре җиңел сулап куйдылар. Мин аларга, тәмледән-тәмле аш пешерү ысулларын өйрәнергә тиешле шәкерт булудан бигрәк, утын ташучы, аны кисеп яручы, утынны мич алдына кертеп куючы малай буларак кадерле идем...

Өйрәнчек дәверен үтеп, мөстәкыйль пешекче булып эшли башлагач, беренче тапкыр пешерә башлаган ашым әле дә хәтердә. Аның тәме, авыр сугыш елларының истәлеге булып, телдә һаман саклана кебек...»

«Мин бу сүзләрнең мәгънәсен, вакытлар үткән саен, тирәнрәк аңлый барам. Ашларыбызга гына игътибар итегез: токмачын аласыңмы, бәлешен яки татлыдан татлы чәй ашларын әйтәсеңме – барысы да чын сәнгать әсәрләре бит алар. Белергә, өйрәнергә, шуларны табыннарыбыз күрке итү өчен, тырышып хезмәт итәргә генә кирәк», – дип яза аш-су остасы.

Юныс Әхмәтҗановның беренче китабы 1959 елда дөнья күрә. «Татар халык ашлары» исемле «тәмле китап» һәр гаиләдә саклана, чөнки заманында ул бик популяр басма буларак тарихка кереп кала. Әлеге басманың «аягы җиңел» була. Юныс ага бер-бер артлы хуҗабикәләр, булачак аш-су осталары өчен бик файдалы басмалар әзерләвен дәвам итә. Алар татар, рус телләрендә нәшер ителә.

«ХЕЗМӘТЕМ – ҖАН РӘХӘТЕ»

Замандашлары Юныс Әхмәтҗановны тырыш, таләпчән, талантлы, популяр, шул ук вакытта бик гади шәхес итеп тасвирлый. Хөкүмәт дәрәҗәсендәгеләр белән дә, шул ук вакытта гади кешеләр белән дә бертигез аралаша ул. Кешеләрне җәмгыятьтә тоткан урынына карап аермый.

Юныс Әхмәтҗановның шәхси архивында Юрий Гагарин, Валентина Терешкова, Юрий Никулин, Александра Пахмутова һ.б. күренекле чордашларының фотолары саклана. Татар ашчысы заманында аларны милли ризыклар белән сыйлаган. Ә кунаклар, рәхмәт йөзеннән, Юныс Әхмәтҗановка ихлас теләкләрен теркәп фотоларын бүләк иткәннәр.

Бөтенсоюз һәм дөньякүләм фестивальләр, конкурсларда катнашып, татарның милли ризыкларын дөнья аренасына чыгарган остаз үзе исә гап-гади кыстыбый белән шулпа яраткан.

Юныс Әхмәтҗанов Теләче районының Зур Кибәхуҗа авылында дөньяга килгән. Әтисе ягыннан барысы да оста тегүчеләр булган. 1930 нчы елларда әтисе Әхмәтҗан абзый гаиләсе белән Казанга күчә. Биредә мех фабрикасына эшкә урнаша. Фабрикада аңа «стаханчы Әхмәтҗан» дигән кушамат та тагалар әле. Биш балалы гаиләдә Юныс – иң олысы. Ата-ана эшкә киткәч, бөтен җаваплылык аның җилкәсендә, димәк. Кечкенә балаларны карау, олылар эштән кайткан җиргә аш әзерләп тору...

Әнисе Зәйнәп апа – тирә-юньдә дан тоткан аш-су остасы. Яңа Бистәнең бай хатыннары уздыра торган аш мәҗлесләрендә ул әзерләгән ризыклар куела торган була. Юнысның аш-суга хирыслыгы да әнисеннән күчкән. Борынгы татар ризыкларын барлап эзләнгәндә әнисенең пешерү ысулларын да теркәп бара булачак оста. Улының эзләнүләрендә ана кеше дә шактый ярдәм күрсәтә.

Юныс Әхмәтҗанов аш-су юнәлеше буенча техникум тәмамлый. Белемен арттыруга зур игътибар бирә. Мәскәүдәге атаклы грузин ресторанында осталык курслары узганда, танылган аш-су остасы Николай Кикнадзеның киңәш итеп әйтелгән сүзләрен һәрвакыт күңелендә йөртә:

– Һәр һөнәргә осталыкны халыктан өйрәнергә кирәк, Юныс! Халыкның борынгы җырларын җыялар, мәкаль-әйтемнәрен теркәп баралар, кием-салым тегү формаларын да, чигү үрнәкләрен дә, архитектураны да борынгы хезмәтләрдән күчереп-күчереп алалар. Безнең эш тә, әгәр аны яратсаң, олыласаң, бу төр хезмәтләрдән һич аерылмый. Тәмле аш пешерә белү – сәнгать кешеләренеке кебек үк талант таләп итә! – ди ул.

«Сайлаган һөнәремә тугрылыгым, тырышлыгым минем гомернең мәгънәсе булып гәүдәләнде. Шулай турыдан-туры кабул итә күрмәгез. Сүзләремнән аңлашылса кирәк: минем шулай ышаныч белән сөйләвем һөнәремнең кешеләргә бик кирәкле икәнлеген тоюдан, горурлану хисеннән килә. Нәкъ шул эш мине горур кеше ясады».

Данлыклы оста СССРның абруйлы шәхесләрен дә, гади студентларны да тукландыра, аларга чын мәгънәсендә милли ризык тәмен тоярга, ләззәтләнергә мөмкинлек бирә. Сугыштан соңгы елларда татар милли ризыкларын туклану оешмалары менюына кертү өчен зур көч куя, үҗәтлек күрсәтә, чөнки Совет чорында Россиядә милли ризыклар җәмәгать туклануыннан кысрыклап чыгарылган була инде. Ул аларны кире кайтару өчен Мәскәүгә өчпочмак, пәрәмәчләрне аз күтәреп ташымый. Теләгенә ирешә, зур түрәләрне килештерә. Киң кулланышка «ашханә» сүзен кертә.

«Чын оста, ул кайсы һөнәргә ия булса да, үз хезмәтен үзе мәңгеләштерә ала. Пешекче элек-электән үк ирләр эше булып саналган, чөнки авыр хезмәт ул. Минем өчен пешекче эше – җан рәхәте».

ИСТӘЛЕКЛӘР

Фатыйма Мәҗитова, Юныс Әхмәтҗановның укучысы, РСФСРның атказанган сәүдә хезмәткәре:

– Юныс абый мактаганны үлеп ярата иде. Бервакыт Мәскәүдә кунакханәдән ВДНХга эшкә барып җитү өчен, без таксига утырдык. Шулай таксида барабыз. Юныс абый алда – таксист белән янәшә утыра. Таксист аңа карый-карый да, тагын бер карап куя. Шуннан сорый: «Сез Леонов түгелме?» Ләкин Юныс абый аңа җавап бирмәде (ул аңа охшаган иде). Бары тик: «Мәскәүдә Леоновны хөрмәт итәләрме?» – дип кенә сорап куйды. Ул үзен хөрмәт иткәнне бик ярата иде, моңа лаек та иде. Ресторанга ашарга кергән кешеләр аның белән, күптәнге танышлары кебек, кул биреп исәнләшәләр. Ул да алар белән елмаеп аралаша. Бактың исә, ул аларның кайберләрен белми дә икән. Ләкин һәр кешене дә якын итә иде. Юныс абый белән командировкаларга да шактый йөрергә туры килде, аннан бик күп тәҗрибә тупладым мин. ВДНХ-га союздаш республикалар арасында оештырылган кулинарлар бәйгесендә татар ашларын тәкъдим иттек. Павильоннар халык белән шыгрым тулы. Ул вакытта чәкчәкне белүче дә юк. «Кукурузмы?» – дип сорыйлар. Безнең һәр пешергән ризыгыбызны мактый-мактый, кунакларга тәфсилләп сөйли белә иде, ризыкны ашый башлаганчы ук, ул аның тәмен аңлатып бирә. Тыңлап торучының шунда ук аппетиты кузгала. Ризыклар шулай затлы итеп хәзерләнсә дә, әгәр анда Юныс абый булмаса, без аны бу дәрәҗәгә җиткерә алмас идек.

Роберт Миңнуллин, Татарстанның халык шагыйре:

–Хәзер милли ашлар белән шөгыльләнүчеләр җитәрлек, ә элек Юныс Әхмәтҗанов берәү генә, берүзе генә иде. Олы кунакларны сыйлауны аңа гына ышанып тапшыралар иде. Шуңа күрә дә, бүгенге көнгә кадәр аның хакында төрле мәзәкләр, легендалар йөри. Аеруча Хрущевны сыйлавы хакында. Сөйләүләренә караганда, Никита Сергеевич Юныс абый әзерләгән тутырган тавыкны яратып ашаган, киткән чагында юлга да салырга кушкан, имеш. Юныс абыйның хатыны Зәйтүнә апаның сөйләгәне истә калган: «Юныс үзе һәрвакыт яратып сөйли торган иде. Хрущев, бик күңеле булып, тутырган тавыкны әзерләгән поварны чакыртып алган. Тиз генә Юнысны эзләп тапканнар. Никита Сергеевич мактый-мактый Юнысны кочакламакчы булган. «Ләкин генсек шактый таза, олы корсаклы, мин дә шул чама. Кочаклашып кына булмый бит!..» – дип шаярта иде ул». Ә инде Юныс Әхмәтҗановның пешергән чәкчәген авыз итеп карагач: «Күрче, нинди тәмле кукуруз!» – дип тә әйткән дип сөйлиләр. Чәкчәкнең нидән пешерелгәнен аңлатып биргәч тә, аның кукуруз түгеллегенә Никита Сергеевич ышанмаган, имеш.

Мәгъсүм Гәрәев, журналист, язучы:

– Юныс тәмле ашлар җырчысы иде. Без аның белән аралашып яшәдек. Берара Юныс партия Өлкә комитеты ашханәсендә эшләп алды. Минем олы баҗам Хәлил Габидуллин да – шунда. Эштә аттан да артык тарталар. Гаиләләре белән кунакка йөрешеп, театр-концерт залларында очрашып, тормыш ямен, дуслык кадерен белеп яшәделәр. «Кофер почмаклары» да бар, зыялылар белән очраша торган җирләре бу. Чын мәгънәсендә дуслык клубы иде ул. Директоры – Хәлил Габидуллин, сәнгать җитәкчесе – Юныс Әхмәтҗанов. Монда артистлар, язучылар, композиторлар да – кадерле кунак. Салих Сәйдәшев белән озын-озак гәпләшеп утырган чакларын бик еш искә алырлар иде Хәлил абый белән Юныс. Миңа клуб утырышына СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлилов, артист Вәкил Закиров, язучы Зәки Нури, композиторлар Исмай Шәмсетдинов һәм Заһид Хәбибуллин кебек зыялыларны алып килү эше йөкләнгән чаклар булды. Һәр очрашуыбыз, гәпләшүебез чын күңелдән, эчкерсез була торган иде… Юныйсның, дусларына кунакка баргач та, биленә алъяпкыч бәйләп, пилмән бөгеп, башкаларны сыйлый торган гадәте бар иде. Еш кына аңа: «Уңганбулган кеше син, ашбаз!» – дия торган идек.

Ренат Залютдинов, «Брупер-Нәүрүз» рестораны генераль директоры, Казан һәм Татарстан рестораторлары һәм отельерлар ассоциациясе президенты:

– Юныс Әхмәтҗанов талантлы пешекче һәм гаҗәеп ихлас кеше иде. Мин аңардан шактый күп нәрсәгә өйрәндем, аның белән эшләү дәверендә зур тәҗрибә тупладым. 1978–1981 нче елларда бергә эшләдек. 1980 елда Мәскәүдә узган Олимпия уеннары вакытында, Мәскәү кунакларын ашаттык. Яшь булуыма карамастан, мин – директор, Юныс абый – производство бүлеге мөдире. Бауман исемендәге институтның тулай торагында бер бүлмәдә 3 айлар чамасы бергә яшәдек. Юныс абый бик таләпчән иде. Башкалардан да шул сыйфатны таләп итте. Без Олимпиадага татар ашлары әзерли идек. Ләкин ул, татарларның булдыклылыгын күрсәтү җәһәтеннәндерме: «Әйдәгез, иртәгә кавказ кухнясы көне оештырабыз, ләкин татар акценты белән. Казаннан килгән пешекчеләр башка милләт ашларын да пешерә белә икән, дисеннәр!» – ди. Шулай эш барышында менюны төрләндерә торган иде. Ә мин шуларның барысын да җитәкчелеккә раслатам. Төрле ризыклар тәкъдим итеп торгач, безнең залга җитәкчеләр дә, гади кешеләр дә күп йөри. Импровизация көчле иде аңарда. Бервакыт йөгереп килгән дә: «Әйдә, «Хан уха»сы тәкъдим итәбез!» – ди. Мин куркып калдым, ничек инде? Совет заманының гөрләгән чагы, андый исемдәге ризыкны табынга куярга түгел, хан, солтаннарны телгә алырга да ярамый! Әмма Юныс абый инде барысын да төгәл уйлап куйган. Дөресрәге, Идел елгасында йөзгән балык язмышын. Тарихны яхшы белә иде, тирәнтен фикерләп, һәр нәрсәне уйлап эш йөртә. Теләсә нинди кыенлыклардан бик оста чыгу юлын таба иде. Олимпиада вакытларында ул мине йоклатмады. Иртәнге биштә торып баса да: «Әйдә-әйдә, тор, синең кебек яшь кешегә 4 сәгать йокы җитә», – дип, таңнан такси чакыртып, эшкә кузгала идек. Мин аннан эшләргә генә түгел, яшәргә дә өйрәндем.

Фоат Әхмәтҗанов, Татарстан һәм Россиянең атказанган тренеры:

– Әтине Казанда һәр кеше таный кебек тоела иде миңа. Аның белән Бауман урамыннан барганда, бөтенесе килеп исәнләшә, якын күреп сөйләшә. Мин үзем әти юлыннан китмәдем. Аның юлын сайласам, «Менә, Әхмәтҗанов малае бит ул», – диярләр кебек тоелды. Арабыздан киткәненә дә 30 елдан артык вакыт узды, әмма аны хәтерлиләр, шунысы куандыра. Әти ял көннәрендә районнарга чыгып, татар апаларыннан төрле рецептлар җыеп кайта иде. Аның төрледән-төрле 17 китабы бар. «Бу хезмәтләрең өчен профессор дәрәҗәсе бирергә кирәк сиңа!» – диләр иде. «Их, минем югары белемем юк шул», – дип, чын күңелдән көрсенә иде әти. Ә мин аңа: «Әти, син күптән инде академик!» – диеп, күңелен юата идем. Әтинең хыялын үзем тормышка ашырдым. Үзем профессор булдым! Әтинең әнисе, минем дәү әнием Зәйнәп тә бик тәмле ризыклар әзерли иде. Ял көннәрендә ул яшь кызларга Татар ашлары йортында «Булачак килен» клубы да оештырган иде. Анда килен токмачы кисәргә өйрәткәннәре хәтердә.

«БЕЗНЕҢ ӘТИ ЛЕНИН КЕБЕК ЯШӘДЕ»

Юныс Әхмәтҗановның 90 еллыгына багышлап, шагыйрь Роберт Миңнуллин «Тәмле ашлар җырчысы» дигән китап әзерләде. Юныс Әхмәтҗанов үзе исән чагында татар газета-журналларында даими рәвештә материаллар бастырып килә. Гаилә архивындагы 4–5 альбомда төрле елларда дөнья күргән китаплары һәм аның турындагы язмалар, шулай ук үзенең материаллары теркәлгән. Татар ашлары тарихының яңарыш чорын саклаган әлеге ядкарьләрдә шулай ук тарихи фотолар да урын алган.

Кызы Фәридә ханым иң кадерле балачак мизгелләре турында сөйли. Әтисе белән бергә эшкә чыгып китүләре, Мәскәүдә Олимпиада вакытында армый-талмый хезмәт күрсәтүләре, ничек итеп әтисенең «Казан» ресторанына эшкә урнаштыруы… Болар барысы да кызының күңел түрендә сакланган иң җылы хатирәләр. Фәридә Давидова үзе дә 49 ел инде кондитер булып эшли.

– Гомере генә кыска булды. Үзен аямыйча эшләде – дип искә ала ул әтисен. – Ял итә белми иде. Һәрбер тантана, яки җитди очрашулар алдыннан кайгыра, һәрнәрсәне йөрәге аша уздыра. Мине иркәләп кенә үстерде димәс идем, каршы әйткәнемне яратмый иде. Бигрәк тә җитәкчеләргә ризасызлык белдерсәм, сүгеп алганнары хәтердә. Әмма әтинең киңәшен тотып кондитер һөнәрен сайлавыма һич үкенмим. Гомерем буе яраткан эшемне башкарам, улым Искәндәр дә бабасы эзеннән китте. Төрле конкурсларда катнашканда да әти үзе белән мине ала иде… бәрәңге әрчергә. Кечкенәдән елый-елый бәрәңге әрчегәннәрем хәтердә. Олимпиада кунакларын ашатканда да төннәр буе шул эшне башкардым… Әтинең һәрвакыт зур самавыры кайнап тора, ул башкалар ашатырга теләмәгән солдатларны, милицияне дә кире бормый, алар өчен пәрәмәчләр пешертә иде. Казан үзәгендә безгә фатир бирделәр. Әни: «Яңа фатирга Мәскәүдән тәрәзә пәрдәләре алып кайтырсың», – дип, акча биреп җибәрде. Кеше сыйлый-сыйлый ул акчабыз да бетте.

Уеннар узгач, иң яхшы пешекчеләрне, командаларны барладылар. Министр, җиңүле урын алган, үзләрен яхшы яктан күрсәтә алган шәһәрләрне сәхнәгә чыгарып мактый. Ә пешекчеләр командасы, җавап итеп, түрәләргә затлы бүләкләр тапшыра. Мин эчемнән кайгырып утырам, безнең команданың андый бүләге юк! Нишләрбез икән, дим. Иң соңыннан безнең команданы атадылар. Беренче урын дип игълан иттеләр. Әти сәхнәгә 15 тиенлек уклавын тотып чыгып китте. «Пәрәмәч-өчпочмак, токмач – яратып ашадыгызмы? Менә алар барысы да менә бу таяк ярдәмендә ясала», – дип, куна таягын министрга бүләк итте! Зал аягүрә басып алкышлады үзен…

Безнең өйдә бервакытта да кешеләр турында начар сөйләшмәделәр, гайбәтнең әсәре дә булмады. Әти өчен бөтен кешеләр дә яхшы иде. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, әти өстеннән нахак шикаять язучылар да булмады түгел, булды…

Шеф-пешекче кул астындагылар өчен иң куркыныч җәза – «Җансызлар!» сүзен ишетү. Юныс Әхмәтҗанович булдыксыз хезмәткәрләрне шулай дип атаган. Пешекче өчен беренче эш – кешеләрне хөрмәт итү, гадел булу, дип санаган ул. Үзе дә гомере буе шул сыйфатына тугры калган.

Татарстанда гына түгел, гомумән Советлар Союзында татар халык ашларын танытучы остаз, төрле министрлар, дәүләт эшлеклеләренең якын дусты бай, мул, иркен тормышта яшәгән, дип уйлаучылар да булгандыр. Ләкин Юныс Әхмәтҗановларның фатирында 1 килограмм он, 1 кг шикәр комыннан артык нәрсә булмаган. Аның чакыруы буенча авылдан берәр борынгы ашны пешерергә килгән апалар да: «И-и, Юныс, бигрәк Ленин бабай кебек яшисең инде, бер өстәл дә, бер карават бит монда!» – дия торган булганнар. Ә атаклы пешекче бу сүзләргә куанган гына.

Юклык заманында аз гына ризыктан да төрле, туклыклы ашлар пешерә торган була Әхмәтҗанов. Мәсәлән, Казан мантыен да ул уйлап таба. Мантыйның ит фаршына бәрәңге турап салсаң, күбрәк тә, юньрәк тә чыга, димәк гади студент та тамагын туйдыра ала, дип фикер йөртә ул. Калҗа, тутырма кебек ризыкларны да табын түренә ул менгерә.

«ПЕШЕКЧЕ ҺӘР КӨННЕ ҺӘРКЕМНЕ СӨЕНДЕРӘ АЛА!»

Яхшы пешекче – әйбәт пешергәне түгел, ә башкаларны да пешерү серләренә өйрәтә белгәне, диләр. Юныс Әхмәтҗанов тирәсендә гел профессионаллар һәм талантлы яшьләр эшләгән. Замандашларының әйтүенә караганда, ул пычак тота белә торган кешене бер күрүдә танып алган, үзе белгәннәрне дә җентекләп өйрәтергә тырышкан.

Күпсанлы истәлекләрендә Әхмәтҗанов аш-су осталыгы хакында түбәндәгеләрне яза:

«Пешекче – артист ул, кунагының күңелен табу өчен, аңа нәкъ сәхнәдәгечә сәнгать остасы булырга туры килә. Йөзеңдә һәрчак елмаю булсын. Усалланып йөрүче кеше тәмле аш пешерә белми ул. Пешекче – табиб. Аңа кешеләрнең сәламәтлеге тапшырылган. Пешекче – рәссам. Аның ашы тәмле генә түгел, бик матур да булырга тиеш. Пешекче философ та, педагог та, сәгатьләр буе утлы плитә янында торучы металлург та.

Кешенең бәхете үзе бәхетле иткән кешеләр санынча арта бара. Шулай икән, димәк, миннән дә, ягъни пешекчедән дә бәхетлерәк кемне табасың? Ул бит һәркемне һәркөнне сөендерә ала!»

Һәр ел саен февраль аенда, остазның туган көнендә, Юныс Әхмәтҗанов исемендәге татар милли аш-су осталыгы конкурсы оештырыла. Биредә нәкъ менә татар халык ашларын оста әзерләүче яшьләр җыела. Татарстан Президенты фатихасы белән узучы әлеге проектта чит илләрдән катнашучылар да бар.

Элегрәк вакытта байларның асравы яки йомышчысы, ат караучысы шикелле дәрәҗәсезрәк саналган ашчы һөнәре Юныс Әхмәтҗанов кебек горур, уңай мәгънәдә үҗәт, талантлы затның тырышлыгы белән популярлашты.

Юныс Әхмәтҗанов 57 яшендә ялкынланып эшләп торган вакытта дөнья куя. Якыннары «йөрәге түзмәде», ди, чөнки ул Татар ашлары йортында соңгы кунакларны озатканчы эшли торган була, ә иртәнге 5 тә – кабат яраткан эшендә. Аны соңгы юлга озатырга Бауман урамын тутырып халык килә. Араларында: «Икенче Тукайны күмәләр...» – дип күрсенүчеләр дә була.

Юныс Әхмәтҗанов 1969 елда Советлар Союзындагы беренче Татар ашлары йортын ачуга ирешә. Бу – аның тормышындагы төп хыялы. Заманында биредә төрледән-төрле милли ризыклар әзерләнә.

Соңгы елларда Татар ашлары йортында озак вакытка сузылган төзекләндерү эшләре үткәрелде. Бина диварына данлыклы пешекченең хәтер тактасы да беркетелгән. Хәтта Юныс Әхмәтҗановның хәтер почмагы да бар. Ләкин шунысы хак: анда атаклы останың рухы юк. Ә бит бу бинада кабатланмас шәхеснең яшәү мәгънәсе булган хезмәт җимешләрен тәкъдим итә торган, аның гомер юлын тасвирлаган экспозицияләре белән балкып торучы бер ашханә эшләсә, нинди әйбәт булыр иде.

ЧОРЛАРНЫ ҖИҢГӘН **ПРОЕКТЛАР**

Ленин исемендәге мәдәният сарае

«Крылья Советов» паркы

«Магеллан» торак комплексы

«Казан Гипронииавиапромы» АҖ – илебезнең алдынгы проект институтларының берсе. Әмма предприятие нинди генә югары нәтиҗәләргә ирешмәсен, ул үз тормышында кече тарихи ватаны турында кайгыртырга да вакыт таба.

Бөек Ватан сугышының беренче айларында Казанның Ленин районы территориясенә (чирек гасыр элек Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарына бүленде – ред. иск.) башкаладан «Гипроавиапром» Мәскәү авиация сәнәгате проект институты эвакуацияләнә. Ул шулай ук бу калага эвакуацияләнгән авиация заводларын проект документациясе белән тәэмин итәргә дә тиеш була. Ә бу заводлар пикега китүче Пе-2 бомбардировщиклары, ерак оча торган Пе-8 бомбардировщиклары, авиация двигательләре җитештерә. Мәскәү һәм Казан белгечләре бригада туплый, аның бер өлеше сугыштан соң институтның Казан филиалын оештыра. «Казан Гипронииавиапромы» АҖнең тарихы әнә шулай башлана. Предприятие Ленин районы белән бергә үсә дип әйтү генә җитми, ул аны төзи, барлыкка китерә. Институт тарафыннан ике район өчен проектланган объектлар нигезендә шәһәр тарихын гына түгел, ә аны оештыручыларның иң югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгын да ачып бирә торган уникаль маршрут төзергә мөмкин.

Авиатөзелеш районының «яшел» визит карточкасы – «Крылья Советов» паркы XX гасырның 30 нчы еллары ахырында барлыкка килә. Институт 40–60 нчы елларда паркны планлаштыру эшендә катнаша. XXI гасырда исә «Казан Гипронииавиапромы» хәйрия максатларында паркның реконструкция проектын әзерли, ул исә Авиатөзелеш районы халкының яраткан паркына яңартылган һәм төзекләндерелгән рәвештә җан өрә. Парк янында – Ленин исемендәге мәдәният сарае. Аның проектын озак еллар институтның баш инженеры булып эшләгән Юрий Мочалов әзерләгән. Мәдәният сарае бинасы бик матур, иркен, якты… Чып-чын сарай! Проект эшләнгәнгә ничә ел үтүгә карамастан, аңа салынган мәхәббәт һәм осталыкның кешеләргә шатлык китерүенә ап-ачык мисал ул.

СССР вакытында төзелешне комплекслы итеп алып барганнар, әнә шуңа күрә дә Ленин районы территориясендә парк та, мәдәният сарае да пәйда була, чөнки хезмәткәрләрнең уңайлы мәдәни һәм иҗтимагый тормышы өчен кирәкле бөтен нәрсә предприятие тирәсендә төзелә. 40 нчы елларда бирегә эвакуацияләнгән С. П. Горбунов исемендәге 22 нче Мәскәү авиация заводы (аннары – Горбунов исемендәге Казан авиация җитештерү берләшмәсе), берничә мотор төзү предприятиесен берләштергән 16 нчы завод (соңыннан – Казан моторлар җитештерү берләшмәсе) районның «йөрәгенә» әвереләләр. «Гипронииавиапром» хезмәткәрләре сугыш елларында бу предприятиеләрнең җитештерү биналарын һәм линияләрен проектлаштыра. Әлеге бурычны тормышка ашырганнан соң, колачлы модернизацияләү, үзгәртеп кору һәм яңадан җиһазландыру проектларына керешәләр. Бу эш бүген дә дәвам итә. Нәкъ менә «Казан Гипронииавиапромы» АҖ Горбунов исемендәге Казан авиация заводында модернизацияләнгән Ту-160 очкычын чыгару белән бәйле цехларны һәм җитештерү линияләрен проектлау белән шөгыльләнә.

Казан авиация һәм моторлар җитештерү берләшмәләрендә хезмәт куючылар өчен «Гипронииавиапром» берничә квартал торак йортның проектын эшли. Дементьев урамыннан Копылов урамына кадәр, Максимов урамыннан Айдаров урамына кадәр кварталдагы торак йортлар институт проектлары буенча калкып чыккан. Тиңдәшсез объектларның берсе – 123 нче һөнәри-техник училище биналары комплексы (бүген – 123 нче лицей). Әлеге уку йорты проекты авиазаводның легендар генераль директоры Виталий Копылов заказы буенча әзерләнә. Виталий Копылов ул вакыт өчен инновацияле «училище – тулай торак – җитештерү» триадасы идеясен тормышка ашырырга тели. Соңрак мондый проект – Фатих Әмирхан урамында уку корпуслары комплексы һәм 9 катлы тулай торак – институт тарафыннан Казан моторлар җитештерү берләшмәсе өчен эшләнә.

Авиатөзелеш районында гражданлык төзелеше проектларын булдыру тәҗрибәсе институтның Яңа Савин районындагы эш нигезенә салына. 60 нчы елларда йорт төзелешендә революция ясаган биш катлы йортларның шактый өлеше «Казан Гипронииавиапромы» проектлары буенча төзелә. 80 нче еллар ахырына институт проектлары буенча төзелгән торак мәйданы 2,6 млн квадрат метрдан артып китә.

Яңа Савин районының иң үзенчәлекле объектлары – район хакимияте бинасы һәм аның янәшәсендәге мәйдан, Меридиан урамындагы 90 нчы еллар ахыры өчен инновацияле система – үзгәртеп корыла ала торган КУБ системасында проектланган берничә йорт, шулай ук 2006–2008 елларда төзелгән «Магеллан» торак комплексы һәм «Татнефть Арена» бинасы.

Казанский Гипронииавиапром

420127, Казан шәһәре, Дементьев ур., 1 йорт
Тел.: (843) 571-95-48, факс: (843) 571-96-56

Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарында яшәүче хөрмәтле казанлылар!

Сезне чын күңелдән районның 25 яшьлек бәйрәме белән котлыйбыз! Кадерле якташларыбыз, сезгә бәхет, сәламәтлек һәм аяз күк йөзе телибез!

Реклама

Фото «Казан Гипронииавиапромы» җәмгыятеннән алынды

ТӨП МАКСАТ – ТОРМЫШНЫ УҢАЙЛЫ ИТҮ

– Соңгы ун елда халык безнең алга куйган бурычлар бик нык үзгәрде, – диде Казан мэры Илсур Метшин республика башкаласы кешеләре белән күптән түгел булып узган очрашуларның берсендә. – Элегрәк түбә ага, подъездлар начар хәлдә, коммуникацияләргә ремонт кирәк, дип зарлансалар, бүген инде әлеге проблемалар хәл ителеп бетте диярлек.

Хәзер безнең алда җәяүлеләр өчен җәмәгать урыннары, балалар белән ишегаллларында ял итү мөмкинлекләре булдыру бурычы тора. Димәк, алга таба хәрәкәт итәбез, дигән сүз, шул ук вакытта башкарасы эшләр дә күп әле...

Һәм бу чыннан да шулай. Казанда халыкның яшәү һәм хезмәт итү шартлары елдан-ел яхшыра бара. Мондый нәтиҗәләргә бүген Татарстанда төзелеш һәм капиталь ремонт өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган республика программалары нәтиҗәсендә ирешелә, шулай ук башкала халкы үзе дә актив өлеш кертә. Билгеле, республиканың авиация сәнәгате предприятиеләре кластеры урнашкан Авиатөзелеш районы да чыгарма түгел. Соңгы елларда райондагы тормыш тамырдан үзгәрде, шул ук вакытта, анда яшәүчеләр фикеренчә, ниндидер дәрәҗәдәге тынычлыгын да саклап калды.

Казанның иң борынгы паркларының берсе моннан берничә ел элек нинди халәттә булуын күрү юлында каршы алучы укытучы, очучы, авыл хезмәтчәне һәм альпинист сыннары һәм аллеяләрдәге биек-биек карт агачлар гына хәтерләтеп тора. Бүген «Крылья Советов» паркы сизелерлек яшәрде. Бирегә гаилә белән пикникка чыгалар, совет чорында төшерелгән нәфис фильмнарны карарга, ачык һавада фитнес яки йога белән шөгыльләнергә киләләр, дуслар белән очрашалар. Авиатөзелеш районындагы яшел зона гына түгел ул, ә һәркем үзе өчен кызыклы һәм мавыктыргыч бирәр шөгыль таба торган урын да.

Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарын төзекләндерү бирредә эшчәнлек алып бара торган эре предприятиеләр һәм оешмалар ярдәменнән башка мөмкин булмас иде. Алар барысы да менә озак еллар инде Казанның Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимияте белән тыгыз элемтәдә эшли. Һәм бу хезмәттәшлекне һич арттырусыз уңдырышлы һәм социаль яктан җаваплы дип атарга була. Районнарның чәчәк атуына шәһәр кешеләре дә саллы өлешен кертә. Алар уңайлы мохит булдыруга кагылышлы мәсьәләләрне күтәрергә, район хакимиятләре белән берлектә нәтиҗәле карарлар кабул итәргә өйрәнде. Болар барысы да казанлыларның тормышына уңай тәэсир ясый, ә Казанны төзегрәк һәм уңайлырак итә.

«Союз» Казан Тәҗрибә Конструкторлык бюросы» АҖ коллективы Казан башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары хакимияте башлыгы Тимур Әлибаевны, муниципалитетның барлык хезмәткәрләрен, шулай ук оешма коллективларын һәм район халкын аңа нигез салынуга 25 ел тулу уңаеннан бәйрәм белән котлый. Барыгызга да ныклы сәламәтлек, иминлек, алга таба да һәрвакыт уңышлар тели!

Реклама
Фото «Союз» Казан Тәҗрибә Конструкторлык бюросы» АҖ нән алынды

МОНДА ОЧАРГА ӨЙРӘТӘЛӘР

Утыз елдан артыграк элек Ленин районы (хәзерге Авиатөзелеш районы) территориясендә самолётлар һәм вертолётлар төзү предприятиеләре үсеш ала. Нәкъ шул елларда республиканың авиация сәнәгате өлкәсендә үз эшенең осталары үсеп чыга, алар бүген дә хезмәт итә әле. «ЭНИКС» АҖ предприятиесендә алар Россия машина төзелешендә иң эре тармак булган авиация өлкәсенең әһәмиятен аңлап, туктаусыз рәвештә һөнәри яктан камилләшәләр, яшь буын белән тәҗрибә уртаклашалар.

Урманда чыккан янгынның мәйданын тиз арада ничек үлчәп була? Хезмәткәрләр тормышын куркыныч астына куймыйча, барып җитүе кыен булган урыннарның чикләрен ничек патрульгә алырга? Еракка сузылган торбаүткәргечләрдә авария булган урынны кыска вакыт эчендә ничек билгеләргә? Шушы һәм башка бик күп сорауларга җавап бер генә – пилотсыз очу аппараты (БЛА) куллану.

Аларны куллану өлкәләре даими рәвештә киңәеп тора, офыкта – БЛА-курьерлар һәм БЛА-таксилар. Татарстанның горурланырлыгы да бар: Казанның Авиатөзелеш районында озак еллар инде кораллы көчләр һәм махсус хезмәтләр өчен пилотсыз очу аппаратлары җитештерүче предприятие – «ЭНИКС» АҖ эшли.

Предприятие җитештергән продукциянең сыйфаты турында «ЭНИКС» хәрби модельләренең профильле салоннар һәм форумнар вакытында ярышларда һәрвакыт иң яхшылар исемлегенә керүе сөйли. Перспективалы эшләнмәләр арасында – Россия Кораллы көчләре өчен эшләнгән җир өстеннән старт бирә торган Е95 кече размерлы һава мишене комплексы. Мишень – төзәп ату имитаторы, анда предприятиенең уникаль эшләнмәсе – пульслы һава-реактив двигателе урнаштырылган. Бу исә аны көндәшлектә тиңдәшсез итә. «ЭНИКС»ның «хитлары» – «Элерон – 3СВ» һәм «Элерон – 10СВ» пилотсыз очу аппаратлары тәүлек әйләнәсендә һавадан оптик электрон күзәтү өчен эшләнгән.

Барлык пилотсыз һәм мишень комплексларын программа белән тәэмин итү һәм аларның математик модельләре «ЭНИКС» белгечләре тарафыннан эшләнә. Комплексларны эшләү, җитештерү һәм сынау дәүләт заказчыгының килешүләре һәм техник биремнәре кысаларында һәм Россия Федерациясенең Оборона министрлыгы контроле астында предприятие тарафыннан башкарыла. Моннан тыш, предприятие комплексларны гарантия вакытында һәм гарантия вакыты узгач хезмәтләндерә, пилотсыз очу аппаратлары сатып алган компанияләрнең операторларын өйрәтә. РФ Кораллы көчләреннән тыш, предприятие продукциясен Росгвардия, ЭЭМ һәм ФКХ кебек структура һәм ведомстволарга, Арктика һәм Антарктика фәнни-тикшеренү институтына, эре нефть компанияләренә һәм башкалар өчен дә җитештерә. Аларның аппаратлары футбол буенча дөнья чемпионаты – 2019 кебек масштаблы чаралар вакытында куркынычсызлыкны тәэмин итү максатларында һавадан күзәтү өчен дә файдаланыла. «Рособоронэкспорт» ААҖ белән берлектә «ЭНИКС» эшләнмәләре халыкара базарга чыгарыла.

Узган ел компания үзенең 30 еллыгын билгеләде. Пилотсыз очу аппаратлары җитештерү буенча фәнни-тикшеренү үзәге Казанда 1988 елда «Сокол» тәҗрибә-конструкторлык бюросының (хәзер «Симонов» тәҗрибә-конструкторлык бюросы) баш конструкторы Утанбәк Цораев инициативасы белән барлыкка килә. Беренче хезмәткәрләрнең күбесе биредә әле дә эшли. Шул исәптән «ЭНИКС»ның алыштыргысыз җитәкчесе Валерий Побежимов та. Бүген, күп еллар элек булган кебек үк, авиамодельләр спорты компания «двигательләренең» берсе исәбендә кала бирә. Берничә ел элек «ЭНИКС» Югары Ослан районының Каинки авылында Авиамоделизм һәм БЛА тышкы пилотлары әзерләү үзәге ачты. 2018 елда үзәк территориясендә Татарстанда беренче кордодром (модельләрне сынау өчен трек, пилот аларны махсус арканнар – кордлар белән тотып тора) төзелде. Үзәктә командировкага укырга килгән БЛА операторлары гына түгел, яшь авиамоделистлар да еш кунак була. Алар иртәгә «ЭНИКС»ның пилотсыз очу аппаратларын һавага очырачак.

Хөрмәтле Авиатөзелеш районы халкы, предприятиеләр коллективлары һәм хакимияте!

«ЭНИКС» АҖ исеменнән Сезне район оешуның 25 еллыгы белән тәбриклибез. Чирек гасыр – яшьлекнең тормыш тәҗрибәсе, максатларны билгеләү, яңа офыкларны ачыклау белән нығыган чагы. Районыбызның киләчәге якты булсын. Моның өчен предприятиеләр дә, кешеләр дә, көч-егәр дә бар!

Фото «ЭНИКС» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды

Реклама

ГЫЙЛЕМ АША – **ЙОЛДЫЗЛАРГА**

Татарстан берничә ел рәттән мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадаларында җиңүчеләр саны буенча беренче өчлеккә керә, бу җәһәттән ул Мәскәү белән Санкт-Петербургтан гына калыша. Тотрыклы рәвештә лидерлар арасында булуда Республика олимпиада үзәгенең роле бик зур.

– Мин олимпиадалар белән дүрт ел шөгыльләнәм. Татарстанда, Мәскәүдә һәм Сочидагы «Сириус» укуукыту үзәгендә тренировкаларда еш катнашам. Бу ел мәктәптә укуга гына багышланмады, максатлы рәвештә ярышларга әзерләнү белән дә үтте, – дип шәрехли информатика буенча 31нче халыкара олимпиадада катнашып, алтын медаль яулаган Илдар Гайнуллин. Ул Н. И. Лобачевский исемендәге лицейның 11нче сыйныф укучысы. Информатика буенча төрле олимпиадаларда күп тапкырлар җиңгән яшь программист үз профилендә теләсә кайсы вузга укырга керү хокукына ия. Иң кыены – сайлап аласы гына калган…

Ил күләмендә белемнәрен күрсәтеп, абруйлы бәйгеләрдә җиңү мөмкинлеге һәр укучыда булырга тиеш. Татарстан җитәкчелеге берничә ел элек шулай хәл итә һәм олимпиада үзәге ачу башлангычын хуплый. Үзәк 24 гомуми белем бирү предметы буенча 9–11 сыйныф укучылары өчен Бөтенроссия олимпиадасының төбәк һәм йомгаклау этабын, шулай ук республика күләмендә 4–7 сыйныфлар өчен математика, рус һәм инглиз теле буенча, 8 сыйныфлар өчен Бөтенроссия олимпиадасы исемлегеннән барлык предметлар буенча, 4–11 сыйныф укучылары өчен Татарстан һәм татар халкы тарихы, татар теле һәм әдәбияты, көнчыгыш телләре, рус теле һәм әдәбияты, геология буенча, авыл мәктәпләренең 7–11 сыйныф укучылары өчен («Олимпка юл» олимпиадасы), кадет мәктәпләренең 7–11 сыйныф укучылары өчен «Ватанга хезмәт итәм! Халыкка хезмәт итәм!» – барлыгы 26 олимпиаданы оештыру һәм уздыруны үз өстенә ала. Үзәк структурасына караган «Дуслык» сәламәтләндерү-белем бирү комплексы ел саен укырга һәм тренировкалар үтәргә дип килгән 10 меңнән артыграк баланы кабул итә. Республика күләмендәге берничә олимпиадада Татарстаннан гына түгел, элекке БДБ илләреннән вәкилләр дә катнаша, шулай ук чит илләрдәге татар диаспорасыннан катнашучылар да бар. Моннан тыш, үзәк Бөтенроссия олимпиадасының берничә йомгаклау этабын да оештыра. 2019–2020 нче уку елында республикада тормыш иминлеге нигезләре, биология һәм сәнгать буенча олимпиадалар катнашучыларын көтәләр.

Оешканнан алып үткән 5 ел эчендә үзәкнең җитәкчеләре һәм белгечләре республика һәм федераль дәрәҗәдәге Мәгариф һәм фән министрлыгы ярдәме белән зур уңышларга иреште. Иң зур уңыш – Бөтенроссия мәктәп олимпиадасының йомгаклау этабында абсолют җиңүчеләр һәм призёрларның саны артуы. 2019 елда Татарстаннан 148 мәктәп укучысы олимпиада бүләгенә лаек булды (алдагы ел белән чагыштырганда, 9 га артыграк). Чагыштыру өчен: исемлекнең лидеры Мәскәүдә 944 җиңүче һәм призёр, Санкт-Петербургта – 185. Аннан соң Татарстан бара, аның артыннан шактый зур аерма белән – Мәскәү өлкәсе (79 җиңүче һәм призёр). Исегезгә төшерәбез, җиңү дә, призлы урын да укучыга Россиянең югары уку йортларына автомат рәвештә керү хокукы бирә. Тел буенча турларда җиңү чит илгә юл ача.

Олимпиадага әзерлек – марафон ул. Әзерлекне үз вакытында башлаган кеше җиңүгә ирешә.

– Татарстанда Бөтенроссия һәм республика күләмендәге олимпиадаларда җиңүчеләр Казан белән Яр Чаллыдан гына түгел, Түбән Кама, Саба, Бөгелмә, Югары Ослан муниципаль районнарыннан да бар, – ди Республика олимпиада үзәге директоры Гөлнара Исламова. – Андый күрсәткечләрнең тотрыклылыгы методик эшнең дөрес оештырылуы турында сөйли. Бу ата-аналарның, педагогларның, мәктәпнең һәм муниципалитетның бер команда булып эшләве нәтиҗәсе. Олимпиада предметның мәктәптәге курсына караганда күпкә тирәнрәк. Бала үзе генә җиңә алмый. Педагогларның һәм методистларның игътибары, тырышлыгы кирәк. Алар өчен без даими рәвештә семинарлар үткәрәбез, олимпиада биремнәрен мисалларда эшләп һәм аңлатып күрсәтәбез. Безнең бергәләп эшләвебезнең нәтиҗәсе республиканың гомуми белем бирү оешмаларында сәләтле балаларны үстерү концепциясе эшләнеп, куллана башлагач һәм тиешле юл картасы эшләнгәч, тагын да зуррак булачак. Ачык бурычлар куеп эшләгәндә генә, без уңышка ирешәчәкбез!

Хөрмәтле Тимур Лазович!

Сезне Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарының 25 еллыгы белән тәбрик итәбез! Республика олимпиада үзәге Авиатөзелеш районы территориясендә урнашкан. Биредә бай интеллектуаль һәм сәнәгать мирасы бар. Без бу традицияләрне дәвам итүебезгә шатбыз һәм безнең укучылар район, шәһәр, республика горурланырлык нәтиҗәләргә ирешсен өчен барысын да эшлибез!

Фото Республика олимпиада үзәгеннән алынды

«БЕЗДӘ ДӨНЬЯГА КИҢ КАРАШ ҖИТМИ...»

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев республикада билгеле шәхес. Ул безгә китаплы балачагы, рок музыкалы үсмер чагы, джинслы яшьлек чоры турында сөйләде. Әлбәттә, татар телебезнең киләчәге, ул өлкәдәге проблемалар хакында да.

Автор:
Руфия Фазылова

«КЫЕН ДА, РӘХӘТ ТӘ»

Милләтебезнең олпат язучыларыннан саналган Аяз Гыйләҗев тормыш иптәше Нәкыя ханым белән өч ул үстерә. Арттыру булмастыр, Гыйләҗевлар нәселен дәвам итүче бу ир-атлар берсе дә тел-теш тидерә торган түгел – зыялы, белемле, абруйлы... Моның сәбәбен Искәндәр Гыйләҗев менә нәрсәдә күрә:

– Аяз Гыйләҗевның улы булу бер яктан бик рәхәт, чөнки әти җитди, дәрәҗәле кеше иде. Дәрәҗә булгач, мөмкинлекләр дә була. Әлбәттә, совет вакытында әллә нинди зур дәрәҗәләр турында сөйләп тә булмый, чагыштырмача, дип әйтик. Әти акыллы, җаваплы кеше булды. Шуңа күрә безгә – өч улына шул гаиләдә тәр-

Фото: «Татар-информ» МАнан алынды

бияләнү һичшиксез рәхәт иде, чөнки безгә игътибар, мәхәббәт, чын мәгънәсендә матур тәрбия насыйп булды. Икенче яктан авыр. Чөнки җаваплылык арта, әтинең исеменә тап төшерүдән куркасың. Әти турында һәрвакыт чамалап сөйлим. Әтинең шәхесе шулкадәр зур, киң, катлаулы, аның турында нәрсәнедер дөрес әйтмәсәм, үземә уңайсыз булачак.

Әти белән бергә әнине дә искә аласым килә. Аллага шөкер, ул бүген дә исән-сау, бик актив. Алар гомер буе бер-берсен тулыландырып тордылар. «Ярты» дип әйтәләр бит әле, менә ул гыйбарә – алар турында. Икесе бер якка карап яшәделәр. Тормышка, иҗатка мөнәсәбәтне күздә тотам. Әни бүген дә үзен Аяз Гыйләҗев хатыны итеп тоеп яши, һаман да шул иҗади казанда кайный. Әтинең мирасын популярлаштырырга, алга алып барырга тырыша. Әти исән чакта да өйдәге эшләрне, балалар тәрбияләүне үз өстенә алды, шул рәвешле иренә язучы буларак шартлар тудырды. Тагын бер мөһим нәрсә – әти бит репрессия корбаны. Япь-яшь килеш курыкмыйча аңа кияүгә чыгуы, ирен хөрмәтләп яшәве – әнинең гаҗәеп көчле хатын-кыз булуы турында сөйли. Без боларның барысын да аңлап, белеп үстек. Әти-әнигә карата хөрмәт, алар белән горурлану – өчебезгә дә этәргеч, көч бирде.

«ТУЛЫ КАНЛЫ ТОРМЫШ БЕЛӘН ЯШӘДЕК...»

Белгәнебезчә, 1960 нчы елларда беренче «хрущевка»лар барлыкка килә. Андый йортларда яшәү меңләгән совет кешесенең хыялына әйләнә. Гыйләҗевларга бу бәхет чагыштырмача тиз насыйп була...

– Өйләнешкәч тә әти белән әни Яңа бистәдә агач йортта бүлмә арендалап яшәгән. 1961 елда, миңа өч яшь булганда, әтигә фатир биргәннәр. Балачак, үсмер елларым әнә шул Воровский урамы, унтугызынчы йортта узды. Әле дә хәтерлим: биш катлы йортның дүртенче катындагы ике бүлмәле зур булмаган фатир иде ул. Әни һаман әйтә: «Фатиргa аяк баскач та, моның барысы да безгәме икән дип гаҗәпләндек», – ди. Яңа фатирга биш кеше күченгәнбез – әти, әни, әби, мин һәм яңа туган Мансур энем. Безнең беренче подъезд бик кызык иде. Бишенче катта – язучы Газиз Мөхәммәтшин, тагын дүрт-биш рәссам яшәде. Күңелле итеп, гаиләләр белән аралаша идек.

Хәзерге көн күзлегеннән караганда тар, кечкенә әлеге фатирда 1971 елга кадәр яшәдек. Әле 1968 елда өченчебез Рашат та туды. Тик кысан, кыен булып бер дә истә калмаган. Киресенчә, аннан киткәч тә, шул фатирыбызны гел сагындык, искә алдык. Хәер, эш фатирда гына да түгелдер, ә яшәү рәвешендә. Тулы канлы тормыш белән яшәдек. Еш кына табигатькә чыга идек. Аеруча спектакльгә барулар истә калган. 7–8 яшемнән театрга йөри идем. Горький урамындагы бинага премьераларга барганым һаман да истә. Сәхнә артында бик күп артистлар белән аралаштым. Әле генә сәхнәдә күргән артист анда бөтенләй икенче яктан ачыла. Театр мохите бик ошый иде миңа. 1970 нче елларда театрның бөтен репертуарын белә идем.

Дөресен генә әйткәндә, әти режиссер булуымны теләде. Еш кына: «Әнә, Марсель абыеңа (Сүз Г.Камал исемендәге ТДАТ режиссеры Марсель Сәлимҗанов турында бара. – Авт.) кара, аннан үрнәк ал», – дия иде. Алар үзара нык аралашып яшәде. Тик мин үземдә андый сәләт тоймадым. Шуңа да әтинең хыялын тормышка ашырып булмады. Әти бик акыллы кеше иде. Безгә беркайчан да ниндидер таләпләр куймады. Киңәш бирә, фикерен әйтә – ләкин без һәрвакыт үз теләгебезчә хәл иттек. Иң әһәмиятлесе – гаилә корган вакытта да ул безгә ирек бирде. Югыйсә аларның безнең өчен үз кандидатуралары бар иде. Ләкин өчебез дә үзебез сайлаган кызларга өйләндек.

«БЕЗ ТЫҢЛАГАН МУЗЫКАНЫ ӘТИ-ӘНИ ЯРАТМАДЫ»

Тургенев язган «әтиләр һәм балалар» проблемасы һәр чорда булган һәм булачак. Гыйләҗевлар гаиләсен дә урап узмаган ул...

– Без заманча шәһәр балалары булып үстек. Һәм мин ул заман кешеләре өчен «коточкыч» музыка тыңлый идем. Әти-әни бу мавыгуымны бер генә дә яратмады. Шуңа күрә мин аны бүлмәдә бикләнеп тыңладым. Яратмауның сәбәбе – инглизчә рок җырлар иде ул.

Без мәктәптә немецча укыдык, инглиз телен белми идем. Аңламасам да, әлеге җырларның көе, яңгыравы ошый иде. Мондый

«Әти белән әни гомер буе бер-берсен тулыландырып тордылар. Икесе бер якка карап яшәделәр. Әни бүген дә үзен Аяз Гыйләҗев хатыны итеп тоеп яши».

мавыгу кайдан барлыкка килдеме? Күренекле тәрҗемәче, каләм остасы Яхъя Халитовның улы Фәрит сәбәпче моңа: ул безне чит ил музыкасы белән җенләндерде. Займищеда күп кенә язучыларның бакчалары бар иде. Без шунда Әхсән Баян, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзиев һәм башка каләм ияләренең балалары белән аралашып яшәдек. Бер Фәритнең генә магнитофоны бар. Җыелабыз да аның янына музыка тыңларга барабыз. Нигездә ул инглиз группаларының җырларын тыңлый. Без дә аңа ияртдек.

Тагын шуны әйтим: ул язмаларны табу һәрвакыт бер маҗара иде. Пластинкалар сатуда юк, популяр музыканы радиодан табып яздырасың. Әлбәттә, андый җырның сыйфаты бик түбән була инде. Тик шулай да булмаганда ярап тора. 1972 елда миңа да магнитофон алдылар. Менә шунда яшерен коллекционерлар белән танышa башладым. Алар һәр районда бар иде. Сатып аласың, алыштырасың...

Киенү рәвеше дә бик кызык иде безнең. Әлбәттә, матур киенәсе килә. Башлангыч мәктәптә әнинең зәвыгы буенча киендек. Безгә ошамаса да кидек. Хәер, мәктәптә укыганда кием сайлау мөмкинлеге булмагандыр да. Ә менә университетка укырга кергәч, матур киенергә теләк нык артты. Үземнең мөмкинчелекләр юк. Бөтен кеше джинс чалбар кия, аеруча икенче, өченче курсларда. Шундый бер чалбарның бәясе 160, 170 сум иде. Levi's, Wrangler фирмаларының джинсысы бар икән синдә, бетте, кызлар егылалар. Сиңа урамда

борыла-борыла карыйлар. Әйе, Һиндстаннан кайткан джинс чалбарлар бар иде, тик ул чүпрәк кенә, бернигә дә яраксыз. Ә чын джинс азрак кына таушалган булырга тиеш. Әти минем бу зур хыялым турында белә иде. Берсендә шулай аның Ригада яшәүче якын дусты – Константин Смирновтан посылка килде. Ачып карасак – анда зәпзәңгәр Montana фирмасы джинс чалбары. Мин аны башта бик аңлап та бетермәдем, бактың исә, ул бик сыйфатлы бренд чалбар икән. Университетта барысы да шаккатты. Хәзер боларны балаларга сөйләсәң, аңламыйлар, бик гаҗәп хәл булып тоела аларга...

«Безгә – өч бертуганга игътибар, мәхәббәт, чын мәгънәсендә матур тәрбия насыйп булды».

«ТАТФАКНЫ САКЛАП КАЛЫП БУЛМЫЙ ИДЕ...»

Искәндәр Гыйләҗев Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетын ун ел җитәкләгән кеше. Тик университет федераль статус алгач, татфак бетүгә, дөресрәге реформалауга дучар булды.

– Татфакны элеккеге юнәлешендә саклап калып булмый иде, монысы көн кебек ачык. Университет – федераль структура һәм федераль университетлар системасы – Россия күләмендә планлаштырылган система. Гади генә итеп аңлатканда, безгә: «КФУ ул Татарстанныкы гына түгел», – диделәр. Монысы – бер. Икенчедән, татфак бик кечкенә бер факультет иде. Яңа шартларда андый кечкенә берәмлекләр калмады.

Мин консерватор кеше, хәзерге көндә барган күпчелек реформалар, үзгәрешләрне чынлап та кирәкме икән, дигән скептикларчарак фикердә торам. Кайвакытта бит реформаны реформа өчен эшлибез.

Татфакны университетның бер фишкасы буларак ясарга мөмкин иде. Зуррак итеп, төрки телләр юнәлешендәге гуманитар бер институт яки факультет буларак ачарга. Бөтен төрки дөньяны колачлый торган итеп... Мин фикеремне әйттем, ишетүче генә булмады...

Тагын милли университет ачарга да теләк-тәкъдимнәр булды. Монысы инде бик зур, яңа юл иде. Ләкин аңа да тормышка ашарга җай ачылмый, ни кызганыч.

Татар телен укытуга карата да фикеремне белдерәсем килә. Минем фикеремчә, бөтен нәрсәне примитив хәл иттек. Артык гади аңладык. Татар телен дәүләт теле дип игълан иттек тә, шуның белән тынычландык. Аның курсын бит тирәнтен алып барырга иде. Шул исәптән, укыту методикасы да төрле булырга тиеш: татар авылында яшәүче укучы өчен – бер төрле, шәһәрдәге татар баласы өчен икенче төрле, рус балалары өчен өченче төрле, татарча белмәгән татар балалары өчен дүртенче төрле. Ә без аны аңламадык. Кадрлар, дәреслекләр әзерләүдә дә ялгышлар җибәрдек. Юк, мин акланмыйм да, мактанмыйм да. Уйлаганнарымның күбесен тормышка ашыра алмадым. Шулай да тырышып карадым. Мисал өчен, дәреслекләрне үзгәрттү. Татфакның деканы булган вакытта, укытучылардан дәреслекләрне үзгәртергә дигән таләп куйдым, ә алар миңа: «Минем дәреслек бар бит инде», – диләр. Һич онытмыйм: яшьрәк буын вәкиле дәреслек язды, өлкәнрәк яшьтәгесе миңа килде дә: «Мин эшләгән дәреслек бар бит, икенчесе нәрсәгә?» – диде. Бу – безнең татарлык. Безгә дөньяга һәм үзебезгә киң караш җитмәде һәм җитми. Без артык шапырынабыз, артык мактанабыз. Ә проблемаларга киң караш белән карап, аларны чишү юлларын күрмибез.

«ЭНЦИКЛОПЕДИЯЛЕ ХАЛЫК ТАРИХКА КЕРЕП КАЛАЧАК»

Искәндәр Гыйләҗев 2015 елның февраленнән бирле Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры булып эшли.

– Институтның үз миссиясе, вазыйфасы бар. Миңа кадәр дә зур эшләр эшләгәннәр. Исеменнән үк күренгәнчә, без зур белем өчен җаваплы. Һичшиксез, энциклопедияле халык тарихка кереп калачак. Татар энциклопедиясенең рус телендә 6 томы инде дөнья күрде. Татарчасының алтынчы томы ике бүлектән торачак, чөнки ул артык күләмле булып чыкты. Энциклопедия үз эченә татар халкын һәм Татарстанны алды. Бөтен тармакларга да кагыла: тарих, мәдәният, икътисад, табигать... Әлбәттә, анда татар исемнәре генә түгел, ә республика үсешенә, тарихына өлеш керткән башка милләт вәкилләре дә, аерым кешеләр дә керде.

Без энциклопедия институты гына түгел, төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның тормышына кагылышлы басмалар да әзерлибез. Төрле өлкәләрне колачларга тырышабыз. Күптән түгел табигатькә багышланган бик эчтәлекле энциклопедиябез дөнья күрде. Тагын бер әһәмиятле эшебез – Татарстандагы торак пунктларга багышланган энциклопедия. Ул өч томда булачак. Аның беренче томы узган ел басылып чыкты. Бу басмалар сыйфатлы кәгазьдә, матур итеп эшләнгән. Әмма аларның тиражлары әллә ни зур түгел, 1 мең тирәсе генә. Шуңа сатуга да бик чыкмый, китапханәләргә җибәрергә тырышабыз.

Бүгенге көндә безнең төп максатларыбызның берсе – tatarica.org электрон энциклопедиясен ныклап торып эшләтеп җибәрү. Анда мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат урнаштыру, чөнки бу – заман таләбе. Затлы энциклопедия һәр кешегә барып җитми, ә менә электрон вариантта аны бик күпләр файдалана алачак. ■

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татар әлифбасы **НИЧӘ** ел яши

Танк училищесының туган көне **НИ ӨЧЕН** ике

Иске Татар бистәсе музее **КАЙДА** урнашкан

Карашай-Саклауда картлык **НИЧӘДӘ** башлана

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ

Яшәлгән һәр көн тарихка әйләнә. Ул фотосурәтләрдә, хатларда, әйберләрдә, җырларда, китапларда, мәктәп көндәлекләрендә, документларда кала... Соңрак, үткәннәрдәге әйберләргә карап, без кайчандыр, әле агачлар бик биек булган чакта, кичергән хисләрне, төсләрне, авазларны искә төшерәбез...

Татарстан Республикасы һәм аның адашы «Татарстан» журналының 100 ел яшәү дәверендә җөмһүриятебез халкында истәлекле әйберләр шактый тупланган. Гаилә тарихлары гаилә архивларында саклана, зур тарихны исә музейлар күз карасыдай саклый. Алар хәзер һаман саен күбрәк популярлаша һәм төрләнә, чөнки тамырларыбыз, бабаларыбыз, гореф-гадәтләребез белән кызыксыну сүнми, бәхеткә, арта бара.

Республикабыз кебек үк 1920 елда туган «Татарстан» журналы үзенең 100 яшьлек юбилеена музейлар марафоны үткәрергә – җөмһүриятебезнең гадәти булмаган 100 музеенда булырга карар кылды.

Бүген сезнең игътибарыгызга шундый беренче җиде музейны тәкъдим итәбез.

2

иң **ГЕРОИК.**
ТАНК УЧИЛИЩЕСЫ МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча

1

иң **ГАЗИЗ.**
ӘЛИФБА МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча

3

иң **МИЛЛИ.**
ИСКЕ ТАТАР БИСТӘСЕ МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча



иң
КОРПОРАТИВ.
ЯШЕЛ ҮЗӘН СУГЫШЧАН
ҺӘМ ХЕЗМӘТ ДАНЫ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА



иң
ОРИГИНАЛЬ.
ТУ-144 ИНТЕРАКТИВ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

иң
САМИМИ.
ЗӨЯ ТАРИХЫ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

иң
КЫЗЫКЛЫ.
ЭДУАРД ЭВЕРСМАН
ИСЕМЕНДӘГЕ ЗООЛОГИЯ МУЗЕЕ

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

Автор:
Руфия Фазылова

ИҢ ГАЗИЗ.
ӘЛИФБА МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча

Әлифба гомере өчен 50 ел вакыт күпме? Тарихтан күргәнебезчә, замана җиле, сәясәт белән бәйле әлифбалар егерме, утыз ел саен үзгәреп торган.

Ә менә 1965 елда гамәлгә кергән әлеге әлифба 50 елдан артык яшәде. Сәләй Гата улы Вәгыйзов белән Рәмзия Гыйләҗ кызы Вәлитова эшләгән әлифбаны күздә тотам. Мөгаллимнәрнең язмышы турында ишеткәч: «Шәп әйберләр зур фаҗигаләрдән соң гына туа, ахры», – дип уйлап куйдым... Иң сөендергәне шул: гомер буе Арча педагогия училищесында белем биргән ирле-хатынлы укытучыларның истәлеге, якты эзе югалмаган. Арчадагы Әлифба музее турында әйтүем.

АЛТМЫШ БИШ ТЕЛДӘ...

Әлифба музее Россиядә бер генә. Алай гына да түгел, музей хезмәткәрләре аны дөньяда бер генә, диделәр. Шуңа күрә дә аларга Норвегия,Финляндия, Германия, Франция, Италия, АКШ, Кытай һәм башка илләрдән экскурсиягә киләләр. Кунаклар, беренче эш итеп, туган телләрендәге әлифбаны эзли башлый. Әгәр тапсалар, сабый бала кебек сөенәләр икән.

– Әйе, музейның даны ерак-ларга таралган, – диде Әлифба музее җитәкчесе Дамир Таҗиев. – Безгә дип махсус атап килүчеләр дә бар. Узган ел булган бер хәлне сөйлим әле. Ингушетиянең мәгариф министры килгән иде. «Сезнең хакта интернеттан укып белдем. Музейда ингуш телендәге әлифба бармы?» – диде. Киштәләргә тезелгән әлифбалар арасыннан ингушныкын алып бирдем. И, сөенде инде министр!

Фото: Лилиана Вәлитова

БУКВАРЬ
ӘЛИФБА
Нн
На-на-на!
у
ун
а
на!
ун ул ал
а-на а-ла
Ул а-на.
А-на а-ла.
ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОГОВОР №
Р.Г.ВӘЛИТОВА
С.Г.ВАГЫЙЗОВ
Әлифба
ТАТКНИГОИЗДАТ

– Безнең музей – Әлифбалар тарихы гына түгел ул, ә ата-бабаларыбызның ничек итеп гыйлем үрләрен яулаулары турында да, – диде Дамир Таҗиев.

«Бу бит мин укыган әлифба», – диде. Безнең белән туганнарча саубуллашты.

Музейда бүген барлыгы 65 телдәге әлифба бар. Башта шуны әйтим: нәкъ егерме ел элек оешкан бу музейны болай дан казаныр дип уйламаганнар. Ниятнең һәм эшнең башы татар әлифбасы авторлары – Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитовага барып тоташа. Мөгаллимнәр, эштән киткәндә, Арча педагогия көллиятенә үзләре «тудырган» әлифбаны, башка кадерле ядкарьләрне бүләк итә. Шул вакытта көллият коллективы, үзара киңәшләшкәннән соң, Әлифба музее булдырырга карар кыла.

Музей җитәкчесе Дамир Таҗиев безгә менә ниләр сөйләде:

– Карар кабул ителгәч, көллият укытучылары төрле телләрдәге әлифбаларны эзләү хәстәренә керешә. Тарих укытучысы Хөсәен Хәйруллин автоном республикаларга хатлар яза. «Әлифба музее ясыйбыз. Зинһар, шушы адреска үзегезнең телдә басылып чыккан әлифбаны салыгыз әле», – ди. Һәм, бүләк итеп, татар телендәге үзебезнең әлифбаны да юллый. Хатлар үзенекен эшли: бер-бер артлы әсбаплар килә башлый. Шул рәвешле төрле төбәкләрдән егермеләп әлифба җыела.

Егерме ел элек башлаган эш бүген дә дәвам итә. Укытучылар, берәр чит җиргә барса, әлифба эзли башлый. Бигрәк тә Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогия көллияте директоры Мусина Лилия Надыйр кызы бу эш белән яна икән. Кая гына барса да, берәр әлифба алып кайтырга тырыша ул.

Музейга елына күпме кеше килә дигәндә, мең ярымнар тирәсе, икән. Чит ил, Россия төбәкләреннән, якын-тирә районнардан, авыллардан да киләләр. Арчаны әйткән дә юк инде.

– Безнең музей – Әлифбалар тарихы гына түгел ул, ә ата-бабаларыбызның ничек итеп гыйлем үрләрен яулаулары турында да, – диде Дамир Таҗиев. – Менә, карагыз, 1778 елда Сәгыйть Хәлфин төзегән татар телендәге беренче әлифба. Ә менә монысы – Мәскәүдә 1634 елда басылган Василий Бурцовның беренче рус әлифбасы. Әлбәттә, болар күчермәләр генә. Ләкин бу бит – тарих. Монда төрле милләтләрнең тарихына сәяхәт кылып кайтырга була. Мәгълүм булганча, шәкертләр элегрәк укырга кайда яхшы мөгаллим бар, шунда юнәлгәннәр. Мисал өчен, күренекле дин белгече Габделнасыйр Курсави (1776–1812), Бохарада белем алып кайтканнан соң, туган авылы Курсада (Арча районы) мәдрәсә оештыра. Бирегә бөтен тирә-яктан укырга килә башлыйлар. Шулай ук ул чорда Ташкичү авылында да көчле мәдрәсә эшли. Андый гыйлемле мөгаллимнәр башка төбәкләрдә дә була. Безнең музейда шул чорга караган шактый дәреслек, аларның күчермәләре бар. Боларның барысы турында да кунакларга бәйнә-бәйнә сөйлибез.

Илзидә Саттарова музей экспонатлары белән таныштыра.

«СИН МИННӘН ВАЗ КИЧ...»

Әлифба музеена җан өргән шәхесләр, арчалыларның хөрмәтле мөгаллимнәре – Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитовага аерым тукталмый мөмкин түгел. Бу исемнәр Арча педагогия көллияте студентларына гына түгел, ә бөтен татар дөньясына таныш. Әйе, ничә буын аларның «Әлифба»сы буенча укырга, язарга өйрәнде бит.

Баксаң, аларның язмышлары бик тә гыйбрәтле, хәтта ки фаҗигале булган икән. Мөгаллимнәрнең икесе дә Арча кешеләре түгел. Сәләй Вәгыйзов Самара губернасы Камышлы районы Байтуган авылында туып-үсә. Әтисе үлгәндә аңа биш ай гына була. Әнисе, сабыен күтәреп, кайнанасы яныннан китәргә җыенганда, әби кеше кырт кисә: «Шәригать буенча бала ир ягында үсәргә тиеш». Әби кулына калган Сәләй бу йортта озак яшәми. Әби-

се, сәламәтлеге начараю сәбәпле, онығын баласыз авылдашларына тәрбиягә бирә. Шул көннән башлап Сөләйман Хәлиуллин атлы малай Сәләй Вәгыйзовка әйләнә. Булачак мөгаллим унҗиде яшькәчә тәрбиядә була. Рәмзия Вәлитова исә Башкортостанның Стәрлетамак балалар йортында үсә. Ике ятим Казан педагогия институтында очраша. Шактый вакыт дуслашып йөргәннән соң, институтның соңгы курсында өйләнешәләр.

1937 елда яшь белгечләрне юллама белән Арча педагогия училищесына эшкә җибәрәләр. Ир белән хатынга зур булмаган торак бирәләр. Һәм шунда бер-бер артлы ике балалары – Камил белән Римма туа. Ә аннан соң сугыш башлана. Медицина тикшеренүе уздырмыйча да 1942 елда Сәләй Вәгыйзовны сугышка алалар. Ә аның күзе бик начар күрә торган була. (Гомер буе калын пыялалы күзлек киеп йөри). Мылтыктан ата алмаганлыгын аңлап, солдатка снаряд ташып торуны йөклиләр. Озак та үтми, Харьков янында отрядлары чолганышта кала, солдатлар барысы бергә әсирлеккә төшәләр. Сугыш бетеп, әсирлектән котылгач та, туган ягына кайтырга насыйп булмый аңа. Хыянәтче, дип, ун елга төрмәгә утырталар. Хатыны, ике баласын ияртеп, Печора елгасы тирәсендәге лагерьга ике ел рәттән бара. Шуннан кайткач, «хыянәтче ире янына йөрүче» хатынны эшеннән алалар, фатирдан куып чыгаралар. Ике баласы белән вакытлыча танышларына сыенган анага иреннән хат килеп төшә: «Рәмзия, баш тарт миннән. Хыянәтче иремнән ваз кичәм, дип, рәсми хат яз. Фамилияңне алыштыр. Шунсыз сиңа көн күрсәтмәячәкләр. Балалар турында уйла… Ә мин монда ничек тә түзәрмен, борчылма…» Рәмзия Вәлитова шулай эшли дә. Аны кире эшенә кайтаралар, тораклы итәләр.

Сәләй солдат, лагерь срогын тутырып, гаиләсе янына Арчага кайта. Аны элеккеге эшенә алмыйлар, район җитәкчеләре сүздән курка. Вак-төяк эшләрдә йөри. Аннан укучысы – районда җитәкче урында эшләүче Равил Галиәхмәтов Сәләй Вәгыйзовны Арчаның Мөндеш авылы мәктәбенә урнаштыра. Ә биш елдан соң, ул инде хатыны белән бергә Арча педагогия училищесында эшли башлый. Шул елларда Татарстан Мәгариф министрлыгы «Әлифба» китабына конкурс игълан итә. Сәләй Вәгыйзов белән тормыш иптәше бергәләп кульязма китап эшли. Аны Казанга алып барып, комиссиягә көч-хәл белән тапшыралар. (Кульязманы башта алмыйлар, янәсе, «Әлифба»ны галимнәр эшләргә тиеш. Ә алар кем?! Гап-гади авыл укытучылары). Дистәләгән эшләр арасыннан нәкъ менә Арча педагогия училищесы мөгаллимнәренеке җиңә! Укытучыларның кульязмалары 1965 елда басылып чыгып, бөтен татар мәктәпләренә таратыла. Соңрак Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова тагын 43 төрле дәреслек һәм методик әсбап эшли.

Күпме авырлыклар күреп тә, берберсенә һәм эшенә тугры калган ир белән хатын турында арчалылар бүген дә сокланып сөйли. Мәхәббәтләре кебек үк, гомерләре дә озын була: Рәмзия Вәлитова – 88 яшендә, Сәләй Вәгыйзов 96 яшендә дөнья куя.

…Әлифба музееның өч залы бар. Аның иң зуры – Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитовага багышланган. Һәр килгән кеше бу ике мөгаллимнең фаҗигале язмышын күз яше белән тыңлый икән. Кемдер аларны «татар әлифбасының әтисе белән әнисе» дип атаган. Мин дә килешәм. Арча якларына барып чыксагыз, һичшиксез, музейга кереп чыгыгыз. Беренчедән, яңадан балачакка кайткан кебек булырсыз. Икенчедән, фаҗигаләр аша килеп ирешкән бу тарихны без белергә һәм күңелдә сакларга тиеш…

КАЙБЕР ФАКТЛАР:

- Беренче славян әлифбасы Львов шәһәрендә басыла. Авторы – Иван Федоров. Унбишәр юллы кырык биттән торган әлеге беренче әсбапның бердәнбер данәсе Гарвард университетында саклана. (Аерым сәбәпләр аркасында Федоровның әлифбасы Россиядә популярлык казанмаган).
- Бик күп гасырлар буенча татар гаиләләрендә Коръән төп китап саналган.
- Беренче татар әлифбасын 1778 елда Сәгыйть Хәлфин төзи. Нәкъ шушы чорда 1 нче Казан ирләр гимназиясендә татар телен өйрәтү сыйныфлары ачыла. Хәлфиннең әлифбасы Мәскәү университеты типографиясендә басыла һәм берничә дистә ел татар телендә укырга-язарга өйрәнү өчен бердәнбер укыту әсбабы була.
- XX гасыр башын татар милләте өчен алгарышлы дәвер дип атап була. Күп кенә урыннарда кыска вакыт эчендә укытучылар әзерләү курслары эшли башлый. Биредә ирләр дә, хатын-кызлар да укый. Яңа дәреслекләр бастыруга зур игътибар бирелә. «Әлифба»да рус букварьларыннан алынган рәсемнәр күренә башлый. Дөрес, татар дәреслекләрендә сурәтләрнең урынсызлыгы турында каты бәхәсләр дәвам итә. Тик алдынгы карашлы авторлар текстларын барыбер рәсемнәр белән тулыландыра.
- 1919 елның 26 декабреннән 8 яшьтән 50 яшькә кадәр укый-яза белмәгән барлык кешеләрнең үз теләкләре буенча йә татар телендә, йә рус телендә белем алырга хокуклы булулары турында декрет чыгарыла.
- 1928 елда латин графикасы – Яңалиф кертелә. Яңалифтә 33 хәреф була. Ул 1938 елга кадәр кулланылышта була. Аннан кириллицага нигезләнгән татар әлифбасы керә.
- Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиев тарихка өч графикада татар әлифбасын эшләгән гаҗәеп шәхес буларак кереп кала. Башта – гарәп, латин графикасында, соңрак кириллицага нигезләнгән татар әлифбасы төзи.

100 ТАТАРСТАННЫҢ МУЗЕЕ

– Иң кыйммәтле экспонат – Александр Демидов кителе, – дип сөйли музей мөдире Альберт Гыймалетдинов.

ИҢ ГЕРОИК.
ТАНК УЧИЛИЩЕСЫ МУЗЕЕ

Быел Казан танк училищесы үзенең 100 еллык юбилеен билгеләп үтте. Ләкин бу – рәсми кабул ителгән дата гына, чынбарлыкта уку йортының тарихы иртәрәк башланган, 53 ел алданрак! Дәрәҗәле хәрби учреждениенең катлаулы хронологиясе һәм аның каһарман укучылары язмышы турында училище музееннан да яхшырак сөйләүче юк, әлбәттә.

– Бу урында музей рәсми рәвештә 1997 елның 20 июнендә ачылды. Мин курсант булганда, ул кечкенә генә кабинеттан гыйбарәт иде, – дип каршы ала кунакларны танк училищесы музее мөдире Альберт Гыймалетдинов.

Бүгенге көндә Танк училищесы музее – витриналар, модельләр, рәсемнәр, геройларның бюстлары һәм диорамалар белән тулы берничә аудитория һәм озын коридорлардан гыйбарәт. Бирегә килгән һәркемне кызыл келәмле юл музейның тарихи вакыйгалары буйлап сәяхәткә алып кереп китә….

Альберт Миңнегаяз улы нинди юнәлештә хәрәкәт итәргә кирәклеген аңлата:

– Музейны дүрт зонага бүләргә мөмкин. Беренчесендә 1866 елның 1 сентябреннән 1919 елга кадәрге тарихи вакыйгалар чагылыш тапкан. Икенчесе Бөек Ватан сугышы чоры турында сөйли. Өченчесе, 1963 елдан башлап, бүгенге көнгә кадәрге вакыйгаларны үз эченә алган. Дүртенче һәм, мөгаен, иң төп зал училищены тәмамлаучыларга багышланган.

ЮНКЕРНЫҢ ИПТӘШЛӘРЕ – МӨСЕЛМАННАР

Училище тарихы, чыннан да, ныклап өйрәнүне таләп итә. Башта аңа нигез салынуга бәйле ике төрле датага ачыклык кертик.

1866 елның 1 сентябрендә Казан Кремлендә Казан юнкерлар пехота училищесы ачыла. Аның казармалары ике катлы бинада (хәзер бирегә «Хәзинә» галереясы) урнашкан була. Шул вакыт арасында уку йорты тарихында 20 дән артык исем алыштыру һәм үзгәртеп кору була, һәм алар бүгенге көндә эшләп килүче Кызыл Байраклы Казан югары танк команда училищесы формалашуына китерә.

1917 елның ноябрендә әлеге хәрби уку йорты таркатыла, шуңа күрә аңа нигез салыну вакыты дип, 1919 елның 22 феврале санала. Ул чакта элеккеге училище базасында 1 нче Казан мөселман пехота команда курслары ачыла.

ДИОРАМА СУГЫШЛАРЫ УТЫНДА

Музейның тарихи зонасы экспонатлары арасында: юнкерлар училищесының көн тәртибе, аны ачу турындагы документлар, училищеның логотибы төшерелгән фарфор савыт-саба, фотографияләр һәм иң кыйммәтле экспонат – Александр Демидовның кителе бар. Училищены прапорщик булып тәмамлап, 1918 елда хәбәрсез югала ул. Гаиләсе Демидовның кителен, күкрәк билгесен, фотоальбомын, хатларын һәм офицер караватын 1917 елда музейга бүләк итә.

Әлеге карават Кызыл Армия сугышчысы манекены янына куелган, хәрби кеше кара яллы аты каршында башын игән килеш сурәтләнгән. Гомумән, музейны оештырганда хәрби киемле манекеннар күп кулланылган. Алар

Автор:
Алёна Кутыркина

Автор фотосы

штабның көндәлек тормышын күрсәтә, диорамаларда батырларча көрәшә... Һәрберсенең битенә буяулар белән төрле хискичерешләр ясалганы күренеп тора. Танылган Мадам Тюссо музее булмаса да, экспозициягә укучыларның шул рәвешле өлеш кертүе – музейны тагын да кызыклырак итә.

Тәэсирле диорамаларның берсендә Советлар Союзы Герое майор Иван Кобяков батырлыгы тасвирланган. Макетта – 1944 елның июлендә Марьина Горка шәһәре янындагы елганы кичү өчен көрәш фрагменты.

Тирә-якны утка тотучы немец танклары, үткен тимерчыбыклар, автомат һәм яраланган герой – сугышчы-манекен, өстенә ком сибелгән килеш, окопта сурәтләнгән. Инсталляция реаль чынбарлык кебек тәэсир итмәсә дә, яшь танкчыларның фантазиясе һәм диораманы ясауга керткән тырыш хезмәте соклану уята.

Күренекле Россия хәрби эшлеклеләре бюстларының макетлары.

ҖИҢ ЯКИ ҮЛ!

– Бәрелеш урыннарында эзтабар отрядлары тарафыннан табылган Бөек Ватан сугышы чоры әйберләре дә зур әһәмияткә ия. Болар – гильзалар, шлемнар, фронтның ике ягында сугышкан солдатларның шәхси әйберләре. Мин, килгән кешеләрнең йөзләренә карап, нәкъ менә шушы экспонатларның аеруча зур кызыксыну уятуын сизәм, – дип сөйли, ачык витриналарга ишарәләп, музей мөдире.

Күпсанлы сугышлардан гарипләнеп, вакыт үтү белән төссезләнеп беткән кораллар, снарядлардан тишкәләнгән каскалар да игътибарны җәлеп итә. Аларны караганда училищеның тарихи девизына әйләнгән «Җиң яки үл!» сүзләренең тирән мәгънәсе тагын да ныграк ачыла.

УЧИЛИЩЕ ГЕРОЙЛАРЫ

Кызыл келәмле юл безне тагын да түргәрәк алып керә, шартлаулар ишетелә башлый – бу залларда училище геройлары турында документаль фильмнар күрсәтелә. Күренекле хәрби эшлеклеләрнең йөзләгән бюст макетлары арасына эләгәсең.

– Күптән түгел шундый макет буенча Казанның 7 нче гимназиясендә безнең урта к укучыбызга һәйкәл куелды. Алексей Козин 1999 елда Россия Герое исемен алды. Училищены тәмамлаганнан соң, ул танк взводы командиры итеп билгеләнә һәм Дагыстанда хәрби бурычын үтәгәндә һәлак була.

КРЕМЛЬ КАРШЫНДА АНТ БИРҮ

Кызыл келәм безне музейның икенче ягына – хәрби киемнәр тарихы коридорына алып кил-

Музей экспонатлары XVII–XIX гасырлардагы хәрби формалар тарихы турында сөйли.

Танкист Зиновий Колобанов исемендәге ИС-3 хәрби танкы.

де, монда XVII–XIX гасыр экспонатлары куелган. Төрле төстәге кительләр эленгән витриналар ут белән бизәлгән, аларга медальләр һәм орденнар ялтыравы кушыла. Янәшәдә генә төрле елларга караган хәрби әйберләр: миналар, кораллар һәм элемтә чаралары. Бу тарихи чынбарлыкны портретлардан төрле чорлардагы училище җитәкчеләре күзәтеп тора кебек.

– Без һәрвакыт яңа экспонатлар эзлибез. Хәзер дә эзләнүдә, ләкин әлегә әйтми торабыз, сер булсын. Тапкач, сезгә беренче хәбәр итәрбез, – дип елмайды Альберт Миңнегаяз улы.

Сөйләшә-сөйләшә кительләр арасыннан барабыз, коридор азагында үтә дә таныш күренеш – Казан Кремленең Спас манарасы фонында яшь курсантлар ант кабул итә. Кремль каршындагы мондый тантаналар 1947 елга кадәр үткәрелгән. Шуннан соң ТАССРның Югары Советы исемендәге Кызыл Байраклы Казан танк техникасы училищесы таратыла.

Ә 1963 елның 31 маенда уку йорты ТАССРның Югары Советы Президиумы исемендәге Кызыл Байраклы Казан югары танк командасы училищесы буларак ачыла. Аның урыны да үзгәрә – училище Каргополь хәрби шәһәрчеге базасында урнашып, бүгенге көнгә кадәр шунда эшләп килә.

Ант бирү күренеше ярымтүгәрәк диварга ясалган, ә картинаның аргы ягыннан геройлар залына керү өчен юл ачыла.

ИҢ ТӨП ЗАЛ

– Биредә без иң күренекле чыгарылыш укучыларыбызны тупладык, алар арасында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган 68 кеше бар, шулай ук – 14 Россия Федерациясе Герое һәм 3 Социалистик Хезмәт Герое. Һәр батырлыкка аннотацияләр язылган, ә геройлар, беркем дә үпкәләмәсен өчен, алфавит тәртибендә урнаштырылган, – дип дәвам итә сүзен экскурсияне озатып йөрүчебез.

Зал диварлары фоторәсемнәр белән тулган, түбәнрәк дәрәҗәдәге геройларның шәхси әйберләре куелган: гитара, аккордеон, бокс перчаткалары, БЭФ-207 радиоалгычы…

Янәшәдә генә – әлеге училищены тәмамлаган хәрбиләрнең Дагыстан Республикасында күрсәткән батырлыгына багышланган макет. Сугыш таулар арасында урнашкан авылда бара. Уенчык машинаның 3 сантиметр калынлыктагы алгы тәрәзәсендә пулялардан калган 4 тишек, капотында пөхтә итеп автомобиль маркасы язылган. Макетның һәр детален игътибар белән карыйсың да, ирексездән үзеңне сугыш кырында кебек сизә башлыйсың…

ПАРАД ТАНКЛАРЫ

Экскурсияне тәмамлап, Альберт Миңнегаяз улы училище территориясендәге Мәңгелек ут янында торган танкны игътибар беләнрәк карарга киңәш итә.

– Бу кулланылыштагы Т-34 танкы. Элек монда эшләми торган танк иде, ә хәзер йөри торганын куйдылар һәм аны Советлар Союзы Герое, танк гаскәрләре генерал-майоры Иван Кобяков хөрмәтенә атадылар. Ул танк училищесына 1963 елдан 1975 елга кадәр җитәкчелек иткән. Янәшәдә тагын СУ-100, ИС-3 һәм «Катюша» тора. Алар Җиңү парадында ике тапкыр катнашып өлгергәннәр инде.

Кайчандыр әлеге училищены тәмамлаган хәрбиләрнең Дагыстан Республикасында күрсәткән батырлыгына багышланган макет.

ТЕРРИТОРИЯСЕНӘ КЕРҮ ТЫЕЛА ТОРГАН ХӘРБИ УКУ ЙОРТЫНДА УРНАШКАН ВЕДОМСТВО МУЗЕЕ ЭКСПОЗИЦИЯСЕН НИЧЕК КҮРЕП БУЛА СОҢ?

1 вариант: училище курсанты булырга һәм, ант итәр алдыннан, танкист көнендә музейга экскурсиягә эләгергә.

2 вариант: туганнар арасыннан биредә укучыны табарга, ант бирү яки чыгарылыш көнендә музейга керергә мөмкин.

3 вариант: училище җитәкчесе исеменә хат язарга була. Аның рөхсәте белән ялгызың гына яисә мәктәп укучылары, яшь армиячеләр яки ветераннар төркеме составында музейга килү мөмкинлеге бар.

4 вариант: «Музей язы»н күтәргә, «Ачык ишекләр көне» яки башка чаралар оештырылуы турында белешеп торырга кирәк.

Бүген танк училищесы музее витриналар, модельләр, рәсемнәр, каһарманнарның бюстлары һәм диорамалар белән бизәлгән берничә аудитория һәм озын коридорлардан тора.

ИҢ МИЛЛИ.
ИСКЕ ТАТАР БИСТӘСЕ МУЗЕЕ

«Татарстан» журналы версиясе буенча

Казан белән танышуны нәрсәдән башларга? Күптөрле вариантлар арасыннан үзебезнекен дә тәкъдим итеп карыйк әле. Тарихи чынбарлык ягыннан иң кыйммәтле урыннан башлагыз. Нәкъ менә бирердә халыкның гади көнкүреше гөрләп торган. Сүз башкалабызның иң күренекле урыннарының берсе – Иске Татар бистәсе турында.



Автор:
Алсу Троицкая

«ДӨРЕС» ТАТАРЛАР ҺӘМ «БАРАБЫЗ» ЧАНАЛАРЫ

Раштуа салкыннары чатнап тора һәм ишеп кар ява – татар ямчылары өчен менә дигән һава торышы бит бу! Көчле бураннан соң, алар Печән базары янындагы трамвай юлларын таптый башлыйлар. Рус хезмәттәшләре бүген эшкә чыкмый, трамвай да маршрутка баса алмый! Шуңа күрә православие бәйрәменә кемнәр күбрәк шатлана икән әле – христианмы, әллә мөселманмы? Күп тә үтми урамнарда әле тегендә, әле монда «Барабыз!» дигән өндәүләр ишетелә башлый. Тапкыр татарларның тиреле чаналарына пассажирлар сикереп кенә тора – тиеннәреңне санап өлгер. Дөресен әйтик, чаналар да зур түгел, бер генә кеше сыйдырышлы, утыргычлар урынына да печән-салам, тиреләр түшәп куелган. Ярар, бер куркынычы да юк, барыбер басып туңып тору түгел инде. «Барабыз! Бара-быз! Ба-ра-быз!», – ямчыларның карлыккан тавышлары гөрләп торган базар шавына кушылып китә...



– Ә монда без кунакларга фотосессия ясарга тәкъдим итәбез, – дигән тыныч тавыш ярминкәнең шау-шуын таратып җибәрә. Бүгенге көн чынбарлыгына кире кайтаручы бу кеше – **Рөстәм Муллагалиев**, тарих фәннәре кандидаты, «Татарская слобода – Татар бистәсе» экскурсоводы. Аның фотосессия турындагы тәкъдиме туристларда, гадәттә, зур кызыксыну уята. Чаналы ат иң кызыклы урында тукталган бит. Алда да, артта да, чын фотографияләр нигезендә эшләнгән шәһәр панорамасы. Артта – Дүрт Евангелист чиркәве биеклегеннән Казан күренеп тора, ә алда – Париж Коммунасы урамы – элеккеге Печән базары урамы күренеше.

– Сез аңлыйсыздыр инде, тапкыр татарларны кеше ташырга яхшы тормыш түгел, юклык чыгарган. Гаиләсен туендырырга акча эшләргә кирәк булган. Бу хакта рус авторлары тарафыннан язып калдырылган тарихи чыганакларда да әйтелгән. Замандашлар өчен бу яхшы үрнәк. Бүген барыбыз да проблемаларыбызны хакимият хәл иткәнен көтәбез, ә ата-бабаларыбыз акча эшләү ысулларын үзләре тапкан. «Менә болар – дөрес татарлар», – дип көлә безнең гид.

Фото: Александр Ефремов


Урам як тәрәзәсе.

КАЙБЕРЛӘРЕ ИНДЕ ЮК ТА...

Кызыклы «Татар бистәсе» музеена Бауман урамыннан җәяүләп 15 минут кына барасы, ул Казанның чын тарихи үзәгендә урнашкан. Аның беренче залы – XX гасыр башындагы Татар бистәсенең нинди булуы турында сөйли. Әлеге макет Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты хезмәткәрләре тарафыннан эшләнгән.

Кайбер корылмаларның масштаблары чынбарлыкка караганда зуррак итеп эшләнгән. Хәзерге вакытка кадәр сакланмаган ике чиркәү кызыл төс белән билгеләнгән. Мехчылар мәдәният йорты янындагы койма белән әйләндереп алынган территория – Екатерина чиркәвеннән калган бердәнбер истәлек. Ә менә Дүрт Евангелист чиркәве урынында бүген бушлык түгел. Чиркәүне шартлатканнан соң, аның урынына «Валтреста» торак йорты төзелә. Татарстан һәм Мәрҗани урамнары чатындагы дугасыман фасадлы сары йорт башка биналар арасыннан әле дә күзгә ташланып тора.

Макетта күренекле табиб, галим, этнограф Карл Фукс йортын да җиңел генә табарга мөмкин, кайчандыр анда Александр Пушкин да кунак булып киткән. Худяков урамындагы Изге Ана иконасы, Тихвин гыйбадәтханәсе дә күренә. Иске Татар бистәсенең башка корылмалары да...

Иске Татар бистәсе макеты.



«Татар бистәсе» музееның Көнчыгыш залында торган әлеге сандык Иван Алафузовның җитен эрләү фабрикасында эшләнгән. 1865 елда ачылган әлеге фабрика Урал, Идел буе һәм Себер текстиль сәнәгатендә иң алдынгы була, ул инде 1890 елга ук халыкара күргәзмәләрдә күпсанлы медальләр яулый. Иван Алафузов, замандашлары сүзләренә караганда, чын хезмәт кешесе була. Беренче гильдия сәүдәгәре, «мануфактур-киңәшче», Казанның нәселдән күчүче мактаулы гражданины, Россия, Персия, Черногория, Австрия орденнары иясе.

БУРЖУАЗИЯНЕҢ ТЫЙНАК МАТУРЛЫГЫ

Музейның Көнчыгыш залы 1906 ел ахырында Казанда ачылган легендар Көнчыгыш клубы стилендә эшләнгән, экскурсовод дәвам итә:

– Бу үзенә күрә дөньяви татар салоны. Татар җәмгыятенең европалаша башлавы дисәк тә була. Без Европа интерьеры мисалында татар йорты үзенчәлекләре турында да сөйлибез. Бай татар йорты турында.

Чыннан да, XX гасырның беренче еллары татар җәмгыятендә трансформация башлану вакытына туры килә, буржуазия вәкилләре тормышында бигрәк тә зур үзгәрешләр була. Әйтергә кирәк, татар байлары яшәгән йорт русныкыннан шактый аерылып тора. Бер яктан, пианино, журнал өстәле, канделябр кебек татарларга хас булмаган интерьер предметлары барлыкка килә… Икенче яктан, йорттагы татар хатын-кызларының традицияләре, гореф-гадәтләре чагылыш тапкан көнкүреш сакланып кала. Мөселман хатыннары яулыктан йөргәннәр, бары тик иң алдынгы карашлы гүзәл затлар гына XX гасыр башында кечкенә калфаклар кия башлый.

XX гасыр башында Казан байларының йортларында татарлар өчен хас булмаган интерьер әйберләре барлыкка килә башлый.

СЕНСОРЛЫ ӨСТӘЛДӘ – БҮГЕНГЕ ТАРИХ

Ислам традицияләрен һәм европалаша башлау сыйфатларын үзенә берләштергән кызыклы һәм кабатланмас җәмгыятьнең оешу тарихы, Иске Татар бистәсен төзү принциплары, аның тарихында булган янгыннар һәм, ниһаять, Казан татарларының үзләре турында без музейның Көнчыгыш залында урнашкан уңайлы урындыкларга утырып, 10 минутлык фильмнан белә алабыз. Гомумән, музейның һәр залында бистәнең тарихы белән якыннан таныштыра торган заманча гаджетлар һәм интерактив мөмкинлекләр бар, алардан һәр кунак файдалана ала.

«Татар бистәсе» музее бинасы үзе дә тарихи яктан кызыклы. XIX гасырда йорт бер катлы булган, соңрак аны өстәп төзегәннәр. Залларның берсендә менә шундый кирпеч түшәмнәрне дә күрергә мөмкин.

ЧӘЙ ГЕНӘ БУЛСЫН...

Музейның соңгы залында образлар һәм мәгънәләрнең гамәли әйберләрдә чагылыш табуын күзәтеп була. «Десертка» биредә... десерт белән чәй тәкъдим итәләр. Иң тәмле һәм күтеп алынган зал. Бигрәк тә балалар өчен. Кыш көне биредә татар халкының хуш исле чәй табыны артында туристлар җылына, җәйге эсседә хәл ала. Талкыш кәләвә, чәкчәк, как, кош теле кебек милли тәм-томнар, татар йорты күренеше һәм чәй эчү традицияләре турында кунакларга чын татар әбисе сөйли. Интерактив әби.

БЕР ГЕНӘ ХАЛЫК ТА МӘДӘНИЯТТӘН БАШКА ЯШИ АЛМЫЙ

Рөстәм Муллагалиев, хикәясен тәмамлап, болай ди:

– Мин, бирегә беренче тапкыр килгәч, таң калдым! Ә хәзер үзем бик теләп кунакларга халкыбыз, аның тарихы һәм традицияләре турында сөйлим. Минемчә, кешенең культурасы аның тарихка мөнәсәбәте аша билгеләнә. Дөресен генә әйткәндә, күпләребез үз халкының мәдәни коды турында яхшы белми. Ә ул, күп нәрсәне логика һәм аңлаешлы системага салып, тарихи һәм бүгенге вазгыятьнең мәгънәсенә төшенергә ярдәм итә. Тагын нәрсә өстәп әйтергә инде? Килегез...

Бу – татар йорты интерьеры. Почмакта мич торган, аның тирәсенә казаннар, он, бал, тоз, шикәр тутырылган чүлмәкләр куелган. Гади, әмма нык өстәлләр һәм сәкеләр күпсанлы кунакларны сыйдыра алган.

ИҢ КОРПОРАТИВ.
ЯШЕЛ ҮЗӘН СУГЫШЧАН ҺӘМ ХЕЗМӘТ ДАНЫ МУЗЕЕ

Кайчандыр, бик ерак 1895 елда, биредә чиркәү була, ә 1917 елдан алып 1970 елга кадәр бина завод идарәсе вазыйфасын үти. 1976 елда тарихи бинада предприятиенең Сугышчан һәм хезмәт даны музее урнаша.

Бүген музей сөттәй ак фасады һәм аны бизәгән матур йөзлекләре белән әкияттәге кечкенә ызбаны хәтерләтә. Һәм бу бина – заманча кораблар һәм суднолар заводы музее – без күрергә күнеккән дан музейларыннан аерылыбрак тора шикелле. Тик бу беренче карашка гына шулай. Чөнки завод музее турист өчен һәрвакыт икеләтә мәгънә белдерә. Бу бина үзе үк инде – А. М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводының тарихы.

«АЛТЫН» «МЕТЕОР»НЫҢ ЛЕГЕНДАР КАПИТАНЫ

Музейдагы иң кыйммәтле экспонатларның берсе – су асты канатлы «Метеор» елга пассажир теплоходының алтын макеты (Яшел Үзән заводы әлеге судноларны күп еллар дәвамында серияләп җитештерә). Танылган очучы, Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев 50 нче елларда капитан булган теплоходның кечерәйтелгән күчермәсе ул. Судно җитештерүчеләр бу каһарманны һәм аның үлемсез батырлыгын һич онытмыйча, аның турында кунакларга бик горурланып сөйлиләр.

Фотолар «А.М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы» АҖнең Сугышчан һәм хезмәт даны музееннан алынды

Реклама

ЕЛЛАР, ИНКЫЙЛАБЛАР ҺӘМ СУГЫШЛАР АША...

Гомумән алганда, завод тарихы 1895 елдан башлана, ул чакта бу төбәктә техник һәм пассажир флоты судноларын ремонтлау ихтыяҗы арта. Нәкъ менә шул вакытта, Элемтә юллары министрлыгының Казан төбәге җитәкчелеге карары белән, Паратск затонында Паратск судно ремонтлау остаханәләре булдырыла.

1918 елда алар Диңгез комиссариатының Идел суднолар төзү һәм механика автоном заводы итеп үзгәртелә. 1922 елда предприятиегә «Кызыл металлист» дигән исем бирелә.

1926 елда, тентлы беренче баржаны уңышлы төзеп бетергәч кенә, заводка төп юнәлеш – судно төзелеше тармагы билгеләнә. 1932 елда предприятиегә атаклы язучы, җәмәгать эшлеклесе, ирек өчен революцион рухта көрәшкән Алексей Максимович Горький исеме бирелә. Завод хөкүмәт тарафыннан куелган җитештерү программасын актив рәвештә һәм сыйфатлы итеп үтәп кенә калмыйча, үз белгечләренең квалификациясен күтәрү мәсьәләсен дә системалы хәл итү юнәлешендә эш алып бара.

Бөек Ватан сугышы елларында предприятие хезмәткәрләре тырышлыгы белән 70 тән артык бронекатер (барлыгы 154 берәмлек), су асты көймәләренә каршы сугышка торган дистәләрчә кораб, торпедалы катерлар, трал баржалары һәм Хәрби-диңгез флоты өчен буксирлар төзелә. Заводтан фронтка 4 миллионнан артык артиллерия снаряды, меңләгән зенит җайланмасы һәм пулемет, авиация бомбалары корпуслары, сапер көрәкләре, аэрочана өчен детальләр һәм башка бик күп продукция җибәрелә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: заводтан фронтка 2800 кеше киткән, ә сугыштан 830 кеше генә әйләнеп кайткан.

Предприятиенең Сугышчан һәм хезмәт даны музее ишек төбендә «Калюжный» исемле легендар бронекатер куелган постамент очраклы гына урын алмаган. Ул шушы заводта төзелә һәм 1942 ел ахырында суга төшерелә. Әлеге катер 1943 елда Каспий хәрби флотилиясе составына кертелә, ә 1944 елда Дунай хәрби флотилиясенә бирелә. Хәрби кораб командасы Бөек Ватан сугышы барышында үз бурычларын лаеклы рәвештә үти. 1967 елда бронекатер Измаил шәһәреннән үзенең туган ягына – Яшел Үзәнгә кайтарыла һәм заводның үзәк мәйданында мондагы эшчеләрнең иң канкойгыч сугыш елларындагы хезмәт батырлыгына, сугышчан каһарманлыгына һәйкәл итеп куела.

ТИҢДӘШСЕЗ МУЗЕЙ

2015 елда, предприятиенең 120 еллыгы уңаеннан, музей бинасы төзекләндерелә. 347 квадрат метр мәйданлы яңартылган музей комплексында завод тарихындагы чорларга бәйле рәвештә биш зал урын ала. Музей комплексының гомуми мәйданы 649 квадрат метрны тәшкил итә.

Бүген музей фондларында 17 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Болар – предприятие тарихы буенча документлар, төрле чорларга караган фотоматериаллар, уникаль тарихи предметлар, архив документлары; Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәренең орденнары, медальләре, бүләкләре һәм бүләкләү документлары, очерклары һәм истәлекләре; машина төзелеше тармагы эшләнмәләре, кораблар һәм судно макетлары, корабларның язулы нигез такталары, техник җайланмалар, предприятие эшчәнлегенең хәзерге юнәлешләре буенча материаллар, заводның «Горьковец» газетасы төпләнмәләре һәм башкалар. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: экспозиция музей экспонатлары һәм фотодокументлар белән тулыландуын дәвам итә, аларны завод эшчеләре һәм аларның туганнары бик теләп тапшыра.

Судно төзүчеләр хаклы рәвештә үз музейларын тәрбия, патриотик һәм туган якны өйрәнү эшчәнлегенең бер үзәге, заводның гына түгел, бөтен Яшел Үзән каласының бәһасез тарихи сәхифәләренең «йөзен билгеләүче» һәм «сакчысы» дип саныйлар. Биредә Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, Россия Федерациясе һәм чит илләрнең (Германия, Канада, Төркия, Иран, Вьетнам, Кытай һ.б.) иҗтимагый оешмалары, уку йортлары, предприятиеләр вәкилләре катнашында төрле чаралар, экскурсияләр даими үткәрелә, предприятиенең ветераннар советы активистлары һәм өлкән яшьтәге хезмәткәрләре хөрмәтләнә, заводның «Вдохновение» хоры иҗади эшчәнлеген дәвам итә.

Ел саен музейга 1500 дән артык кеше килә, шул исәптән – завод хезмәткәрләре үзләре дә.

«А. М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы» АҖнең Сугышчан һәм хезмәт даны музее эшчәнлеге ел саен югары бүләкләр белән билгеләп үтелә, алар арасында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы, «Советлар Союзы флоты адмиралы Н. Г. Кузнецов» юбилей медале, «Корпоратив музей-2019» Бөтенроссия конкурсының III дәрәҗә дипломы бар.

ИҢ ОРИГИНАЛЬ.
ТУ-144 ИНТЕРАКТИВ МУЗЕЕ

Музейда саклана торган борынгы әйберләр белән танышу хөрмәткә лаек гамәл – шигем юк. Тик шулай да гасыр тузаны кунган реликвияләрне өйрәнер урынына сезгә дөньяда тавыш тизлегеннән дә тизрәк оча торган беренче пассажир лайнеры штурвалы артына утырырга тәкъдим итсәләр, нишләрсез? Уйлап та торасы юк – әлбәттә, күк!

«Двигательне җирдә кабызу» төймәсенә басуга, пилот кабинасында бөтен нәрсә мизгел эчендә үзгәрә башлый. Двигательләрнең шавы көчәя бара, менә ул иң чик ноктага җитә, һәм син үзеңне старт алдыннан ракетада утырган космонавт кебек хис итә башлыйсың. Гадәти «аэрбасларның» гүләве Ту-144 нең дөбердәве белән чагыштырганда – черки бызылдавы кебек кенә.

СТАРТКА!

Аннан соң – тизлек алу, шулкадәр тиз ки, син очучы кәнәфиенә сеңгәннән-сеңә барасың. Штурвалны үзеңә тартасың, машина җирдән аерыла һәм, кисәк кенә болытларны энәдәй тишеп, югарыга омтыла. «Туполев» очкычының күтәрелгәндә яхшырак күрү өчен төшерелгән «торна борынын» урынына кайтарырга вакыт! Тумблерда чирткән тавыш – хәзер инде самолет ракетаны хәтерләтә. Берничә минут – һәм «ракета» тавыш тизлегенә кадәр тизләнеш ала. Сәгатенә мең ике йөз километр, мең өч йөз, мең биш йөз, ике мең…

Коточкыч тизлек! Ә монда, пилот кабинасында, приборлардагы күрсәткечләргә карап һәм корпусның вибрациясен тоеп кына, тизлекнең гаять зур икәнлеген аңлыйсың. Һәм тагын тыштагы тавыш – фюзеляж буенча каты кысылган һава ташкыны ысылдап үткәндәй тоела…

– Сез ишеткән тавыш, тойган йөкләнеш – Ту-144 экипажына чын очыш вакытында төшкән кебек үк, – дип, безне күктән җиргә кайтара экскурсоводыбыз – очучы-инструктор тавышы…

СТРАТОСФЕРАДА ҖИР НИЧЕК ШАУЛЫЙ

Юк, сез чыннан да совет «конкордының» пилот кабинасында, тик җирдә – Казанда. Илдә, юк, мөгаен, дөньяда да беренче Ту-144 очкычы интерактив музеенда. Ул КМТТУ-КАИ тырышлыгы белән ачылды. Ә инде командир кәнәфиендә, чын штурвал артында утырып, «чын-чынлап» очу мөмкинлеге, әлбәттә, лайнер-музейның төп «фишкасы».

– Самолёт, экипаж кабинасы, приборлар – барысы да чын. Алай гына да түгел, безнең кабинада тулы интерактив, аэродинамик платформага кадәр, – дип сөйли Алинә Хәбибуллина, КМТТУ-КАИның җәмәгатьчелек белән элемтәләр идарәсе башлыгы урынбасары. – Гади генә әйткәндә, пилот кәнәфиенә утырган кешедә тавыштан тизрәк тизлеккә ия самолёт белән идарә итү иллюзиясе туа: һавага күтәрелү, шәһәр өстеннән очып үтү, төшеп утыру…

БЕЛЕШМӘ

Борт номеры 77107 (завод номеры 05-1) булган Казан Ту-144 очкычы– Советлар Союзында Туполев ТКБнда эшләнгән беренче тавыштан тизрәк очучы пассажир самолётлары семьялыгы вәкиле. Беренче мәртәбә һавага 1975 елда күтәрелә. Сынау очышларында кулланыла. Очыш массасы 195 тонна (һәм коммерция йөкләнеше 15 тонна) булган очкычның очыш ераклыгы 3080 км ны тәшкил итә. 77107 номерлы борт Ту-144 самолётлары паркында иң зур очу сәгатенә ия: 830 сәгать һәм 455 күтәрелү-төшү.

Автор:
Әскәр Сабиров

Фотолар КММТУ-КАИ матбугат хезмәтеннән алынды

Чыннан да, тулы иллюзия. Ә алган тәэсирләр – бернәрсә белән дә чагыштырырлык түгел. Заманча берәр «боингтан» тавыш тизлегеннән дә тизрәк очучы Ту-144 пассажир самолётына күчеп утыру – балалар каруселеннән соң «американ тавында» атынуга тиң. Һәм бу музей тудырган тойгылар гына түгел. Әйтик, мәсәлән, ерак 1977 елда совет «суперсоникгында» Мәскәү – Алма-Ата рейсы буенча ничек очуы турында бер пассажир болай дип сөйли: «Иң кызыгы – очкычны уратып алган зур тизлекле һава ташкыны. Төгәлрәге, Ту-144 сыдырып үтүче кысылган һава. Двигательләрнең тигез гүләвеннән тыш, шактый көчле ысылдау, ул двигательләр тавышына өстәлә һәм кайвакыт хәтта тавышны ничектер «кысрыклап та чыгара»: «Ш-ш-ш-ш...» Аның конкрет чыганагы юк, ул бөтен җирдән ишетелә: очкычның бортларыннан, өстеннән, астыннан. Моны нәрсә белән чагыштырып була? Зур булмаган басым нәтиҗәсендә баллоннан кысылган һаваның чыгуы белән. Кемнең, әйтик, авиазаводта, пневмоинструмент кулланылган цехта эшләгәне бар, алар әлеге ысылдау авазын беләләр...»

ВАКЫТ ҺӘМ КОНКУРЕНТЛАР БЕЛӘН УЗЫШТА

СССРда эшләнгән тавыш тизлегеннән тизрәк Ту-144 – инглиз һәм французларны (аларның пассажир «Конкорд»лары һавага соңрак күтәрелә) һәм үз вакытын узган самолёт. Шул ук вакыт аның өчен рәхимсез дә була. Дөньяда барлыгы җиде Ту-144 сакланып калган. Шуларның берсе Германиядә, Зинсхаймда, җирле музейга куелган. Анда совет белгечләренең заманны уза алган проекты иң кыйммәтле экспонатлардан санала.

Казандагы Ту-144, парадокс, 30 елдан артык шәһәр читендәге бетон койма артында боегып утырды. Бары тик берничә ел элек лайнерны яңа урынга күчерергә һәм халык каршына куярга карар кылынды. Күчерергә, дип әйтүе генә җиңел – гаять киң колачлы күп тонналы машина шәһәр урамнарына берничек тә сыя алмый.

Һәм шул вакытта КМТТУ-КАИда шактый акчалар таләп иткән махсус операция эшлиләр... Аннан соң, Ту-144 тиешле районга «төшеп утыргач», аңа совет чорына хас традицион аэрофлот формасын «кидерәләр». Ә инде очкыч бөтен матурлыгы белән шәһәр урамын ямьли башлагач, аның казанлыларны һәм кунакларны магниттай үзенә тартуы ачыкланды.

Бөек илнең горурлыгы булган лайнер фонында төшерелгән селфи челтәр буенча мизгел эчендә таралды. Шуңа күрә авиация вузының лайнерны Ту-144 интерактив музеена әйләндерү карары әлеге вакыйганың мантыйкый дәвамы булды. Тик менә КМТТУ-КАИга әлеге ниятне тулысынча үз акчасына гына башкару мөмкин түгеллеге дә ачыкланды. Нишләргә?

Владимир Путинның Казанда җәмәгатьчелек вәкилләре белән очрашуы вакытында вуз ректоры Альберт Гыйльметдинов аңа ярдәм сорап мөрәҗәгать итте. Президент: «Яхшы идея, әлбәттә, ярдәм итәргә кирәк», – дип белдерде. Дөрес, шунда ук СССР Министрлар Советы рәисе Алексей Косыгинның Ту-144 очкычының күпме торуы турындагы сорауга җавабын кабатлады: «Моны мин генә беләм, әмма беркемгә дә әйтмим...»

«Мин моны шуңа әйтәм: проектыгызны гамәлгә ашыру акылга сыярлык кысаларда булырга тиеш», – дип аңлатып китте Владимир Путин.

ТАВЫШ ҺӘМ АКЧАЛАР БАРЬЕРЫ

Акылга сыярлык кысаларда интерактив музей, дөресен генә әйткәндә, җәй көнне үк эшләп китә алыр иде. Май аенда РФ Президенты Владимир Путин имзалаган документта болай диелгән: «Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгына А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ базасында илебез авиасәнәгатенә багышланган интерактив техника музеен оештырырга ярдәм итәргә һәм аның эшли башлавын 2019 елда Казанда узачак «Ворлдскиллс» стандартлары буенча һөнәри осталык дөнья чемпионаты ачылышына туры китерергә...»

Күрәсең, ярдәм белән министрлыкта нindидер аңлашылмаучанлыклар килеп чыккан, шуңа күрә әлегә хәбәрчегез – Президент грантлары фонды булышлыгы белән яңартылган һәм виртуаль дөнья технологияләре белән җиһазландырылган пилот кабинасында «очкан» сирәкләрнең берсе. Хәер, махсус симуляторда Казаннан Россия башкаласына «очкан» кешеләр арасында РФ фән һәм югары белем министры Михаил Котюков та бар. Күргәннәрдән тәэсирләнеп, ул проектны гамәлгә ашыру дәвам иттереләчәк, дип вәгъдә бирде.

Самолёт-музейда аның рәсми ачылышына тагын нәрсәләр барлыкка киләчәк соң? Ту-144 салонының бер өлешен вак детальләренә кадәр элеккегечә итеп ясаячаклар, пассажирлар кәнәфиләрен дә үз урыннарына кайтарачаклар. Икенче өлешендә интерактив зона оештырылачак, анда теләге булганнарның барысы да физика законнарын өйрәнә алачак. Дәресләкләр буенча түгел – гамәли рәвештә. Бирегә, мәсәлән, кечерәк кенә аэродинамик торба урнаштыру карала. Ә самолёт янәшәсендә музей бинасы булырга тиеш. Эчтә – «суперсоник»ның уникаль двигателе, самолёт макетлары,

СҮЗ УҢАЕННАН

Беренче тапкыр Ту-144 интерактив музеен ачу идеясен «Татарстан» журналы әйтте. «Полеты в мечтах и наяву» («Татарстан»,2016 елның июле, рус версиясе) мәкаләсендә Казанда Ту-144 музее нинди була алуы турында җентекләп сөйләнде. Шунысы гаҗәп: безнең репортажда язылган күп нәрсәләр өч елдан соң тормышка ашты.



Махсус симуляторда Казаннан Россия башкаласына «очкан» кешеләр арасында РФ фән һәм югары белем министры Михаил Котюков та бар.

панорамалы кинотеатр… Монда 1969 елның 5 июнендә – инглиз һәм французлардан иртәрәк – тавыш каршылыгын беренче тапкыр җиңгән Ту-144 самолёты тарихы турында барысын да белергә мөмкин булачак.

КАНАТЛАРДА – ЙОМЫРКА ТӘБӘСЕ

Ә хәзер чынлыкта барысы да ничек булырга мөмкинлеген күз алдына китерик. Менә сез трап буенча өскә күтәреләсез, кулыгыз белән фюзеляжга кагыласыз – ул төшке кояш нурларыннан җылынган. Экскурсовод ролен башкаручы бортпроводник аңлата:

– Очыштан соң «суперсоник»ның канатында йомырка тәбәсе ясарга була иде, диләр, ул, янәсе, шулкадәр кыза. Бу, әлбәттә, шаярту, ләкин чынбарлыкка бик якын. 20 мең метр биеклеккә күтәрелеп, тизлекне сәгатенә 2500 км га кадәр арттырганда очкычның тышкы ягы 150 градуска кадәр кыза!

Лайнерның корпусы галәмдәгедәй диярлек температура алмашуларына чыдый.

Алга таба атлыйк – Ту-144 салонына рәхим итегез! Биш рәт кәнәфи, баш тери торган урынында ап-ак тыш, проводникларны (алар эшли!) чакыру төймәсе һәм узган гасырдагы совет газеталары – алары ачыла торган өстәлләрдә. Мондагы шартлар – нәкъ менә атаклы аэрофлот флагманындагы кебек үк.

Ту-144 пассажир лайнерлары арасында беренче булып тавыш тизлеге каршылыгын уза алды, тик СССРда даими рейслар башкару да артта калды. Бары тик генсек Леонид Брежнев чит илгә сәфәре вакытында «Конкорд»ның ничек эшләгәнен күргәч кенә, «үзебезнең» пассажир очышларын башларга команда бирелә. Өстәвенә, совет самолёты һәм аэродром хезмәтләре, дөресен генә әйткәндә, моңа әле бик әзер булмый. Внуководан беренче мәртәбә реклама сыйфатында һавага күтәрелгәннән соң, самолётны башка аэродромда утыртырга туры килә, чөнки двигательләрдәге кызган газлар очып китү полосасына зыян китергән була, дип сөйлиләр. Ә башкаладан Алма-Атага оештырылган даими рейсны очучылар «поцелуй тигра» дип атыйлар, эш шунда ки: Ту-144нең резервта запас ягулыгы булмый диярлек. Казахстан башкаласында һава торышы уңайлы булмаган очракта самолёт башка аэродромга барып та җитә алмаска мөмкин була…

Экскурсовод гаҗәеп самолёт турында сөйләгән арада без, «пассажирлар», кәнәфиләргә чумып, очкычта бирелә торган сыйларны тәмләп карыйбыз – Мәскәү – Алма-Ата рейсында 40 ел элек тә шундый ук бокалларга салынган каберне яисә рислинг тәкъдим ителгән. Ул, сүз уңаеннан, 1977 елда (бары тик бер генә ел) Ту-144 башкарган бердәнбер даими пассажир рейсы була. Казахстан башкаласына кадәр араны самолёт ике сәгатьтә үтә, билет бәясе – 80 сум, СССРдагы уртача хезмәт хакыннан күпкә кимрәк.

Шундый легенда да бар: имеш, әлеге рейска утырган һәр кешенең паспортына: «Летал на Ту-144!» мөһерен сукканнар. Сүз уңаеннан, ни өчен әле әлеге салонда булып чыккан һәр кешегә махсус мөһер сугылган открытка бүләк итмәскә, ди? Анда кайчандыр инглиз-француз «Конкордына» көндәш булып торган совет очкычының сурәте ясалган булсын – истәлеккә.

Пилот кабинасы. Монда сезгә тавыш тизлегеннән тизрәк очучы пассажир лайнерларында беренче экипажлар махсус костюмнарда очканнар, дип сөйләячәкләр – кинәт кенә герметизация бозылу очрагына…

ИРЕКЛЕ ОЧЫШ ЭФФЕКТЫ

Иң кызыгы – десертка. Пилот кабинасы. Монда сезгә тавыш тизлегеннән тизрәк очучы пассажир лайнерларында беренче экипажлар махсус костюмнарда очканнар, дип сөйләячәкләр – кинәт кенә герметизация бозылу очрагына…

Сезгә самолётның очында зур булмаган канатлар (бу Ту-144 конструкциясенең үзенчәлеге, ул машинага күтәрелгәндә һәм төшеп утырганда тотрыклылык өсти) белән «идарә итәргә» рөхсәт итәчәкләр. Ә аннан соң очышка «рөхсәт» бирәчәкләр…

Очыш тәмамланганда сезгә буйсынган лайнер, үзенең «торна борынын» аскарак төшереп, җай белән генә бетонга тиячәк. Двигательләр гүләве әкренләп тынычак, әмма сез әле чын очышта алгандагыдай тәэсирләрегездән озак вакытлар арына алмаячаксыз!

Берничә ел элек лайнерны яңа урынга күчерергә һәм халык каршына куярга карар кылынды.

Күчерергә, дип әйтүе генә җиңел – гаять киң колачлы күп тонналы машина шәһәр урамнарына берничек тә сыя алмый.



Ту-144 тиешле районга «төшеп утыргач», аңа совет чорына хас традицион аэрофлот формасын «кидерәләр».

НӘРСӘ:
Ту-144 самолёты базасында интерактив техника музее

КАЙДА:
Казан, Четаев урамы, 18а

КАЙЧАН:
Музей рәсми рәвештә әле ачылмаган, ләкин постаментка урнаштырылган лайнерны теләге булган һәркем карый ала. Иң матур манзара – Фатих Әмирхан проспектыннан.



«Татарстан» журналы версиясе буенча

ИҢ САМИМИ.
ЗӨЯ ТАРИХЫ МУЗЕЕ

Әйе, XIX гасырда матур итеп чытлыклана, аерылыша белгәннәр. Тагын хат язарга яратканнар. Бик үзенчәлекле, самими итеп. Бу шундый нәзакәтле, шундый серле һәм... бик шәхси. Хатны алучы кеше аны язучының кагылуын тойгандай булырлык дәрәҗәдә. Искиткеч тәкәллефле гасыр, кыскасы...

Автор:
Алсу Троицкая

Күңелне дулкынландыра, үзәкне өзә торган хатирә. Егет – укытучылар институты шәкерте Александр Артемьев. Кыз – Мариинск гимназиясен тәмамлаган Елизавета Слободская. Һәм аларның бер-берсенә язган искиткеч назлы, хисле, тетрәндергеч хатлары...

Артемьев-Слободскийлар гаиләсенең бер-ике йөз хаты һәм Александр Артемьевның 77 көндәлеге бүген Зөя тарихы музеенда саклана. Алар 30 ел буена хат алышкан! Гәрчә Идел сусаклагычларын төзү елларында Зөядәге бөтен торак биналар диярлек җимерелеп бетсә дә, гаҗәп хәл – әлеге гаиләнең Никольская урамындагы йорты безнең көннәргәчә сакланган...

Сүз уңаеннан, әле языша гына башлаган чорда бу парның хатлары яшерен булган, чөнки гашыйк пар «никахлашмаган». Ни өчен, дип сорыйсызмы?



«Яшь кыз беркайчан да ир-атка хат язмый, хәтта үзенең ата-анасы исеменнән дә; аның туган тиешлесе булмаган яки бик үк карт булмаган ирнең кулында кыз кулы белән язылган бер генә җөмлә дә булмау – иң яхшысы».

XIX гасыр азагында Россия җәмгыятенең югары катлауларына тәгаенләнгән этикет кагыйдәләреннән. Тәүге тапкыр Санкт-Петербургта 1890 елда басылган «Гамәли белешмәләр китапханәсе» сериясеннән «Жизнь в свете, дома и при дворе» китабында шулай ук хат этикеты, хат алышу нечкәлекләре, һичшиксез сакланырга тиешле әдәп кагыйдәләре бар. Китап дворяннар (морзалар) катламы вәкилләренә тәгаенләнсә дә, андагы кагыйдәләр рус мәдәниятенең «көмеш гасыры» чорына хас нәфислек, нәзакәтлелек үрнәге буларак кабул ителгән.

Фото: Александр Гайнетдинов

ӨЯЗ МОРЗАЛАРЫ ТОРМЫШЫ ТУРЫНДА

– Бу йорт фасады әлеге дә баягы Артемьев-Слободскийларның Зөядә сакланып калган чын йортына нигезләнеп эшләнгән, – дип сөйли «Зөя шәһәр-утравы» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы экскурсоводы Ольга Малахова.

– Ә бу Елизавета Слободскаямы? – дип кызыксынабыз, тәрәзәдән безгә карап торучы гүзәл ханымга сокланып. Искиткеч сылу буй-сын, акыллы күз карашы, зәңгәр төстәге бик матур күлмәк, кулында исә, әлбәттә инде, китап...

– Әйе, музейны оештыручылар аның хатлары буенча хәтта йортларының интерьерын да тәфсилләп торгыза алды. Күз алдыгызга китерә аласызмы, нинди озын хатлар язганнар ул чакта! Күрүегезчә, өяз морзалары шактый тыйнак яшәгән. Әмма зәвыклары булган...

Рөхсәт булудан файдаланып, Артемьев-Слободскийлар йорты тәрәзәсеннән эчкә күз салабыз. Музейда мондый гына кызыксынуны тыйнаксызлыкка санамаслар, дип өметләнәбез.

Тыйнаграклар йорт фасадын тышкы яктан гына күзәтә һәм анда 1885 елгы табличканы күреп ала. Ул бу йортның янгыннан иминиятләштерелгән булуын аңлата. Мондый такталарны Россиянең күп кенә борынгы шәһәрләре урамнарында бүген дә күрергә мөмкин. Кайдадыр алар балчыктан, кайдадыр металлдан ясалган, әмма барысының да асылы бер.

Мондый такталарны Россиянең күп кенә борынгы шәһәрләре урамнарында бүген дә күрергә мөмкин. Кайдадыр алар балчыктан, кайдадыр металлдан ясалган, әмма барысының да асылы бер.

АЛТЫН УРДА ЭЗЕННӘН

– Хәзер исә без Зөя өяз шәһәренең почта конторасында. Утырып, сез үзегезнең якыннарыгызга берничә сүз сызгалый аласыз, – дип дәвам итә Ольга Анатольевна. – Гомумән, Россия империясендәге теләсә кайсы шәһәрчеккә килеп төшүгә үк, кеше нәкъ менә почта конторасында теркәлергә тиеш булган. Һәм өенә хат җибәргән, СМСлар булмаган бит. Сүз уңаеннан, Россия почтасының эш принцибы хәзергә кадәр үзгәрмәгән диярлек. Ул чакта да хатларны үлчи торган булганнар, дөрес, электрон үлчәүдә түгел инде. Күп язсаң – кыйбаткарак, аз язсаң арзангарак төшкән. Шулай ук маркалар ябыштырылган һәм, кабат файдаланылмасын өчен, штемпель басып, гамәлдән чыгарылган. Фаразларның берсе буенча, почта станцияләре системасы өчен без татар-монголларга бурычлы. Ямнар Алтын Урда чорында аның чик буендагы биләмәләре белән элемтәдә тору өчен булдырылган. Ямнар берберсеннән билгеле бер ераклыкта урнаштырылган. Биредә курьер атларын алыштырган, тамак ялгаган, ялга тукталган һәм кабат юлын дәвам иткән. Вакыт үтү белән «ям» сүзе әйләнештән төшеп калган, ә ямчы вазыйфасы әле бик озак сакланган...

КУЛДАН ЯЗЫЛГАН ҖӘҮҺӘРЛӘР

Шәһәр урамнарыннан почта ящикларының юкка чыгуын шәйләдегезме сез? Хат яки открытканы почта бүлегеннән генә җибәреп була хәзер. Ә бит аларны язу һәм бигрәк тә алу ничек рәхәт иде! Безгә әле бу хисләр таныш. Ә балалар? Яңа ел алдыннан Кыш Бабайга бүләк сорап язсалар гына…

Эш сагыну хисендәме, әллә башкадамы, әмма Зөя тарихы музеенда октябрь азагында ачылган «Мин барыннан да бигрәк хатлар формасын яратам…» күргәзмәсе үзенә җәлеп итә. Ни дисәң дә, хат – кулдан язылган җәүһәр бит ул. Биредә «Зөя шәһәр-утравы» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы җыелмасындагы хат язу культурасына һәм аларны җибәрү системасына кагылышлы предметлар куелган.

«Хат язышканда җорланудан, ике мәгънәлелектән тыелу һәм гыйбарәләрне мөмкин кадәр йомшарту зарур; фикерне язмача белдерүнең зур кимчелеге бар – ул тавыш интонациясен һәм хат язучы кешенең йөзе нинди кыяфәттә булуын тапшыра алмый. Ә бит сөйләшүдә тон һәм карашның никадәр зур әһәмияткә ия булуы һәркемгә мәгълүм. Бер үк фразаны дистәләрчә төрле интонация белән укып була, һәм һәрвакыт ул яңа мәгънәгә ия булачак.

Шунлыктан хат язганда бик игътибарлы булу һәм алынган хәбәрдәге мәгълүматка тулысынча ышанмау лязем.

Һәрвакыт истә тоту зарур: телдән әйткән сүз җилгә оча һәм аның эзе калмый, ә инде «каләм белән язганны балта белән дә чабып ташлап булмый». Сак кеше беркайчан да беркем турында да язмача гайбәт сатмас һәм киләчәктә үзенә зыян китерергә мөмкин булган кискен фикерләрне әйтергә беркайчан да җөрьәт итмәс. Хатта гайбәткә урын булмаска тиеш; нинди дә булса бер саксыз сүзнең никадәр хәсрәт яки бәхетсезлеккә китерү мөмкинлеген күз алдына да китерүе кыен, чөнки бер хаттагы бер ялгыш фикер шунда ук төрле шәрехләүләр тудыра һәм икенчесендә инде чын дөреслек итеп тапшырыла. Әгәр кешеләр аек акыллы, төпле булса, язылган хатын җибәргәнче уйланырга тиеш: күп халык алдында кычкырып укылган очракта аңа кызарырга туры килмәсме? Артык күп язу кешеләрне артык күп сөйләүгә караганда да ешрак харап итә. Шунлыктан хәйләкәрләр һәрвакыт бик аз яза, ә эчкерсез гади кеше артыгын язып ташлый да кайчагында шуның өчен җәзага дучар ителә».

«Жизнь в свете, дома и при дворе» китабыннан

Безнең белән кабат Ольга Малахова. Ул сүзен дәвам итә:

– Каен тузына язылган атаклы Новгород хатлары безгә мәктәп елларыннан ук таныш. Әмма XIX–XX гасырларда, транспорт инфраструктурасы үскәч, хат язу культурасы тагын да киңрәк таралган. Әйтергә кирәк, хат язу, эпистоляр жанрда аралашу һәркемнең дә хәленнән килмәгән, чөнки Россиядә укымышлы затлар, укый-яза белүчеләр аз булган. Әмма шуңа да карамастан, хат язу культурасы булган, хәтта дәреслекләрдә хат язарга өйрәтү кагыйдәләре бастырылган. Язу рәвеше, хатны бөкләү тәртибе, хатның формасы, кәгазенең сыйфаты ук кешенең статусы, аның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе турында сөйләгән. Ә инде хатның эчтәлеге, өслүбе кешенең әдәбе, аксөякләргә хас сыйфатларының ни дәрәҗәдә булуын күрсәткән.

ХАТ ЯЗЫШЫГЫЗ. БУ РӘХӘТЛЕК БИРӘ

Сүз уңаеннан, XIX гасырдагы язу әсбапларыннан һәм совет чоры көнкүреше элементларыннан тыш, күргәзмәгә Артемьев-Слободскийлар гаилә архивыннан чын хат һәм открыткалар да куелган. Биредә, Зөядә, әлеге гаиләнең берничә буыны яшәгән.

Кәгазь хатларны еллар буе сакларга мөмкин. Аларны язучының кул җылысын тоеп, кабат-кабат укырга була. Без яшәгән мәгълүмати технологияләр дәвере исә аралашуның бөтенләй башка төрен тудырды. Әмма коры электрон хәбәрләрне дә кат-кат укыйсы килерме икән соң?



Мондый гаярь хат ташучы егеттән башка Елизавета Слободская һәм Александр Артемьевның хатлардагы романы бөтенләй булмас та иде. Музей-тыюлыкка алардан мирас булып хатлар гына түгел, чын хәзинә – балалар рәсемнәре, революциягә кадәрге уеннар һәм көнкүреш предметлары да калган әле.

Беренче ачык хатлар – открыткалар – Россиядә 1870 нче елларда пәйда була. 1909 елда «ачык хат» төшенчәсе махсус карар буенча «почта карточкасы» дип үзгәртелә. Тәүге открыткалар соргылт-аксыл төстәге 9х12 сантиметр үлчәмдәге почта кәгазе кисәгеннән гыйбарәт була.
Бер ягында – герб, марка, адрес, икенче ягында – хат өчен урын. Шунысы да кызык: баштарак открыткада вак хәрефләр белән:
«Почта бүлеге хатның эчтәлеге өчен җавап тотмый», дип язылган була.
Күп кенә танылган рәссамнар открыткалар да ясаган. Рәссам Елизавета Бём эшләре аеруча киң танылган. Бу жанрда сәнгать дөньясының башка вәкилләре дә эшләгән. Күргәзмәдә сез Борис Кустодиев ясаган открыткаларны да күрә аласыз.



21. VI. 1930. 6 ч. вечера. Милый Юра!
Я два раза был в Свияжске и оба раза заставал тебя спящим. А очень хочется побеседовать с тобой! Думаю что и тебе хочется того же. Что ты поделываешь? И слушаешься ли ты маму? Как идут твои пароходы? Ходишь ли купаться? Или из за дождей сидишь дома? Через неделю я буду в Свияжске. Будь здоров и умен! Целуй маму! Целую тебя. Папа.

Бу хатның басма диярлек хәрефләре аның кайдадыр еракта хезмәт итүче әтисенең баласына язган хаты булуын күрсәтә.
Һәр сүздән ата мәхәббәте бөркелеп тора һәм кайгыртуы сизелә.

Казанның Покров һәм Театр урамнары чатындагы почта конторасы. Бүген бу – КМТТУ-КАИ ның Ирек мәйданындагы бишенче корпусы. XIX гасырда нәкъ менә шул урын Казанның географик үзәге саналган һәм шуннан чакрым баганалары башланган. 1957 елда кардиналь рәвештә үзгәрткәннән соң, бина бүгенге кыяфәтенә кергән.

Бу – Зөя тарихы музее буйлап без оныткан эпистоляр жанрга бәйле нибары бер күргәзмәгә кечкенә сәяхәт кенә. Зөя шәһәр-утравы тарихы һәм аның кешеләре турында тагын шундый күңелне нечкәртә торган хикәятләр ишетәсегез киләме? Зөя тарихы музеена рәхим итегез!

Икенче кат тулысынча канатлылар вәкилләренә багышланган

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ВЕРСИЯСЕ БУЕНЧА

Автор:
Алёна Кутыркина

ИҢ КЫЗЫКЛЫСЫ. ЭДУАРД ЭВЕРСМАН ИСЕМЕНДӘГЕ ЗООЛОГИЯ МУЗЕЕ

Витриналардагы казык тешләрен ыржайткан ап-ак баш сөякләре бу музейга килүчеләрне кызыксынып күзәтә. Стендлардагы йөзләрчә күбәләк канаты төрле җете төсләргә кереп ялтырый. Карасу төстәге агач киштәләрдә медуза, моллюск, елан, тагын нindидер аңлаешсыз җан ияләре «консервланган» банкалар рәт-рәт тезелгән. Хайван скелетлары, кош сөкәтләре, фаунаның әллә нинди сәер вәкилләре дә бар анда – иң борынгылары 1889 елдан бирле саклана икән. Университет паркетының академик шыгырдавын тыңлый-тыңлый, без КФУ дагы Эдуард Эверсман исемендәге зоология музее экспонатлары белән танышабыз.

УНИВЕРСИТЕТТАН ӨЛКӘНРӘК

Гаҗәп хәл: Россиядәге иң зур зоология музейларыннан берсенең коллекциясе үзе урнашкан уку йортыннан алданрак пәйда булган. Эш исә менә нәрсәдә. XVIII гасыр азагында кенәз Григорий Потемкин-Таврический Екатерина II фәрманы белән Екатеринослав шәһәрендә яңа университет ачарга әзерләнә. Ул сирәк очрый торган имезүчеләр, җир-су хайваннары, рептилияләр, балык һәм кошларның сөкәтләрен чит илләрдән сатып ала. Әмма 1798 елда тәхеткә Павел I утыра һәм барлык 133 экспонат-

Автор фотолары

ны да Казандагы үзенә бик ошаган император гимназиясенә күчерергә боера. Ә 1804 елда Александр I Казан Император университетын булдыру турында карар кабул итә, тупланган экспонатлар шунда кала.

Князь Григорий Потёмкин-Таврический

Яков Коксин

Эдуард Эверсман

НИГЕЗ САЛУЧЫЛАР

– Казанда зоологиягә өч немец нигез салган, – дип тарих белән таныштыра безне экскурсия җитәкчебез, музей инженеры **Валериан Гаранин.**

Зоологик тупланма өчен җаваплыларның беренчесе медицина һәм табигать фәннәре докторы Карл Фукс була. Аның тырышлыгы белән музейда 500 дән артык кабырчык туплана. Университетта чагыштырма анатомия кабинетына нигез салучы Александр Эйхвальд экспозицияне Кавказда яшәүче кошлар һәм сөйрәлүчеләр белән баета. Эдуард Эверсман исә музейны үстерүгә аеруча зур өлеш кертә. 1828 елдан ул Казан университетында зоология һәм ботаника профессоры була. Үзенең студентлары белән экспедицияләргә чыккан саен галим яңа экспонатлар алып кайта һәм музейдагы коллекциянең тәфсилле исемлеген төзи.

– Әмма менә бәла, унтугызынчы гасыр азагында музей хезмәткәрләреннән берсе этикеткаларны яңартырга уйлый. Һәм алардагы иң мөһим язуны – экспонатның кайчан, кайда, кем тарафыннан табылуын һәм тапшырылуын төшереп калдыра. Шунлыктан тупланмадагы кайсы сөкәт һәм препаратларның иң борынгы булуын әйтүе кыен, әмма алардан кайберләрен безнең беренче зоологларыбыз хезмәтләре белән тәңгәлләштерә алганнар.

ЭВОЛЮЦИЯ ТӘРТИБЕНДӘ

Бүген музей университетның төп бинасының көнчыгыш канатындагы икенче катта урнашкан сигез залдан гыйбарәт. Аның фондларында 3,5 мең умырткалы, 4 мең умырткасыз хайван һәм 30 меңнән артыграк бөҗәк исәпләнә. Мең ярымлап экспонатны белгечләр аеруча әһәмиятле дип саный.

Экспозициядән иң гади төзелешлеләрдән башлап приматларга кадәр булган тереклек үсешен күзалларга мөмкин. Шунлыктан экскурсия бар нигезнең нигезе булган умырткасызлар патшалыгыннан башлана. Экземплярлар арасында голотиплар – хайванның әлеге төре беренче тапкыр шуның буенча сурәтләнгән тарихи препаратлар да бар. Яссы суалчан-турбелляриның егерме төре шундый голотип булуы белән мактана ала.

Аннары иң матур зал: Александр Бутлеров коллекциясендәге йөзләрчә күбәләк тере кебек тоела. Бу танылган химикның җитди мавыгуы булган, аның хәтта дипломы да Идел-Урал төбәгендә яшәүче күбәләкләргә багышланган.

Бинаның калган урыннары – умырткалы хайваннар бүлеге. Кош һәм имезүчеләр үзләренең табигый позаларында катып калган, кайбер сөкәтләр исә ауның ничек баруын күрсәткән тәфсилле сурәт хасил итеп урнаштырылган – таксидермистлар шул рәвешле үзләренең осталыгын һәм хайваннар табигатен яхшы белүләрен күрсәтмәкче булган.

Арткы планда Николай II шәхсән үзе аткан зубр сөкәте

ЭКСПОЗИЦИЯНЕҢ ГОРУРЛЫГЫ

Хайваннарның бөтен дөньядан җыелган сирәк һәм сәер төрләреннән тыш, музейда җирле фауна да җентекләп чагылдырылган. Күп экземплярлар Казан губернасында җыелган, экологиягә һәм ландшафтка бәйле үзгәрешләр аркасында хәзер инде аларның бер өлеше Татарстан территориясендә очрамый да.

Эре кырпы балыгы сөкәте экспозициянең мактанычы булып тора, аннан да зуррак экспонат республика Милли музеенда гына бар.

– Миңа узган гасырда кырпы балыгын да, мәрсинне дә авыз итү насыйп булды. Искиткеч тәмле, – дип искә ала эксурсия үткәрүчебез. – Хәзер исә плотина аркасында бездә әлеге балыклар бик сирәк очрый, мондый эреләре исә бөтенләй юк та. Узган гасыр урталарына кадәр республика территориясендәге археологик казу эшләре вакытында табылган бо-

Агулы умырткасызлар
препаратлары экспозициясе

Химик Александр Бутлеров
тоткан күбәләкләр коллекциясе

рынгы хайван скелетлары да биредә саклана иде. Хәзер бу экспонатлар университет карамагындагы Геология музее залларына күчте, биредә реликвия сыйфатында мамонтның баш сөяге генә калды.

МОҢСУ ХӘЛЛӘР ҺӘМ КЫЙММӘТЛЕ ЭКСПОНАТЛАР

Биредәге хайваннарның кайберләре, сирәк сөкәтләр булдыру өчен, музейга махсус тапшырылган. Мәсәлән, зур зубрны ау вакытында патша Николай II аткан һәм музейга бүләк иткән. Император үзе Казанда булмаган, әмма академик шөһрәткә ия калага хөрмәт белән караган.

Коллекциядәге кайбер экспонатларның пәйда булуы моңсу хәлләр белән бәйле, аларның кайберләрен Валериан Иванович безгә дә сөйләде:

– Бу Карлсон кушаматлы су үгезенең (бегемотның) баш сөяге, ул 1985 елда Казан зооботаника бакчасында һәлак булган. Зоопаркка килүченең вольерга ыргыткан теннис тубын йоткан ул...

Арыслан гаиләсенең пәйда булуы XIX гасыр азагында булган очрак белән бәйле. Ул чакта Казанга күчмә цирк килгән, арысланнар гаиләсендә бәләкәч туган гына булган. Әмма кемдер бөтен гаиләне агулаган һәм, зоология өчен сирәк ихтималны кулдан ычкындырмас өчен, 1 нче гильдия сәүдәгәр Павел Щетинкин үләксәләрне 250 сумга сатып алган. Меценат аларны сөкәтләрен ясау өчен университет музеена тапшырган.

1883 елда үлеп беткән квагга зебрасы исә музейның иң кыйммәтле экспонаты санала. 1843 елда профессор Эверсман үлгән хайванның тиресен Берлиннан алып кайта. Казанда 120 ел сакланганнан соң, музей директоры Александр Попов аны, сөкәтен ясатыр өчен, Ленинград зоология институтына җибәрә.

Бөтен дөньяда шундый нибары 23 экспонат бар, Казан зебрасы таеның сөкәте исә хәзер Германиядә, Майнц шәһәре музеенда тора. Эксклюзивны үзләренә калдырырга теләп, ленинградлылар казанлыларга кваггаңы алты зур хайван сөкәтенә (шулар арасында жираф белән мөгезборын да була) алыштырырга тәкъдим итә. Әмма галимнәр ризалашмый, уникаль зебра кире Казанга кайта.

DISCOVERY КАНАЛЫННАН КЫЗЫКЛЫРАК

Бирегә экскурсиягә килеп элэгүчеләр бәхеткә тиенәчәк – алар безнең әңгәмәдәшебезнең бай зоологик тәҗрибәсе белән танышачак.

– Биредә Татарстандагы еланнарның бөтен төре бар. Минем кара еланнан авыз иткәнем бар, аннары ай буе шешкән кулымны бәйләп йөрдем, – дип көлемсери Валериан Иванович.

Ул шулай ук тәвә кошын тынычландырырга, көртлек һәм боҗыр тотарга рәхәтләнеп өйрәтәчәк, мәче башлы ябалакның ни өчен кешегә һөҗүм иткәләвен аңлатачак, бүреләрне алдар өчен боланнарның нәрсәгә сәләтле булуы турында сөйләячәк... Чал сакаллы 92 яшьлек Валериан Гаранинның экспонатлар янәшәсендә сөйләгән шундый кызыклы хикәятләре Discovery каналыннан күпкә кызыклырак.

– Мин ярты ставкага эшлим һәм атнасына өч көн экскурсияләр үткәрәм. Әле студент чагымда ук мин коллекцияне яңа экспонатлар белән тулыландыручы профессорлар белән таныш идем. Хәзер бу сирәк очрый. Берничә ел элек Татарстаннан тимсах (крокодил) сөкәтләре алып китәргә җыенган контрабандачыны тоткарлагач, шуларны безгә бирделәр.

Чыннан да, контрабанда тимсахы сөкәтләр компаниясендә үзенең табигый булмаган позасы белән аерылып тора. Гомумән, музейдагы һәр экспонат уникаль, күпчелеге биредә 200 әр ел «яши», аларны карап тотарга һәм кайвакыт ремонтларга гына кирәк.

Язгы ау инсценировкасы. Кем җиңәр?

ПОШИМЫ, БҮРЕЛӘРМЕ?

Эдуард Эверсман исемендәге зоология музее – университетта популяр урын. Биредә дәресләр, экскурсияләр, тематик кичәләр һәм квестлар даими үткәрелә. Бер урында тупланган шулкадәр күп хайван белән тагын кайда шулай танышып, аларның табигатен, холкын өйрәнеп була соң?!

Без бүреләрнең пошины аулавын сурәтләгән күренеш янында туктаддык.

– Бу һөҗүм урмандагы кар өсте каткан мизгелдә булган. Поши авыр, ул карга бата, бүреләр исә – юк, шуңа аның бугазына ябышу җиңелрәк. Көрәшнең ничек бетәсен без белмибез. Бәлки, пошины яраларлар гына, һәм ул китеп котылыр. Яисә бүреләр аны җиңәчәк, тик ул чакта кимендә ике ерткыч имгәнәчәк яки үләчәк, чөнки поши һәрвакыт җаны чыкканчы каршы тора, – дип тәмамлый экскурсияне Валериан Иванович.

ЗООЛОГИЯ МУЗЕЕН НИЧЕК ТАБАРГА

Казан федераль университетының төп бинасы. Музейлар кассасы кергәч тә сул якта.
Музейда ялгыз да, төркем составында да йөреп була. Билет бәясе – 150 сум, мәктәп балалары, студентлар һәм пенсионерлар өчен –100 сум.



الیفبی
طاطار دلیننک الیف بینینک تحقیق
یازولغان حرفلاری و هجالارینی
بتلمش
قزان گیمنازیه لاری ننک استاذی و آدمیرال
کانطوری ننک ترجمانی سعید خلفه
اوغلی املاه و قزان قلعه سیندا اکی ملالار
املاه شول اوق گیمنازیه لارده قرالمش
و ماقتالمش

АЗБУКА
ТАТАРСКАГО ЯЗЫКА
съ
обстоятельнымъ описаніемъ
буквъ и складовъ,
сочиненная
Казанскихъ Гимназій учителемъ,
и Адмиралтейской Конторы переводчикомъ
САГИТОМЪ ХАЛЬФИНЫМЪ,
и Татарскихъ въ Казанѣ слободъ Муллами
въ оныхъ Гимназіяхъ
разсмотренная и одобренная.
Печатана при Императорскомъ Московскомъ
Университетѣ, 1778. года.

«Татарстан» журналы өчен МАХСУС

ЗЫЯЛЫ ЯШӘҮ ҮРНӘГЕ

(ХӘЛФИННӘР ДИНАСТИЯСЕ ТУРЫНДА)

XVIII–XIX гасыр татар мәдәниятендә Хәлфиннәр династиясе аерым урын били. Аталы-уллы Сәгыйть һәм Исхак Хәлфиннәр, Исхакның улы Ибраһим Хәлфин – шушы зыялы гаиләнең 3 буын вәкилләренең татар телен өйрәнүгә, мәгърифәтчелекне үстерүгә керткән хезмәтен бәяләп бетерерлек түгел. Алардан соң да зыялы нәселне дәвам итүчеләр арасында сәүдәгәрләр, педагоглар, җәмәгать эшлеклеләре һәм башкалар күп.

Автор:
Илшат Фәйзрахманов

ИСКЕ ТАТАР БИСТӘСЕ ҺӘМ КАЗАН АДМИРАЛТЕЙСТВОСЫ

Укытучылар династиясенә нигез салучы Сәгыйть Хәсән улы Хәлфин (1732–1785) – XVIII гасырда татарның билгеле шәхесе. Ул – тәрҗемәче, мәгърифәтче, педагог, Казанның Иске һәм Яңа Татар бистәләреннән 1767 елгы Император закон чыгару комиссиясе депутаты, 1 нче Казан ирләр гимназиясенең татар теле укытучысы, татарлар арасында беренче филолог. Кайбер мәгълүматларга караганда, аның бабалары Казан арты төбәгеннән чыккан. Атасы Хәсән Айтуган улының Иске Татар бистәсендә зур гаилә корып яшәгәнлеге билгеле – Сәгыйть иң олысы, аның тагын 4 бертуган энесе, ике сеңлесе, шулай ук икенче үги әни белән килгән ике сеңлесе була.

XVIII гасырда татарның сәүдә-икътисадый, иҗтимагый-мәдәни үзәкләренең берсе булып Казанның Иске һәм Яңа Татар бистәләре тора. Бистәдә яшәүче йомышлы татарлар 1718 елгы Петр патша фәрманы нигезендә Адмиралтействога лашман хезмәтенә беркетелә. Бистәдәгеләр хезмәтләрен җиңеләйтүне сорап хөкүмәткә мөрәҗәгатьләрне (ул чорда «челобитная», «прошение», дип аталган) лашманнар арасында беренчеләрдән булып актив рәвештә язганнар. Алардан күреп, башка җирләрдәге лашманнар да үз мөрәҗәгатьләрен төзегән, ышанычлы кешеләр аша Петербургтагы Адмиралтейство-коллегиягә җиткергән.

Һәм менә бистә татарлары үзләре арасыннан ышанычлы кеше буларак Сәгыйть Хәлфинне төрле җәмәгать эшләренә җәлеп итә башлый. Сәгыйть Хәлфинең хезмәт юлы Казан адмиралтействосы белән тыгыз бәйләнгән. 1764 елдан ул Казан адмиралтействосы конторасында тылмач (тәрҗемәче) вазыйфасын башкара. Урман кисүче лашманнар белән Адмиралтейство администрациясе арасында арадашчы буларак, лашманнарның гозерләрен татарчадан русчага тәрҗемә итү һәм, киресенчә, администрация боерыкларын татарчага тәрҗемә итеп, лашманнарга аңлату белән шөгыльләнә. 1769 елга кадәр Сәгыйть Хәлфиннең гаиләсе, башка йомышлы татарларныкы кебек үк, җан башыннан салым түләүчеләр исәбендә йөри. Аннан соң гына Сәгыйтькә дәүләт чиновнигы статусы бирелеп, аны һәм гаиләсен салымнардан азат итәләр.



XVIII гасырда татарның сәүдә-икътисадый, иҗтимагый-мәдәни үзәкләренең берсе булып Казанның Иске һәм Яңа Татар бистәләре тора. Рәсемдә – Иске Татар бистәсендә урнашкан Апанай мәчете. (1768-1771 елларда төзелә).

ГИМНАЗИЯДӘ УКЫТУ ЕЛЛАРЫ

Татар теленең күп гасырлар дәвамында руслар белән көнчыгыш халыклары арасында дипломатик аралашу теле булганлыгы билгеле. Шуңа күрә татар телен руслар арасында да яхшы белгән чиновниклар, дәүләт эшлеклеләре әзерләү максаты белән кайбер уку йортларында татар телен укыту кертелә. 1769 елда, 1 нче Казан ирләр гимназиясендә татар классы ачылгач, Сәгыйть Хәлфин татарлардан беренче булып анда укыта башлый. Билгеле, ул чорда татар телендәге уку әсбаплары да, укыту методикасы да эшләнелмәгән диярлек була. Әлеге хәл Сәгыйть Хәлфинне үз предметын тагы да бирелебрәк камилләштерергә этәргеч бирә. Ул телнең лексик составын, грамматик конструкцияләрне һәм кагыйдәләрне өйрәнә. Һәм менә, ниһаять, 1778 елда Мәскәү университетында «Татар теленең әлифбасы» дигән уку әсбабы дөнья күрә. Әлеге дәреслек бүген культ дәрәҗәсендә исәпләнә ала. Ул рус телендәге аңлатмалар белән гарәп шрифтына өйрәтә. Әлифба тәрҗемәчеләр өчен уку әсбабы буларак кулланыла, 100 ләп данәсе Казан гимназиясенә кайтартыла. Әлеге әлифбада татар теле көнчыгыш (гарәп, фарсы, төрек) телләрен өйрәнүдә башлангыч нигез буларак карала. 1785 елда Сәгыйть Хәлфин «Татар сүзлеге һәм кыскача татар грамматикасы»н кульъязма рәвешендә төгәлли. Тик ул басылмый кала. Әлеге сүзлек 20 меңнән артык сүзне үз эченә ала һәм бу вакытка кадәр әзерләнгән сүз запасы 600 дән артмаган рус-татар сүзлекләреннән бик күпкә баерак була.

МӨХӘММӘТРӘХИМ ҺӘМ ИСХАК ХӘЛФИННӘР

Патшабикә Екатерина II идарә иткән чорда Казандагы татар бистәләрендә күпсанлы мануфактуралар, сәүдә йортлары үсеп чыга. Аеруча бай татарларның шәһәрнең руслар яшәгән кварталларында да үз йортлары була. 1782 елда Казанда Татар Ратушасы ачыла. Ул татар бистәләрендәге халык эшләрен карый. Сәгыйть Хәлфиннең энесе Мөхәммәтрәхим шулай ук Казанда билгеле кеше – 1757 елгы Пруссия походында йөреп кайта, Иске Татар бистәсендә җәмәгать эшләре белән актив шөгыльләнә, 1782–1785 нче елларда бистәдә бургомистр булып тора, халыкның ышанычлы кешесе санала.

Сәгыйть Хәлфин кебек тәрҗемәчеләргә дәүләттән дә, халыктан да ихтыяҗ зур була. Ул, чиновник буларак, дәүләттән окладын да ала, шулай ук тәрҗемәсе өчен гозерләнеп килгән халыктан да төшем керә. Шуңа аларның гаиләсе үз вакыты өчен бер дә начар яшәмәгән. Акрынлап атасы эшен улы Исхак (1754–1800) башкара башлый. Әле 1773 елда ук, Сәгыйть Хәлфин авырган чакларда, аның урынына Казан адмиралтействосы конторасында тәрҗемәче булып эшли, 1785–1800 нче елларда 1 нче Казан ирләр гимназиясендә укыта. Исхак Хәлфиннең аеруча билгеле хезмәте – 1785 елгы «Учреждения для управления губерний Российской империи»нең татар һәм Кырым татарлары теленә тәрҗемәләре.

ИБРАҺИМ ХӘЛФИН

Исхакның улы Ибраһим Хәлфин (1778–1829), Мәскәү университетын тәмамлагач, гаилә традицияләрен дәвам итеп, 1800 елдан шул ук Казан гимназиясенең татар сыйныфында укыту эшләренә керешә. 1803 елда ул рәсми рәвештә 12 гимназистны укыта, укучылар санын арттыруга, гарәп һәм төрек телләрен укытуны кертүгә ирешә. 1804 елда Ибраһим Хәлфин тарафыннан әзерләнгән «Татар теленең әлифбасы һәм этимологиясе» әсбабы 1200 тираж белән басылып

Ибраһим Хәлфинне 1812 елда Казан университетына лектор итеп куялар, 1823 елдан ул көнчыгыш телләре адъюнкты вазыйфаларын башкара. Ибраһимның балалары да тәрбияле, белемле булып үсәләр. Бер улы – Шаһингәрәй Хәлфин – татарлар арасыннан Казан университетының беренче студенты.



Казандагы Азия типографиясендә басылган татарча әлифба. 1812 ел


№ 7 подано 15 июля 1780 г.

Покорнейшее прошение

Йомышлы татарларның Казан адмиралтействосына Исхак Хәлфин кул куеп язылган үтенече. 1780 ел.

чыга. Ибраһим Хәлфин русчаны да яхшы белгән, аңарда дәресләрне кызыклы, җанлы итеп оештыра белү сәләте көчле булган, шуңа да аның дәресләренә йөрүчеләр саны арта бара, кайвакыт 35 кә кадәр укучы килә. Ибраһим Хәлфин татар телен ниндидер кысаларга кертеп, аерып карамыйча, башка телләр белән берлектә өйрәнүне яклый. Ул татарларга да югары белем бирү турында хыяллана, алгарыш булсын өчен туган телне генә түгел, русчаны, дөнья казанышларын да яхшы белү кирәклеген әйтә. Сәләтен һәм тырышлыгын, алдынгы фикер сөрешен күреп, Ибраһим Хәлфинне 1812 елда Казан университетына лектор итеп куялар, 1823 елдан ул көнчыгыш телләре адъюнкты вазыйфаларын башкара. Мәгърифәтчелек идеяләре белән сугарылган гаиләдә тәрбия алган Ибраһим, атасы белән бабасын да уздырып, татар, төрек, гарәп, фарсы телләрен укытуны тагы да югары дәрәҗәгә күтәрә. Ул укытучы гына түгел, галим, тарихчы, археограф, әдәбият белгече буларак та танылу ала. Мәсәлән, Ибраһим Хәлфин 1397 елгы Тимер Котлыг ярлыгын әзерләп бастыра. Шулай итеп, ул хан ярлыкларын фәнни өйрәнүнең башында тора.

Ибраһимның балалары да тәрбияле, белемле булып үсәләр. Бер улы – Шаһингәрәй Хәлфин – татарлар арасыннан Казан университетының беренче студенты. Икенче улы Садыйк Теләнче-Тамакта яшәп сәүдә эшләре белән шөгыльләнә.

«АЗИЯ» ТИПОГРАФИЯСЕ

1800 елда 1 нче Казан ирләр гимназиясендә «Азия» типографиясенең ачылуы мөһим бер вакыйга була. Бу типографиядә бары гарәп шрифты гына булып, беренче 3 ел эчендә генә дә 31 мең татар һәм гарәп телендәге китаплар бастырыла (Коръән, әлифба, грамматика китаплары һ.б.). Типография ачылу татарча һәм башка көнчыгыш телләрендә чыга торган китапларны бары тик ныклы тикшерү үткәреп кенә бастыруны калдыру максатын күз алдында тота. Ибраһим Хәлфин типография оешкан вакыттан алып вафатына кадәр аның цензоры булып тора. Хәлфин катнашында типографиянең беренче 8 елында 26 исемдәге мөселман китабы дөнья күрә. Ул күп кенә көнчыгыш телләрендәге басмаларга һәм Казан университетындагы көнчыгышны өйрәнүче галимнәрнең хезмәтләренә фәнни, әдәби һәм техник редактор була.

Билгеле, цензор эше җиңелләрдән түгел. Бигрәк тә христиан диненең рухына туры килми торган фикерләр булган язмаларны бастыру тыела, патша хөкүмәте татарча китаплар чыгару мөселманнарны чукындыруга комачаулар дип курка. Шикле татар кульязмалары Петербургка цензураның баш идарәсенә җибәрелә. «Азия» типографиясенең эшләвенә Казан университеты ректоры Николай Лобачевский матди һәм рухи яктан ярдәм итеп тора. Эчке эшләр министрына Казанда көнчыгыш телләрендәге китапларны бастыруны дәвам итәргә кирәклеген дәлилләгән цензор язуында «Азия» типографиясе ачылуының максаты да Коръән, әдәби китаплар бастыруда дип күрсәтелә. Бу типографиянең әһәмияте – күп кенә кульязмаларны бастырып, татар халкының әдәби, рухи ядкарьләрен, шулай ук Ибраһим Хәлфиннең хезмәтләрен саклап калуда, халыкка таратуда.

Хәлфиннәрнең тормыш юллары һәм эшчәнлекләре – нинди заман булуга да карамастан, халыкка аңбелем бирүне максат итеп куйган чын зыялыларның матур бер яшәү үрнәге.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!

ТАРИХ КӨЗГЕСЕНДӘ, ЯКИ ИРЕККӘ ТУГРЫ КАЛУ

Быелгы яңа китаплар арасында нон-фикшн жанрында дөнья күргән берничә гаять кызыклы басма бар. Китап фанатлары тарафыннан бик тә көтеп алынган һәм резонанс тудырган икесенә тукталып үтәбез бу юлы. Әлеге китаплар – тарихи бүгенгебезгә урыны-урыны белән субъектив, ә урыны-урыны белән гаять объектив караш һәм бәя ул.

Автор:
Луиза Янсуар

«ҮЗ ТАРИХЫҢНАН БАШ ТАРТЫРГА ЯРАМЫЙ!»

BECOMING. МОЯ ИСТОРИЯ.

Эксмоның «Бомбора» сериясе нәкъ менә нон-фикшн һәм вакыйга булып исәпләнгән кулъязмалар белән эш итә, нигездә. Мишель Обама китабы – быелгы сезондагы яңалыклар арасыннан иң игътибарны җәлеп иткән тәрҗемәләрнең берсе. АКШ ның элеккеге беренче ледиы язган мемуарлар, әйтергә кирәк, Американың үзендә 3 миллионнан артык тираж белән сатылып, «кайнар пәрәмәч» кебек таралып бетте. Китап 32 телгә тәрҗемә ителеп, 10 ай дәвамында иң мәртәбәле китап рейтингларының берсендә – Amazonда беренчелекне бирмәде.

Рус телендә басылып чыгуга, аңа рецензентлар да, Мишель Обама фигурасына мөкиббән булучылар да, керләргә тырышучылар да бердәй ябырылды. Һәм бу аңлашыла да, шәхес һәм аның тирәсендә барган җәнҗаллар, бүгенге заман теле белән әйтсәк – хайп. Бомбораның юнәлеше дә шул: хайп дулкынында булган авторларны һәм басмаларны тиешлечә әйләнешкә кертеп, үз дәрәҗәсен, рейтингын тоту.

Әмма, хайпмы, түгелме, бер нәрсә шиксез: китап чынлап торып кызыклы һәм мавыктыргыч. Нинди генә җәнҗал да аны, асылда, бөш булса, укучы өчен күркәм итә алмас иде. Мин үзем Обама мемуарларыннан әллә ни көтмәдем, әмма – ялгышканмын.

Фотолар: https://www.livelib.ru/ һәм https://www.goodfon.ru/ сайтыннан алынды

Мишель Обама бик гади яза, хәер, аның бу стиле аша зирәклек бөркелеп тора. Әлбәттә, элеккеге беренче ледига булышмый калмаганнардыр, тулы бер команда китапны хәстәрләргә ярдәм иткәндер, дип фаразларга урын бар. Дөнья практикасында без мондый аналогларны яхшы беләбез һәм, билгеле ки, гаҗәпләнмибез дә. Ләкин, ничек кенә булмасын, кешегә үзе уртасында, эчендә кайнаган вакыйгаларга детальле анализ ясар, аларга караш ноктасын тәгаен көйләр, фикерен аермачык белдерер өчен… акыл кирәк. Һәм – эчке ирек. Кыскасы, кешене моңа махсус өйрәтеп булмый. Матур, шома язарга, сүз сөрешен көйләргә – әйе. Әмма вакыйгалардан фикер сөземтәсе чыгарырга – моны бары тик башыңнан кичереп һәм соңыннан чагылдырып кына була, дияр идем. Шуңа да Мишель Обама китабы минем өчен көтелмәгән һәм, сүз дә юк, күңелле ачыш булды.

Беренче леди күз алдына Америка яп-ялангач, махсус ябынча-бизәкләрсез килеп баса. Миңа кыйммәтле ташлар белән бизәлгән ванна бүлмәләре өйдән бигрәк музейны хәтерләткән шәхси йортлардагы аукционнарда булырга да туры килде. «Катрина» өермәсеннән соң булган бар мөлкәтен югалткан гаиләләрнең эшли торган суыткыч белән газ плитәсенә куанудан нишләргә белмәвен күрергә дә. Мин күзгә карап алдашкан икейөзле бәндәләрне, сатлык җаннарны очраттым. Шул ук вакытта рухы искиткеч нык укытучыларны, хәрбиләрнең хатыннарын һәм башка бик күпләрне күреп, үз күзләремә үзем ышанмаган чаклар да күп булды. Һәм, әлбәттә инде, дөнья буйлап йөргәндә, бик күп балалар белән таныштым. Алар мине күз яшьләрем атылып чыкканчы көлдерде дә, йөрәгемне өмет белән дә тутырды. Ә иң шәбе: без бергәләп бакчада казына башлауга, мин үз дәрәҗәмне дә, титулымны да бөтенләй онытa идем.

Кеше күз уңындагы шәхескә әверелүгә, мине кат-кат «җир шарындагы иң вәкаләтле ханым» дип тә атадылар, шул ук вакытта «явыз кара хатын» дигән мөһер дә сугып куйдылар. Беләсе килә: бу төшенчәнең кайсы өлеше мине ныграк әрнетергә тиеш булды икән – «явыз» дигәнеме, «кара» дигәнеме, әллә инде «хатын» дигәнеме?

Миңа милли телевидениедән иремә пычрак сүзләр ташлаучы, ачыктан-ачык яла ягучы кешеләр каршында еллар буе елмаерга туры килде. Ә иң сәере менә нәрсә: алар безне хурласа да, минем белән фотога төшүдән тайчанмады. Әле җитмәсә – ул фотографияне камин өстенә куеп, танышбелешләренә күрсәтүдән дә. Интернет-блогларда минем хакта нәрсә генә язмадылар… Боларның барысы да тәмам чыгырымнан чыгара иде, хәер, күбрәк – көлдерә, дисәм, дөресрәк булыр.

Мин Америка турында һаман да бик күпне белмим. Ә тормыштан нәрсә көтәргә икәнен – бигрәк тә. Әмма мин үземне беләм. Әтием, Фрейзер, мине үтә дәрәҗәдә тырыш булырга, еш көләргә һәм һәрвакыт биргән сүземдә торырга өйрәтте. Әнием, Мэриан – мөстәкыйль фикер йөртергә һәм турысын сөйләргә. Чикаго шәһәренең көньяк бистәсендә урнашкан тар, кысан фатирыбызда яшәгән елларда алар миңа гаиләбез тарихының ни дәрәҗәдә кыйммәт булуын төшендерде. Һәм ул гаилә тарихының ил тарихы кысаларында да – мөһим булуын.

Синең тарихың – бердәнбер кадерле нәрсә. Ул соңгы сулышыңа кадәр – синеке. Синеке генә. Башка нәрсәләрдән баш тартсаң да, үз тарихыңнан баш тартырга ярамый!

Мишель Обама китабындагы вакыйгалар, алар Ак йортны калдырып китеп, бераз сулыш алганнан соңгы вакыттан башланып китә. Ул аны «безнең яңадан үзебезгә үзебез хуҗа булган дәвер», «ирек дәвере» дип атый. Бу тарих гаҗәеп детальле, аналитик сыйдырышлы, әмма шул ук вакытта бик тә калку, масштаблы, дияргә була. Автор һәр вакыйганы аңарга китерүче факторлар белән, еракта, тирәннән алдырып, бүгенгегә бәйләргә омтыла. Ул тарихны үзләреннән башланган итеп кенә тоймый, хәтта – үзләренә кадәрге президент кәнәфиен һәм йортын биләгән затлар белән генә дә чикләми. Һәм, билгеле инде, үзләреннән соң килүчеләрнең дә адымнарына җентекле күзәтү, анализ ясарга тырыша. Бу анализда моңсу ноталар да, субъективлык та бардыр, бәлки, әмма кискенлек һәм беркатлылык юк. Бу – системаны ваемларга омтылу, ул системаның эчке шөрепләрен, хәрәкәт амплитудасын бәяләү ымсынуы.

Мишель Обама сүз башын тамырлардан башлый – милли асылдан. Күпмилләтле һәм расалы, күпкарашлы һәм үзенә үтергеч дәрәҗәдә ышанган, күкрәген «мин» дип каккан илнең көче дә, көчсезлеге дә каян – әнә шул кызыксындыра, шул борчый аны. Аның карашы – читтән торып та, эчендә кайнап та. Һәм бу караш үз артыннан китапның буеннанбуена ияртеп бара. Мавыктыра, бәхәсләшергә чакыра, ачуландыра, сокландыра… инандыра.

Без Мишель Обама буыныың нинди тәрбия алып, нәрсәләр йогынтысында үсүен күздән кичерәбез һәм бүгенге дөнья картинасын аныграк күзаллыйбыз. Китап гасыр эчендәге мәдәни кодларны, катламнарны үз эченә дыңгычлап тутырган. Ул – гаҗәеп тәрбия һәм үз-үзеңне үстерү тарихы да.

Спойлерларга бирелмичә генә укырга киңәш итәм.

Үзебез өчен Американы да, аның белән идарә итү бәхетенә (ә кайчакта бәхетсезлегенә) ирешкән, тарихның бер тоткасына әверелүдән искиткеч ирек тә алган, колга да әверелгән затларның үз эчке тыюлыгы – җаны һәм рухы өчен көрәшен ваемлар өчен.



ДИАЛОГИ С ВЛАДИМИРОМ СПИВАКОВЫМ

Соломон Волков исеме китап сөючеләргә яхшы таныш. Зәвыклы китап сөючеләргә – бигрәк тә. Ул – күренекле культуролог, сәнгать белгече, мемуарлар остасы. Гомеренең соңгы дистә елларын АКШ да яши. Волков – күпсанлы китаплар авторы, ул китаплар укучыларында һәрвакыт зур кызыксыну һәм полемикага омтылыш уята.

Ни өчен, дигәндә, Волковның иң үз иткән жанры – бөек замандашлары белән диалогка омтылу, шул сөйләшүләрдән өземтәләрне киң халык массасына җиткерү. Ул бу эшне үзенә күрә тарихи миссиясе буларак кабул итмиме икән дигән шик тә туа хәтта. Кем белә бит!

Язганнары җәлеп итми калмый. Минем үземнең күз алдымда шунда ук кайчандыр Ахматованың «яшь плеядасы» вәкиле булган егет килеп баса. Менә, алар Бродский белән «Бөек Старуха»ның дачасында гәпләшеп таң аттыралар. Менә ул Бродский турындагы китабын әзерләгәнче, аның белән еллар дәвамында серләшә, бәхәсләшә... Мондый форсатны язмыш, яки Фортуна ханым, дисәк дөресрәктер, һәркемгә дә бирми. Ярый, чордаш, аркадаш булу – анысы әле бер нәрсә, ә бит син шул даһи чордашыңның тере һәйкәлен тудырырга да алынасың... җөрьәт итәсең... Моның өчен сиңа үзеңә ни дәрәҗәдә сак, әдәпле, сабыр булырга кирәк тә, ни дәрәҗәдә – субъективлыктан ирекле булырга... Әйтер идем: һәркемнең дә альтер эгосы рөхсәт итә алмый моны... Бу – үзе бер талант, үзе бер җиһү.

Соломон Волков чорының бөекләре генә түгел, ә чын осталары, үз эшенең фанатлары галереясын тудыруы белән олы игътибарга һәм ихтирамга лаек. Әйе, әйе, ул аларны бөеклек призмасыннан караудан бигрәк, осталык, мастерлык призмасыннан күзәтә. Әйтерсең, җиткерергә тели кешеләргә: бөеклекнең аргы ягында күз алдына китерергә дә куркыныч булган, коточкыч авыр, җелекне суыра торган хезмәт ята. Үз эшеңә һәм иманыңа бирелгәнлек. Фидакарьлек. Каһарманлык!

Бу галерея гаҗәеп бай һәм киңкырлы: композитор Дмитрий Шостакович, скрипач Натан Мильштейн, язучы Иосиф Бродский... һәм менә, заманыбызның күренекле дирижеры Владимир Спиваков.

Бу китап Спиваковның юбилее уңае белән басылып чыккан иде. Һәм менә АСТ, Елена Шубина редакциясе аның яңартылган, тулырак басмасын тәкъдим итә. Уникаль эчтәлек-контентка һәм архив документларына, фотохроникаларга бай, искиткеч зәвыклы, затлы басма килеп чыккан. Диалог Волковның без инде ияләшеп өлгергән стилендә: үтә дә шәхси, детальле, җылы, интим, камералы ракурстан башлап, киң колач җәя һәм тарихи яссылыкка, дөнья мәдәнияте масштабына алып чыга. Без шәхес тирәли, әйтерсең, төрле биеклектә һәм якынлык-ераклыкта торучы көзгеләр... юк, камералар куеп чыкканбыз да, аны җентекләп күзәтәбез. Һәр сүзен, һәр ымын эләктереп алырга омтылабыз. Анализлыйбыз: сүтәбез, җыябыз... Ә иң мөһиме – Волковның барлык китапларына да хас үзенчәлек бу! – яратабыз аны.

Яратып якын килү, шуңа да артык авырткан темаларга, нокталарга саксыз кагылмау – әнә шуның белән үтә кадерле шәхсән миңа Соломон Волков стиле. Ул кагыла, кагылып кына калмый, кайта-кайта каезлый кайбер җөйләрне, әмма шул вакытта да күз алдында торган шәхесне түбәнсетмичә, кимсетмичә, аңа ирекле булып калырга, йөзен сакларга мөмкинлек биреп. Бу инде аның үзенең дә, әңгәмәдәшләренең дә чын мәгънәсендә затлылыгы – интеллигентлыгы турында сөйли.

Модернистларга алмашка постмодернистлар килде – юк, революционерлар түгел иде алар, гәрчә талантлы шәхесләр булсалар да. Араларында әллә ни зур алыплар күренмәде, тик күбесе үз пъедесталын тапты. Модернистлар васыять итеп калдырган мирасны үзара өзә-тетә бүлеште дә, сөяген дә калдырмады диярлек. Ә сәнгать ул арада «үзебезнекеләр өчен уен»га әверелде. Ябык клублар стилендәге: үз тәнкыйтьчеләре булган, дәрәҗәле киңәшчеләре, арт-фондлары, хәтта ки һәйбәт кәнәфиләрдә утыручы түрәләре дә.

Халыкка нишләргә кала иде соң? «Арт» төшенчәсе белән билгеләнгән басу-кырда читтәгеләрдән – аутсайдерлардан – кемгә урын бар? Ә бит сәнгатькә тартылу кешеләрдән беркая да качмаган иде югыйсә! Һәм нәкъ менә шушы аптыраш-та калган, таптанып басып торган заман аутсайдерларының сусавын басар өчен тарих мәйданында Спиваков пәйда булды. Ул алар каршына, аз да түгел, күп тә түгел, югары сәнгать белән тартынмыйча чыгып басты. Классик сәнгать белән! Ирекле рәвештә, үзен ышанычлы хис итеп.

Аны халык өеренә хезмәт итә, дип гаепләүчеләр табылды. Янәсе, ул нинди классик сәнгатьне алга сөрүче булсын, күңел ачарга гына ярый торган репертуар тәкъдим итә ич, әнә, халыкка шуңа да ошый. Һәм менә ул «күңел ачу репертуарында» – классик һәм модернистик сәнгатьтәге иң катлаулы авторлар. Брамс, Шостакович, Стравинский, Шёнберг, Барток... иң яңалардан – Шнитке, Щедрин, Пярт...

Һәм барысы да – үз ирегенә, рухына тугры калган, идеалларына хыянәт итмәгән авторлар...

Күптән түгел генә мин Спиваковның Карнеги-Холлдагы коцертында булдым. Зал шыгрым тулы. Зал аягүрә басып Стравинский әсәрен алкышлады! Ни өченме? Чөнки Спиваков аның «Итальян сюита»сын шундый дәрәҗәдә уйнады ки, бу әсәрне беренче мәртәбә ишетүчеләр аңардан тәмам әсәренде. Болай да була ала икән, дип таң калды!

Менә нинди аның яшерен миссиясе: гадилек аша катлаулы нәрсәләрне халыкка куркытмыйча, гайрәте чикмәстәй, йөзен чөермәстәй итеп җиткерә белү... яраттыру!

Бу китапның тагын бер бик тә олы миссиясе, вазифасы бар: ул талантның каян килүе, аны ничек тәрбияләү, үстерү, ничек саклау турында. «Бөеклек», «мин-минлек» чире белән авырудан ирекле булып кала алып, хезмәтеңә һәм эчке иманыңа тугрылыкны саклау турында. Ә ул сыйфатлар бары тик зыялы кешедә генә була ала, дип ассызыклый Волков һәм аның әңгәмәдәше.

Шуңа да китап – гаҗәеп җиңел һәм гыйбрәтле.

Шуңа да алар бу әңгәмәгә бик күркәм рәвештә парлап дирижерлык итә.


www.protatarstan.ru
Поиск...
РУС | ТАТ
Подписка!
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Арыш ипие – иң кадерле сый
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
25 ноября 2019
2020 елда казанлылар беренче тапкыр Бөтенроссия халык санын исәпләүне интернетта уза алачак
22 ноября 2019
«Казан Кремле» музей-тыюлыгының «Манеж» Күргәзмәләр залында «Объектива – аны» дигән күргәзмә ачылачак
21 ноября 2019
Казанда кәрәш буенча Татарстан чемпионаты узачак
Бәхет тулы еллар...
Беренче Казан «хрущёвка»ларында кемнәр өй туйлары уздыра
Миркасыйм Госманов: югалган мирас эзеннән...
Ватанга кайту
Якты киләчәк ничек төзелгән
1960 нчы еллар
Реклама 16+

МАХСУС ПРОЕКТ

— 48нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Рафаил Глянц, Түбән Кама шәһәренең тәүге төзүчеләреннән берсе, Россиянең һәм ТРның атказанган төзүчесе, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почет Билгесе» орденнары кавалеры, декабрь аенда үзенең 85 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Түбән Каманың тәүге төзүчеләреннән берсе, мактаулы һәм ихтирамлы зат

Василий Носов,
«МТМЛ ИК» ЖЧҖ
генераль директоры

Фото www.vasha-gazeta.ru сайтыннан алынды

– Хөрмәтле Рафаил Григорьевич, Сезне чын күңелдән 85 яшь тулган көнегез белән тәбрикләргә һәм бу көндә яңгыраган барлык изге теләкләргә кушылырга рөхсәт итегез!

Сезнең зирәк акылыгыз һәм хезмәт сөючән кулларыгыз белән Түбән Кама каласына нигез салынган. Ерак 1961 елда Сез бирегә, ялан кырга, инженер вазыйфасында килеп төшкәнсез. Мәгълүм булганча, беренче адымнар – иң катлаулысы, әмма Сез, кыенлыклардан куркып калып, кирегә чигенүчеләрдән түгел. Гаять зур комсомол төзелеше озак елларга Сезнең тормыш куәтенә һәм илһам чыганагына әйләнгән.

Сез нинди дә булса эшкә алынасыз икән, аның нәтиҗәсе һәм сыйфаты турында хафаланасы юк. Һәр проектыгызга зур җаваплылык белән карыйсыз: төзелешне шәхсән үз контролегездә тотасыз һәм фатирларны карап йөрисез, барысын да кешеләр өчен бик уңайлы итәргә тырышасыз. Түбән Кама үсешенә керткән өлешегез бәяләп бетергесез – Сезнең актив катнашыгызда берничә миллион квадрат метр торак һәм шәһәрнең бөтен инфраструктурасы диярлек төзелгән.

Ышанып әйтә алам: Түбән Каманың бүгенге казанышлары өчен без аның беренче төзүчеләренә, шул исәптән, Рафаил Григорьевич, Сезгә бурычлы! Нәкъ менә Сез шәһәргә тормыш сулышы өрдегез һәм аның киләчәктәге үсеш юнәлешен билгеләдегез.

Сезгә сәламәтлек һәм яраткан шәһәребезне күркәмләндерү юнәлешендә тагын да киңрәк колач һәм мөмкинлекләр булуын телим. Сезгә һәр көн канәгатьлек хисе, гармония һәм рәхәтлек китерсен! Озын гомер һәм бәрәкәтле мул тормыш телим Сезгә!

Реклама

МТМЛ
УПРАВЛЯЮЩАЯ КОМПАНИЯ

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-76,

8-9272-483-384

e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

ДҮРТ САКЛАУНЫҢ БЕРСЕ

Бу авылга баргач, һәр танышкан кеше күңелгә кереп калды. Һич шигем юк, алар сезнең өчен дә кызыклы булачак. Сүзем – Сарман районының Карашай-Саклау авылы турында.

«ҮЗ АВЫЛЫ МӘКТӘБЕНДӘ БЕЛЕМ АЛГАН БАЛА БӘХЕТЛЕ»

Сарманда Саклау исемле берничә авыл бар – Югары Саклау, Чиле Саклау, Саклаубаш, Карашай-Саклау. Аларны нәрсә берләштерә соң? XVII гасыр башында, Петр I Указы нигезендә, кораб төзелешенә Сарман урманнарыннан имән кисә башлыйлар. Моны җирле халык башкара. Агачлар кайда киселгән, шунда саклана. Шуңа ул урыннарны «саклау» дип йөртә башлыйлар. Карашай-Саклау исеме әнә шуннан килеп чыккан.

Белмим, мондый чагыштыру урынлы булырмы: авыл миңа матур гына киенгән, горур атлап барган урта яшьләрдәге ир-атны хәтерләтте. Тормыш көйләнгән, халыкның эш урыны бар, йорт-җирләр төзек...

Бүген бирегә 310 кеше яши, 142 хуҗалык бар. Саланың чәчәк аткан чоры Бөек Ватан сугышына кадәр булган. Җирле халык игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балыкчылык белән шөгыльләнгән. Читкә китеп эшләү булмаган.

– Бездә күрше авыллардагы кебек итек басмаганнар, чана да ясамаганнар, – диде туган ягының тарихын өйрәнгән Назыйм Мәхмүтов. – Авыл кешеләре гади, шул ук вакытта тәрбияле дә. Сарманда халык бик тырыш. Карашайда да искәрмә түгел.

Авыл җирлегенә тагын күрше Чураш авылы да керә. Үзәк булып Карашай-Саклау тора. Бирегә төп белем бирү мәктәбе (берничә ел элек урта мәктәп булган), мәдәният йорты, ФАП, кибетләр – кыскасы яшәү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. 1969 елда салынган мәктәптә 34 бала белем ала икән. Эшли башлаганнан бирле бер тапкыр да капиталь ремонт ясалмаган белем үзәгенә без дә кереп чыктык. Дөресен генә әйткәндә, хәзер мондый мәктәпләрне бик очратмыйбыз. (Утыз ел элек салынган мәктәпләрнең күбесе дәүләт программасы буенча яңартылып бетте). Ә Карашай-Саклау мәктәбе бу исемлеккә кермәгән. Әйе, аның идәнен алыштырганнар, стеналарын буяганнар. Ә ишек, тәрәзәләр, гомумән, мәктәпнең тышкы кыяфәте яңартуга мохтаҗ.

– Ата-аналар монысына да бик риза, – диде Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы Вероника Хөсниева. – Берничә ел элек мәктәпне япмакчы иделәр. Кая гына язмадык, бармадык. Тәки теләгебезгә ирештек, япмадылар. Минем үземнең дә кызым бирегә укый. Туган авылы мәктәбендә белем алган бала бәхетле ул. Иртүк торып автобус көтәсе юк. Кайтасы килгәндә кайта. Ә ремонт... Бәлки иганәчеләр табып булыр әле. Хәер, хикмәт мәктәпнең кыяфәтендә түгел, ә белем бирү дәрәҗәсендә, балаларга мөнәсәбәттә. Ә бездә укытучылар коллективы көчле.

Фото: Александр Ефремов

– Бездә күрше авыллардагы кебек итек басмаганнар, чана да ясамаганнар, – диде туган ягының тарихын өйрәнгән Назыйм Мәхмүтов.

Автор:
Руфия Фазылова

– Беренче КАМАЗны 2002 елда алдым, – диде Илгиз Мөхтәров.

ИРЛӘР ШӨГЫЛЕ

Карашай-Саклауда ир-атларның күбесе үз эше белән мәшгуль. 2000 нче елларда, колхозлар таралып, авылда эш калмагач, ир-атлар үзләренә КАМАЗ машиналары сатып алган. Андыйлар бүген авылда 16 кеше икән. Шуларның берсе – Илгиз Мөхтәров. Бер түгел, ике КАМАЗы бар аның. Башта колхоз техникасында эшләгән, хәзер менә – үз-үзенә хуҗа.

– Беренче КАМАЗны 2002 елда алдым, – диде Илгиз абый. – 2003 елны шәхси эшмәкәр булып теркәлдем. Төрле оешмалар белән эшлибез бит, документлаштырмасаң булмый. Мин бик еракларга йөрмим, Удмуртия кебек әллә ни ерак булмаган төбәкләргә генә чыгам. Авылда шактый еракларга йөрүчеләр дә бар. Әле эшнең тыгыз вакыты, чөгендер, ашлама ташыйбыз. Кыш көне буш торган вакытлар да була.

– Гаиләне шушы машина туендыра алайса? – дим.

– Тырыш булсаң, иренмәсәң, яшәргә була инде. Зарланмыйм... Ник алганыма үкенмим. Ә башка тагын кайда эшлисең? Чаллы, Сарман, Минзәлә безгә чагыштырмача ерак түгел, шунда йөк ташыйбыз. Зәй шикәр заводы белән килешү төзедек, чөгендер ташыйбыз. Әлбәттә, чыгымнар да шактый. Ике КАМАЗга елына утыз меңнән артык салым гына түлим, ягулыгын да кушкач – җыела. Тик барыбер җитә, Аллага шөкер.

Илгиз Мөхтәров кебекләр авылда күп булса, Таһир Мөхәммәтов шикелле кеше бүтән юк. «Ат җене кагылган» диләр бит, бу очракка ул бик «мач» килә.

Таһир Мөхәммәтов хуҗалыгында кырыктан артык ат бар. Аннан башка авыл, район сабантуйлары узмый икән. Ел саен биш-алты ат әзерли ул. Күбесе гел алдынгы урыннарда килә.

– Кызым Рәзилә район Сабантуенда беренчелекне бирми, – диде Таһир абый. – Өч яшьтән ат өстенә утыртып куйган идем, шуннан төшмәде инде. Мәктәпкә укырга кергәнче үк, ярышларда ат өстендә чапты.

Рәзилә дә этисе кебек ат белән «җенләнгән». Шуңамы, кыз Минзәлә ветеринария техникумына укырга кергән. Быел тәмамлый икән.

– Рәзилә аннан авылга кайтамы? – дигән идем:

– Кайтмас инде. Район, шәһәр тирәсендә калыр. Ә авылны ташламас дип уйлыйм, болай да атна саен кайтып йөри. Атларны күбрәк сагынамы, минеме, белмәссең. (Көлә).

Таһир Мөхәммәтов фермер булып теркәлмәгән. Атларны да ул үз көче белән үрчеткән. Җире дә юк. Солы, печән, саламны сатып ала икән. Мин исә, аптырап:

– Атлар гел ашап тора бит. Сатып алган азыкны ничек җиткерәсез? Файдасы каламы? – дигән идем:

Таһир Мөхәммәтов хуҗалыгында кырыктан артык ат бар.

Язмыш Фәхрәзиевләрне яңадан туган нигезләренә кайтырга мәҗбүр иткән.

– Дөресен генә әйткәндә, атлар асраудан аңа бер файда да калмый, – диде безне тыңлап торган Вероника Хөсниева. – Ул аларны файда өчен түгел, күңеле кушканга асрый. Шуннан ләззәт ала. Җәен-кышын шулар белән мәш килә, көтү көтә. Кышын да алып чыга. Аның бөтен яшәү рәвеше шул атларга бәйле.

– Безнең әти дә ат караучы иде, – диде Таһир абый. – Атсыз торганны белмим. Дөрес, моның кадәр күп түгел иде. Биш-алты ел элек кенә баш санын кырыкка җиткердем. Алай җиңелрәк. Колыннарын үстереп сата торам, ул акчага иген, печән алам. Әле бит паспорты булган нәселле чабышкы ат та сатып алдым. Аны башка атлардан аерып тотам. Көн саен ике тапкыр йөгерергә алып чыгам.

– Ул чабышкы атыгыз белән берәр җиңү яуладыгызмы соң? – дим.

– Ижау, Уфа, Оренбургта узган ат чабышларында катнаштык. Призлы урыннарны алдык. Бик канәгать булып кайттым.

– Андый зур ярышларда җиңү аз булса да матди хәлне җиңеләйтәме? – дим.

– Һаман акча ягын сорыйсыз. (Көлә). Бик дәрәҗәле ярышларда җиңсәң, отышлы инде ул. Ә гадиендә… Ярышка баргач, атыңны махсус җиргә урнаштырырга кирәк, бу, кимендә, 3–4 мең сум тирәсе. Шуңа юл бәяләрен куш. Үзеңә калмый инде. Әле бит чабышкы атына солы белән печән генә ашатып булмый, аерым меню кирәк. Шулай булгач, мондый ат тоту кесәгә суга. Тик акча белән исәпләнми торган әйберләр бар, сеңлем…

«ӘНИ ВАСЫЯТЕН ҮТӘП...»

Язмышлар, диген… Өч бертуган – ике хатын-кыз, бер ир-ат бер түбә астында шулай тату яшәгәнен күргәнем юк иде. Тату гынамы соң? Өч ел элек заманча зур йорт җиткергәннәр, фермер булып теркәлгәннәр, зур гына хуҗалыклары бар. Моннан тыш, һәркайсының төп эш урыны да бар. Фәхрәзиевләрнең иң олысы Нәҗипкә – 55 яшь, Гөлфия белән Әлфиягә 43 яшь. Абый кеше сеңелләренә әти дә, туган да. Аннан башка йортта бер эш башламыйлар.

– Йорт салу абыйның теләге иде, – диде Гөлфия Фәхрәзиева. – Ул вакытта әле әниебез исән иде. Абый башта аның фатыйхасын алды. Ике ел дигәндә йортны салып чыктык. Шуңа сөенәм: әниебез бу йортта яшәп калды.

Игезәкләр – Гөлфия белән Әлфия югары белемле тәрбиячеләр. Чаллыда балалар бакчасында эшләгәннәр. Язмыш аларны яңадан туган нигезләренә кайтырга мәҗбүр иткән.

– Әнинең хәле начарайгач, эшемне ташлап авылга кайттым, – диде Гөлфия. – Абый – Себердә, вахта юлы белән эшли. Бер ай монда, бер ай эштә. Хәер, китеп эшләмәсә дә, авыру әнине абыйга гына калдырмас идек. Аннан Әлфиянең дә ире үлеп китте. Ике яшьлек кызы белән ул да монда кайтты. Менә шулай көтмәгәндә туган нигезгә җыелыштык.

Без килгән көнне өйдә кайнар бәлеш белән баскан токмачлы аш пешкән иде. Нәҗип абый Себердән кайткан. Сеңелләр абыйларын гел шулай мул табын белән каршы алалар икән.

– Авылга кайткач, бер ай буе сыйланып кына ятам, – дип елмайды абый кеше.

Юк, әлбәттә, бу гаиләдә сыйланып кына ятып булмый. Эшләргә дә кирәк һәм – күп итеп. Ике ел элек, 200 мең сум грант отып, мини-ферма ясаганнар. Бүген 8 са-

вым сыеры бар. Моңа өстәп – таналар, бозаулар...

– Тагын йөзләп баш кош-корт асрыйбыз, – диде Гөлфия Фәхрәзиева. – 300 баш тавык, 50–100 баш каз, үрдәк, бүдәнә (перепелка – авт.) – төрле кошлар үрчетәбез. Соңгы вакытта шушы өлкә белән нык кызыксына башладым. Интернеттан төрле токымлы тавык йомыркалары кайтартам. Аны инкубаторда бастырып чыгарам.

– Токымлы тавыклар сезгә ни өчен кирәк? – дим.

– Тәк инде, кызык өчен. Йомыркалары тәмлерәк кебек.

– 300 баш тавыкның йомыркасын кая куясыз?

– Сатабыз. Сораучылар күп. Өй йомыркасы тәмле бит.

Ул да түгел, Нәҗип абый белән Алия кайтып керде. (Алия – Әлфиянең кызы).

– Өчебезгә – бер бала, – дип елмайды абый кеше. – Мәктәптән барып алдым. Себердән кайтканымны зарыгып көтеп тора. Мин юкта әнисе белән апасы маллар янына алып чыга. Мин исә чыгармыйм, иркәләп кенә тотам үзен.

Шактый озак утырдым бу гаиләдә. Туганнарның берберсенә булган җылы мөнәсәбәтен күреп, хәтта бер мәл аптырап куйдым. Мал бүлеп, сәлам дә бирешмәгән туганнар бар. Ә монда...

– Безнең бер-беребезгә кычкырып эндәшкәнебез дә юк, – диде Нәҗип Фәхрәзиев.

– Ә ничек шулай? – дим.

– Әти белән әни шулай тәрбияләде безне. Әни үлгәндә дә: «Бер-берегезне ташламагыз», – дип әйтте.

КАРТЛЫК НИЧӘДӘ БАШЛАНА?

Авылларга баргач, һәрвакыт берәр өлкән кеше белән очрашырга тырышабыз. Карашай-Саклауда Рәсимә Билалова белән таныштык һәм тел шартлаттык! Бу кадәр эшләрне бер кеше эшли алмаска тиеш кебек. Әмма була икән бит!

Рәсимә апа җырлый, гармунда уйный, шигырьләр яза. Һәм аларны бүген дә сәхнәдәдән җырлый, сөйли.

– Концертта ул булса, алып баручы да, җырлаучы да, уйнаучы да кирәк түгел, – диде Карашай-Саклауның авыл җирлеге башлыгы.

Болардан тыш, Рәсимә апа чигә, бәйли. Кул эшләрен рамкага

Рәсимә Билалова ярты сәгатькә якын концерт куйды безгә.

алып, бөтен стенага элеп чыккан. Тагын 77 яшьлек әби утыз сутый бакчасын бер ялгызы утырта, эшкәртә. Бәрәңге, чөгендер, кабак... Җәй көне өйдә тормый дияргә дә була.

– Балаларыгыз булышмыймы? – дигәч, әби сөйләп китте:

– Һәр кешенең – үз тормышы. Бу шулай булырга тиеш тә. Аякта йөргәндә балаларга йөк буласым килми. Атлаган саен аларны чакырып кайтарыйммы?! Кайталар, киләләр, рәхмәт яусын. Тик фәлән эшем бар, дип беркайчан чакырганым юк.

Рәсимә Билалова дүрт бала үстергән, ни кызганыч, бер баласын җирләгән инде. Гомер иткән тормыш иптәшен дә югалткан. Шуңа карамастан, яшәү дәртен югалтмаган ул. Ярты сәгатькә якын концерт куйды ул безгә. Күз тимәсен, дип тыңлап тордык.

Рәсимә апа башта авылда сыер савучы булып эшләгән. Тормыш иптәше үлгәннән соң, Чаллыга китеп, кошчылык фабрикасында эшләгән. Әлеге дә баягы, балалар хакына, дип.

– Колхозлар таралгач, авылда тормышлар авырайды, – диде Рәсимә апа. – Балаларга ярдәм итәргә кирәк, дип, авылдан киттем. Дөрес, атна саен кайтып йөрдем, бакча тоттым. Чаллыда ике бүлмәле фатир алгач, аны улыма калдырып, яңадан авылга кайттым.

Карашай-Саклауга кайткач, Рәсимә Билалова килен булып төшкән йортын яңадан рәтли. Сыер ала. Әле малларны бетергәнгә өч кенә ел икән. Хәзер аның төп шөгыле – бәйләү, яшелчә, җиләк-җимештән төрле салатлар, кайнатмалар әзерләү.

...Рәхәт кешеләр була. Карашай-Саклауда без менә шундый кешеләр белән аралаштык. Алар сиңа, якын итеп, «апаем» дип эндәшә. Бернинди һавалану, уфтану юк. Булганына шөкер итеп, тормыштан ямь табып яши беләләр. Бу яктан алар – күпләргә үрнәк.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Саклау авылы исеме беренче ревизия документларында 1709 елда искә алына. Ә Карашай дигән исеме XVIII гасырның урталарында гына кушыла һәм ул кеше исеме белән бәйле. Анда да «деревня Саклово или Карашай Саклово» дип бирелгән. Беренче ревизия вакытында авылда 5 гаилә яшәгәнлеге билгеле. Аларның нәселләре бүген дә авылда яши.

XVII гасыр азагында Казанның Дәрвишләр бистәсеннән бу якларга күпләп халык килеп урнаша. Шул исәптән – Карашай-Саклауга да. Әйткәнемчә, аңа кадәр бу урында күпмедер кеше яшәгән. Җир астыннан табылган көнкүреш калдыклары шул турыда сөйли. Моны тарихчылар да раслады. Шулай булгач Дәрвишләр бистәсеннән килгән халык авылга нигез салучылар дип әйтеп булмый, ә бәлки авылны зурайтучылар дияргә кирәктер.

Назыйм Мәхмүтов, мөгаллим, төбәк тарихын өйрәнүче.

Балыклы урыннар Татарстанда бик күп. Әйләнә-тирәдә – елгалар, ә кайчагында, ярлары күренмәүне исәпкә алсаң, диңгез-дәрьялар җәелеп ята, диярсең. Чулман белән Идел үзләре генә дә ни тора! Һәм бу иксез-чиксез Татарстан суларында балыкларның тулы колонияләре яши. Ниндиләрме? Бу сорауга төгәл җавап беләсегез килсә, Балык Бистәсенә барыгыз, һәм – туп-туры яр буена. Монда, елгага кармак салмыйча да, күп нәрсә белә аласыз. Биредәге «елга халкы»ның исемнәре турыдан-туры эскәмияләргә сызгалап куелган. Алар, җил уңаена әйләнеп, сезнең якка әле бер, әле икенче ягы белән борыла. Шамбы, ташбаш, ротан, опты, кәрәкә... Балык Бистәсе патшабикәсе – кырпы балыгы – бу рәвешле теркәп куюга да мохтаҗ түгел. Ул яр буенда үзәк урынны алып тора. Аны монда XVI гасырдан, әлеге бистә хәрби ныгытма булмаган чактан ук, яхшы беләләр. Тора-бара бу бистә, Чулман, Бәтке, Әшнәк, һәм Шобыт елгаларының су асты җан ияләре хисабына мантый бару сәбәпле, һөнәрле-кәсепле, сәүдә белән шөгыльләнүче бик бай авылга әверелгән.

«Зәңгәр җирлектәге көмеш балык тоту җәтмәсе, калканның сул ягыннан салынып төшеп, аның уң яктагы югары өлешен ачык калдырган, һәм бөтенесе өстендә – койрыгын «чапылдатучы» алтын кырпы» – Балык Бистәсе гербында нәкъ шушы балык сурәтләнгән. Патша-балыкның гигант нөсхәләре ерак елларда калган инде, андыйларның кайбер фотографияләре һәм сөкәтләре генә ил музейларында саклана, шуларның иң тәэсирлесе – ТР Милли музеена куелган.

Хәзер кырпы балыгын көндез шәм яндырып эзләсәң дә табып булмый. Без дә таба алмадык, югыйсә исемнәре без әйткән эскәмияләргә язылганнарның ишләрен Балык Бистәсендә сатып алырга мөмкин – чи килеш тә, тозланганын да, ысланганын да.

Ә бит элек... Чеховның «Куен дәфтәре»ндәге язманы хәтерлисезме? «Станция янындагы пычрак трактир. Һәм һәрбер трактирда һичшиксез керән белән тозлы кырпы балыгын таба аласың. Россиядә никадәр кырпы балыгы тотыла бит!»



«Трактирщик». Б.М. Кустодиев.

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый



2019 ел. Балык Бистәсе.

Фото: журнал «Татарстан»

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

XX гасыр башы. Балык Бистәсе авылы.

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ